2 ° 2017

# ФӘННИ ТАТАРСТАН



ISSN 2499-9741

КАЗАН

***Журнал «2014 — 2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән,
мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология
һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ФӘТТАХОВ Э.Н., Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары —
мәгариф һәм фән министры (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛЬОГЛУ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

► **БАШ РЕДАКТОР**

КИМ МӨГАЛЛИМ улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ДӘҮЛӘТШИНА Л.Ш. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХАЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият һәм халык иҗаты)

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

Я.М. АБДУЛКАДЫЙРОВА, Н.Т. АБДУЛЛИНА, Е.Ф. ЛУКЬЯНЧЕНКО

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Сөләйманов Җ.Ш., Хәкимов Б.Э., Гыйльмуллин Р.А.* Татар теле корпусын төзүнең концептуаль һәм лингвистик аспектлары . . . . 7
*Әхмәтҗанов И.Г., Гәрәева А.К.* Татар һәм инглиз телләрендә дендротопонимнарны өйрәнү тәҗрибәсеннән . . . . . . . . . . . 17
*Максимов Н.В.* Сөйләм: абстракт һәм конкрет төшенчәләр . . . . . 22
*Миңнуллин Б.К.* Гомуммилли телнең яшәеш формасы буларак әдәби тел һәм аның функциональ стильләре . . . . . . . . . . . . . 28
*Миргалимов И.Ф.* Татар дөнья картинасында пространствоны горизонталь яссылыкта күзаллау модельләре . . . . . . . . . . . . 33

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Газиев И.М.* Граммофон язмаларында Тукай әсәрләре . . . . . . . 37
*Рәмиев З.З.* Галимҗан Ибраһимов һәм Фатих Әмирхан (1917 елга кадәр) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
*Жакупов Ж.А.* Казакъ-татар рухи элемтәсенең бер күренеше хакында (Г. Ибраһимов һәм А. Байтурсынов) . . . . . . . . . . . 50
*Насибуллова Г.Р.* «Казан утлары» журналы һәм хәзерге татар әдәбияты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Мөхәммәтҗанова Л.Х., Әхмәтгалиева Г.Р.* «Каһарман Катил» дастанында утка табыну йоласы һәм дини-мифик Иблис образы чагылышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Заһидуллин И.К.* Мөселман руханиларының 1905 елгы Уфа корылтае . 66
*Миңнемуллина Ч.Д.* Казан әҗнәби укытучылар семинариясендә музыка укыту (XIX гасырның икенче яртысы) . . . . . . . . . . 86
*Окан Таһир.* Финляндия ислам җәмгыяте . . . . . . . . . . . . . . . 90

### ТАБИГАТЬ ФӘННӘРЕ

*Рәхимов И.И., Ибраһимова К.К.* Интенсив хуҗалык эшчәнлеге шартларында Татарстан экосистемасының табигый биотөрлелеген саклау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
*Миңнуллина Л.Ф., Шәйдуллина Э.Р.* Уропатогеннарның антибактериаль матдәләргә каршы торучанлыгы . . . . . . . . . . 107
*Миңнуллина Л.Ф., Һадиева Г.Ф.* Биопрепаратлар буларак кулланырга яраклы яңа *Bacillus subtilis* штаммнары . . . . . . . . . 115

### ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Шәйдуллин Р.В.* Тарихчы галим, остаз һәм татар халкының милләтпәрвар улы *(Вәлиев Рәмзи Кәлим улына 80 яшь тулу уңаеннан)* . . . . . . . 121

## ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН

*Яхин Ф.З.* Дүрт ягым кыйбла: Арчаның тарихи халкына бер сәяхәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

## СӘНГАТЬ

*Москвина А.Р.* Мәгариф, фән һәм мәдәният өлкәләрендә татар-казакъ мөнәсәбәтләренең яңа формалары *(ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ тәҗрибәсеннән)* . . . . . . . 148
*Галимова Э.М.* Татар музыка сәнгатендә Г. Тукай мирасы . . . . 152
*Шкляева Л.М.* Урта Идел буе татарлары йортларын бизәүдә төрки орнаментлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
*Газизова М.Р.* 1920–1930 елларда «Чаян» журналы битләрендә халыкара сәяси сатира . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Рамазанова Д.Б.* Булатова М.Р. Курмантауский говор среднего диалекта татарского языка в этнолингвистическом аспекте . . 168
*Солтанова Р.Р.* Сәнәигы нәфисә. Искусствоведение Татарстана: альманах. Выпуск 1. Теория, история, современная художественная практика, арт-рынок . . . . . . . . . . . . . . . . 173
*Яруллина А.Г.* Татарлар һәм Татарстан: «Татар энциклопедиясе»нең 5 нче томы дөнья күрде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ


*Сулейманов Дж.Ш., Хакимов Б.Э., Гильмуллин Р.А.* Концептуальные и лингвистические аспекты разработки корпуса татарского языка . . . 7

*Ахметзянов И.Г., Гараева А.К.* Из опыта изучения дендротопонимов в татарском и английском языках . . . 17

*Максимов Н.В.* Речь: абстрактные и конкретные понятия . . . 22

*Миннуллин Б.К.* Литературный язык как форма существования общенационального языка и его функциональные стили . . . 28

*Миргалимов И.Ф.* Горизонтальные модели представления пространства в татарской картине мира . . . 33


### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ


*Газиев И.М.* Произведения Тукая в граммофонных записях . . . 37

*Рамеев З.З.* Галимджан Ибрагимов и Фатих Амирхан (до 1917 года) . 44

*Жакупов Ж.А.* Об одном факте казахско-татарской духовной связи (Г. Ибрагимов и А. Байтурсынов) . . . 50

*Насибуллова Г.Р.* Современная татарская литература и журнал «Казан утлары» . . . 56


### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО


*Мухаметзянова Л.Х., Ахметгалиева Г.Р.* Огнепоклонничество и религиозно-мифический образ Иблиса в дастане «Кахарман Катил» . . . 60


### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ


*Загидуллин И.К.* Курултай мусульманского духовенства 1905 года в Уфе . . . 66

*Миннемуллина Ч.Д.* Преподавание музыки в Казанской инородческой учительской семинарии (вторая половина XIX века) . 86

*Окан Дахер.* Исламское общество в Финляндии . . . 90


### ЕСТЕСТВЕННЫЕ НАУКИ


*Рахимов И.И., Ибрагимова К.К.* Сохранение биоразнообразия природных экосистем Татарстана в условиях интенсивной хозяйственной деятельности . . . 96

*Миннуллина Л.Ф., Шайдуллина Э.Р.* Сопротивляемость уропатогенов антибактериальным веществам . . . 107

*Миннуллина Л.Ф., Хадиева Г.Ф.* Новые штаммы *Bacillus subtilis,* пригодные к использованию как биопрепараты . . . 115


### ПЕРСОНАЛИИ


*Шайдуллин Р.В.* Валеев Рамзи Калимович: ученый и наставник молодежи *(к 80-летию)* . . . 121

**ПО СЛЕДАМ ЭКСПЕДИЦИЙ**

*Яхин Ф.З.* Путешествие к историческому населению
Арского района . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

**ИСКУССТВО**

*Москвина А.Р.* Новые формы татаро-казахских отношений
в области образования, науки и культуры
*(из опыта ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ)* . . . . . . . . . . . 148

*Галимова Э.М.* Наследие Г. Тукая в татарском музыкальном
искусстве . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152

*Шкляева Л.М.* Тюркский орнамент домовой резьбы у татар
Среднего Поволжья . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157

*Газизова М.Р.* Международная политическая сатира
на страницах журнала «Чаян» в 1920–1930-е годы . . . . . . . . 162

**НОВЫЕ КНИГИ**

*Рамазанова Д.Б.* Булатова М.Р. Курмантауский говор среднего
диалекта татарского языка в этнолингвистическом аспекте . . . . 168

*Султанова Р.Р.* Сәнәигы нәфисә. Искусствоведение Татарстана:
альманах. Выпуск 1. Теория, история, современная
художественная практика, арт-рынок . . . . . . . . . . . . . . . . 173

*Яруллина А.Г.* Татары и Татарстан: вышел 5-й том «Татарской
энциклопедии» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176

**НАУЧНАЯ И ОБЩЕСТВЕННАЯ ЖИЗНЬ**

УДК 811.512.145'33

***Җ.Ш. Сөләйманов,***
***Б.Э. Хәкимов,***
***Р.А. Гыйльмуллин***

# ТАТАР ТЕЛЕ КОРПУСЫН ТӨЗҮНЕҢ КОНЦЕПТУАЛЬ ҺӘМ ЛИНГВИСТИК АСПЕКТЛАРЫ

Статья посвящена вопросам разработки концептуальной основы и уточнения модели корпуса татарского языка. Исследуются особенности представления лингвистической информации и предлагаются принципы корпусной морфологической разметки текстов на татарском языке. Самостоятельную проблему представляет обеспечение репрезентативности текстовой коллекции корпуса, одним из путей решения которой является статистический анализ лингвистических особенностей текстов. На процесс разработки корпуса татарского языка и его лингвистической разметки влияют особенности языковой системы, в частности соотношение регулярных и нерегулярных явлений.

**Ключевые слова:** татарский язык, корпусная лингвистика, информационные технологии, лингвистические модели, репрезентативность корпуса текстов, лингвистическая корпусная разметка.

Табигый телләрне эмпирик төгәл материал нигезендә тел мәгълүматларын автомат рәвештә эшкәртү технологияләрен кулланып тикшерү хәзерге фән өлкәсендә перспектив юнәлешне тәшкил итә. Телләрнең электрон корпусларын төзү күп кенә лингвистик мәсьәләләрне чишүнең иң нәтиҗәле чарасы санала. Татар теле өчен шундый системаны булдыру тел төзелеше, аның лексик составы турында яңа мәгълүматлар алу белән бергә башка телләрнең, аерым алганда төрки телләрнең, лингвистик модельләрен төзү, әлеге телләрдәге текстларны электрон технологияләр ярдәмендә эшкәртү өлкәсендә дә яңа мөмкинлекләр тудыра.

Татар теле корпусын төзү өлкәсендә тикшеренүләр XX гасырның 90 нчы елларыннан башлап Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм Казан (Идел буе) федераль университетындагы фәнни коллективлар тарафыннан алып барыла [Бухараев, Сулейманов, 1995; Бухараев, Сафиуллина, Сулейманов, 1995]. Аның төп юнәлешләрен компьютерлар өчен лингвистик модельләрнең формаль алгоритмнарын эшләү һәм машина тәрҗемәсе, эзләү системалары, компьютер лексикографиясе кебек өлкәләрне колачлаган гамәли тикшеренүләр тәшкил итә. Алга таба машина фонды концепциясе билгеле бер үзгәрешләр кичереп һәм тулыланып, татар теленең барлык лингвистик ресурсларын колачлаган гомумтел корпусы концепциясенең нигезен тәшкил итте. Хәзерге вакытта шундый гомумтел корпусы концепциясе «Туган тел» корпусы проектында гамәлгә ашырыла [Татарский национальный корпус...].

**1. Татар теле корпусының концептуаль моделе.** Мәгълүм булганча, һәр табигый тел кешелек җәмгыятендә аралашу һәм дөньяны тасвирлау максатларына хезмәт итә торган катлаулы семиотик системаны тәшкил итә. Бүгенге көндә дөньяның үзенчәлекле информацион моделе саналган телнең теге яки бу күренешләре модельләрен төзүнең төрле юллары бар. Телне формаль яктан тулаем тасвирлау мөмкин булмау сәбәпле, безнең тарафтан лингвистик модельләрне төзүдә билгеле бер мәсьәләләрне хәл итү өчен «контекстуаль тулылык» принцибы нигезендә минималь күләмдәге чараларны билгели торган прагматик юнәлеш тәкъдим ителде. Нәтиҗәдә прагматик юнәлештәге лингвистик модельләрнең түбәндәге төрләре аерып чыгарылды:

1) контекстның эченә үтеп керергә, аны трансформацияләргә мөмкинлек биргән, лингвистик модельләрдән башка «контекст моделе» һәм «дөнья сурәте моделе» кебек экстралингвистик модельләрне дә кулланган семиотик модельләр;

2) автоматлаштырылган система белән кеше арасында табигый телдә аралашуны тәэмин иткән, үз эченә коммуникатив һәм контекстуаль модельләрне, минималь лингвистик информацияне алган интерактив модельләр;

3) текстларны телнең билгеле бер тармакларына караган формаль кагыйдәләр нигезендә максатчан эшкәртүне тәэмин иткән концептуаль-формаль модельләр;

4) табигый тел тармакларының мөһим берәмлекләренең универсаль тасвирламасын тәшкил иткән концептуаль-функциональ модельләр [Сулейманов, Гатиатуллин, 2003].

Әлеге классификация нигезендә татар теле корпусы телнең төрле тармакларының үзара тыгыз бәйләнгән концептуаль-функциональ модельләре комплексы буларак күзаллана. Ачык система буларак ул башка лингвистик модельләрне һәм алар белән бәйле автоматлаштырылган тамгалау системаларын да өстәргә мөмкинлек бирә. Ягъни корпус үз эчендә морфологик, синтаксик, семантик һ.б. модельләрне берләштерә.

Электрон корпусның информацион моделе үз эченә морфологик, синтаксик, семантик һ.б. лингвистик мәгълүматны ала. Әлеге мәгълүмат типлары үзара тыгыз бәйләнештә тора. Алар мәгълүматны автомат рәвештә эшкәртүне тәэмин итүче махсус формаль күрсәткечләр (тамгалау системалары) белән билгеләнә торган лингвистик параметрлар рәвешендә тәртипкә салынган. Лингвистик мәгълүмат параметрлары корпус берәмлекләрендә чагылыш таба.

Шуның белән бергә корпус моделе мәгълүматны эшкәртү системасыннан, үз эченә тамгаланган текстлар коллекциясен алган мәгълүмат базаларыннан һәм алар белән идарә итү системасыннан оешкан технологик схеманы тәшкил итә.

**2. Мәсьәләне хәл итү юлы буларак корпусның репрезентативлыгы.** Репрезентативлык, ягъни җитди лингвистик нигез, барлык корпусларның да мөһим

үзенчәлеге һәм аларны эшләүнең зарури шарты булып тора. Моңа ирешүнең дискурска, телнең яшәешенә яисә тел күренешләре төрлелеген, шул исәптән сирәк һәм пассив тел берәмлекләрен чагылдыруга юнәлтелгән төрле стратегияләре бар [Баранов, 2001; Шимкова, 2005].

Татар теле корпусына килгәндә, текстлар коллекциясе башлангыч этапта ук билгеле бер репрезентативлыкка ия булырга һәм нәтиҗәле тикшеренүләр үткәрү мөмкинлеге тудырырга тиеш. Бу мәсъәләне хәл итү текстларны аларда төрле тел күренешләренең, шул исәптән еш кулланылмый торган берәмлекләрнең дә урын алуын күз алдында тотып сайлаганда гына мөмкин. Моның өчен текстларны корпуска кертер алдыннан аларга җентекле статистик анализ үткәрү сорала.

Әлеге максатта безнең тарафтан гомуми күләме 600000 нән күбрәк сүз кулланылышы тәшкил иткән татарча текстларның эксперименталь коллекциясенең төрле квантитатив һәм лексик-грамматик параметрларының статистик үзенчәлекләре тикшерелде [Гильмуллин, Невзорова, Хакимов, 2011].

Тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, сүз төркемнәре барлык текстларда да нигездә бер үк кулланылыш ешлыгына ия. Җыелма текстта да аерымлык күзәтелми. Әлеге текстлар төрле күләмгә ия, алар ХХ гасыр дәвамында төрле вакытта язылганнар. Шул рәвешле түбәндәге таблицада чагылыш тапкан статистик параметрлар сәнгатьле проза стиле өчен хас булган «уртача нормалы» билгели торган константалар ролен үтиләр. Нәтиҗәдә конкрет текстларның статистик үзенчәлекләрендә бу константалардан читкә тайпылыш дәрәҗәсен билгеләргә мөмкинлек туа.

Мәсәлән, беренче текстта (Т. Галиуллин хикәяләре), бер яктан, исемнәрнең чагыштырмача югары, сыйфатларның түбән ешлыгы, ә икенче яктан, рәвеш, алмашлык һәм ярдәмлек сүз

*1 нче таблица*

Сүз төркемнәре статистикасы: сәнгатьле проза (%)

| | Исемнәр | Фигыльләр | Сыйфатлар | Рәвешләр | Алмашлыклар | Ярдәмлек сүз төркемнәре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Т. Галиуллин | 39,32 | 35,68 | 9, 85 | 1,52 | 7,4 | 6,22 |
| Г. Гыйльманов | 35,13 | 36,71 | 8,02 | 2,22 | 9,94 | 7,99 |
| Ә. Еники | 35,05 | 33,75 | 9,14 | 2,59 | 9,56 | 9,91 |
| Р. Зәйдулла | 35,6 | 37,08 | 7,86 | 2,33 | 9,27 | 7,86 |
| Г. Кутуй | 35,51 | 37,03 | 8,2 | 2,58 | 8,03 | 8,65 |
| Г. Бәширов | 34,8 | 35,76 | 8,83 | 2,93 | 9,58 | 8,1 |
| Ф. Әмирхан | 35,17 | 35,27 | 8,52 | 2,86 | 9,38 | 8,8 |
| Җыелма текст | 36,09 | 36,06 | 8,57 | 2,29 | 9 | 7,99 |

төркемнәренең аз очравы (2 нче таблица) әлеге текстта аерым тел конструкцияләренең үзенчәлекле кулланылышы турында сөйли. Ул, корпуска кертелгән очракта, төрлелекне арттыра һәм нигездә корпусның репрезентативлыгына да тәэсир итәргә тиеш.

Уку-укыту өлкәсенә караган текстларда шулай ук төрле мәгънәләргә ия булган аерым тенденцияләр күзәтелә. Биредәге мәгънә төрлелеге, безнең фикеребезчә, беренчедән, коллекциядә бу жанрдагы текстларның чагыштырмача аз санда булуы, икенчедән,

*2 нче таблица*

| | Исемнәр | Фигыльләр | Сыйфатлар | Рәвешләр | Алмашлыклар | Ярдәмлек сүз төркемнәре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Беренче текст | 36,67 | 32,17 | 12,43 | 1,37 | 6,2 | 8,16 |
| Икенче текст | 38,73 | 34,97 | 10,99 | 1,34 | 5,66 | 8,31 |
| Өченче текст | 41,75 | 39,4 | 9,15 | 0,88 | 3,17 | 5,65 |
| Җыелма текст | 39,74 | 34,81 | 11,17 | 1,26 | 5,34 | 7,69 |

*3 нче таблица*

Сүз төркемнәре статистикасы: газета текстлары (%)

| | Исемнәр | Фигыльләр | Сыйфатлар | Рәвешләр | Алмашлыклар | Ярдәмлек сүз төркемнәре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Беренче текст | 40,48 | 32,21 | 10,01 | 1,68 | 6,75 | 8,89 |
| Икенче текст | 45,3 | 30,26 | 10,36 | 1,34 | 5,44 | 7,3 |
| Җыелма текст | 42,47 | 31,4 | 10,16 | 1,54 | 6,2 | 8,23 |

*4 нче таблица*

Сүз төркемнәре статистикасы: жанрлар буенча җыелма мәгълүматлар (%)

| | Исемнәр | Фигыльләр | Сыйфатлар | Рәвешләр | Алмашлыклар | Ярдәмлек сүз төркемнәре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Сәнгатьле проза текстлары | 36,09 | 36,06 | 8,57 | 2,29 | 9 | 7,99 |
| Уку-укыту өлкәсенә караган текстлар | 39,74 | 34,81 | 11,17 | 1,26 | 5,34 | 7,69 |
| Газета текстлары | 42,47 | 31,4 | 10,16 | 1,54 | 6,2 | 8,23 |
| Җыелма текст | 38,51 | 35 | 10,02 | 1,71 | 6,91 | 7,86 |

аларның төрле «фәннилек» дәрәҗәсенә ия булуы һәм төрле предмет өлкәләренә каравы белән аңлатыла. Шуңа да карамастан, сәнгатьле проза белән чагыштырганда ачык күренеп торган номинативлык, сыйфатларның активлыгы һәм, киресенчә, алмашлыкларның пассивлыгы жанрның квантитатив маркерлары буларак хезмәт итәргә мөмкин.

3 нче таблицадан күренгәнчә, газета текстлары да аларга хас булган нормадан читкә тайпылышларны һәм тел төрлелеген билгеләргә мөмкинлек бирә торган аерым константаларга һәм жанр-стиль маркерларына ия.

Шул рәвешле, төрле функциональ кулланылышка ия һәм күләме чикләнгән текстлар корпусының репрезентативлыгына билгеле бер дәрәҗәдә аларның квантитатив һәм статистик үзенчәлекләрен анализлау нигезендә ирешергә мөмкин. Әлеге метод репрезентативлык параметрларының тагын да төгәлрәк классификациясен эшләү хисабына камилләштерелергә мөмкин.

**3. Татар теле корпусында морфологик тамгалау системасы.** Татар телендә сүзнең морфологик төзелешен аның агглютинатив табигате билгели: сүзформалар сүз ясагыч һәм сүз төрләндергеч аффиксларның нигезгә билгеле бер тәртиптә ялгануы нәтиҗәсендә ясалалар. Һәр грамматик мәгънә, кагыйдә буларак, аерым аффикс ярдәмендә белдерелә. Аффикслар даими, ягъни аерым сүз төркемнәренә караган барлык сүзләргә дә кушылалар. Шуңа бәйле рәвештә морфологияне формаль яктан күзаллау өчен аерым очракларда нигезләр сүзлегенә мөрәҗәгать итеп, аффикслар чылбырын анализлау сорала.

**3.1. Татар текстларын морфологик тамгалау моделе.** Татар теленең бүгенге көндә эшләнгән морфологик модельләре аның агглютинатив табигатен тасвирлаганда билгеле бер стандартларга нигезләнәләр [Suleymanov, Guilmoulline, Guilmoulline, 2000; Сулейманов, Гатиатуллин, 2003]. Татар теле корпусындагы текстларны морфологик тамгалауны автоматлаштыру лингвопроцессорлар тарафыннан кулланылган махсус программа чараларын булдыру юлы белән тормышка ашырыла. Аерым алганда, автоматлаштырылган морфологик тамгалау системасының үзәк компоненты буларак татар теленең ике катлы морфологик моделе нигезендә махсус җайлаштырып эшләнгән анализатор кулланыла [Гильмуллин, 2009; Хакимов, Гильмуллин, 2009].

Татар теле морфологиясенең әлеге моделе сүзформаны билгеле бер тәртиптә урнашкан ике катта чагылышлы аффикслар чылбыры буларак күзаллауга нигезләнә. Беренче («тышкы») катта аффикслар фонологик үзенчәлекләре белән, алломорфлар буларак тасвирланса, икенче, ягъни «эчке», катта шул алломорфларның гомумиләштерелгән берәмлеге, морфема буларак күрсәтелә. Мисал өчен, «эчке» катта морфотактика структурасында аерым билгеле урын алып торган *«-га»* аффиксы-морфемасы, «тышкы» катта *«-га, -гә, -ка, -кә, -а, -ә, -на, -нә»* аффикслары-алломорфлары

белән чагыла. Анализаторның эшчәнлеге фигыль һәм номинатив парадигмалар нигезендә корылган һәм сүз нигезе белән телдәге аффикслар арасындагы үзара бәйләнешләрне билгели торган морфотактик кагыйдәләр базасы нигезендә тормышка ашырыла [Гильмуллин, 2009].

Алга таба татарча текстта морфологик тамгалауны автоматлаштыру мөмкинлекләрен карап үтик. Татар телендәге сүз төркемнәренең грамматик үзенчәлекләре тел белеменә караган күпсанлы хезмәтләрдә тулы һәм җентекле рәвештә тасвирланган [Татарская грамматика, Т. II, 1993]. Аларны тану һәм автомат рәвештә тамгалау түбәндәге формаль күрсәткечләр нигезендә башкарылырга мөмкин:

I. Лексик-грамматик (семантик) төркемчәләрнең ачык күренеп торган формаль күрсәткечләре юк, ә кайберләренә хас булган формаль күрсәткечләр тотрыклы түгел. Шуңа өстәп, ирекле сүзформаның мондый структурасы турыдан-туры билгеле бер семантик төркем белән бәйләнмәгән.

II. Морфологик категорияләр исә, гадәттә, билгеле бер сүзформасын чагылдыра торган ачык формаль күрсәткечләргә ия.

Димәк, татар теленең морфологик үзенчәлекләре сүзформаның аффикслар составы автомат рәвештә анализланган вакытта чагыштырмача җиңел таныла-лар. Төрле сүз төркемнәренең лексик-грамматик (семантик) төркемчәләрен тану һәм автомат рәвештә тамгалау исә морфологик күрсәткечләр нигезендә генә хәл ителә алмый. Шул сәбәпле корпусны төзүнең башлангыч этабында морфологик тамгалау системасында эзлекле рәвештә билгеле бер аффикслар ярдәмендә белдерелгән грамматик категорияләр турындагы мәгълүмат кына урнаштырылырга мөмкин.

**3.2. Татар теле морфологиясендә тотрыксыз күренешләр.** Алга таба татар теленең тотрыклы табигатькә ия морфологиясендә урын алган гомум кагыйдәләрдән читкә тайпылыш очракларына һәм аларны текстларны автомат рәвештә тамгалау процессында эшкәртү мөмкинлекләренә тукталу сорала. Тел системасына мөнәсәбәттә бу күренешләрне ике төргә аерырга мөмкин: тышкы (системага карамаган) һәм эчке (системага бәйле) тайпылышлар.

1. Тышкы тайпылышларга ассимиляцияләнмәгән алынмалардагы морфологик үзгәрешләр һәм хәзерге татар орфографиясендәге җитешсезлекләр белән бәйле очраклар керә. Әлеге тайпылышларның төрләре Җ.Ш. Сөләймановның «Регулярность морфологии татарского языка и типы нарушений в языке» мәкаләсендә тасвирланган [Сулейманов, 1994]. Бүгенге көндә хәзерге татар орфографиясе һәм алынмаларны үзләштерү принциплары нигезендә бу төр сүзләрне автомат рәвештә эшкәртү мәсьәләсен хәл итү һәм алардагы үзгәрешләр белән бәйле закончалыкларны тасвирлау чараларын табу сорала.

2. Тышкы тайпылышлардан башка татар теленең морфологик системасында автомат рәвештә

танылырга мөмкин булган эчке тайпылышлар да урын ала. Әлеге тайпылышлар тел берәмлекләре өчен хас универсальлек, полифункциональлек, экономиялелек белән бәйле рәвештә барлыкка килеп, аларның системалы билгеләре саналалар һәм аерым эчке закончалыкларга буйсыналар.

Автомат рәвештә тамгалау вакытында аерым кыенлыкларны полифункциональ һәм омонимик аффикслар, «нуль» формалар, тиңдәш кисәкләр (аффикс аларның соңгысына гына кушылырга мөмкин), билгеле бер категория сүзләрнең, аерым алганда, кайбер алмашлык һәм бәйлек сүзләрнең, төрләнешендәге үзенчәлекләр тудырырга мөмкин.

**3.3. Татар теле корпусында морфологик мәгълүматны стандартлаштыру.** Табигый телне автомат рәвештә эшкәртү системасы өчен концептуаль һәм технологик стандартларны булдыру зур әһәмияткә ия. Татар теле корпусының морфологик стандарты мәгълүматны бертөрле итеп тәкъдим итәргә, морфологик аннотациянең теоретик нигезен оештырырга һәм үз эченә татар теленә хас булган теге яки бу морфологик күренешләрне, шул исәптән бәхәсле очракларны да, тасвирлау кагыйдәләрен алырга тиеш.

Морфологик мәгълүматны тәкъдим итү структурасына килгәндә, биредә лексемаларның кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләү һәм сүзформаларның морфологик үзенчәлекләрен аңлату белән бәйле бәхәсле мәсьәләләрне аерып чыгарырга мөмкин.

Татар грамматикасында сүз төркемнәрен тасвирлау өлкәсенә ике төп бәхәсле мәсьәлә хас. Беренчесе аффикслар алмаган хәлдә атрибутив функциядә килгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләү белән бәйле. Биредә аларны артык омонимия очракларын булдырмас өчен исем сүз төркеменә кертеп карау дөресрәк булыр иде.

Икенчесе күпкә катлаулырак һәм ул бер-берсен алыштырып килгән сүз төркемнәрен (сыйфатлар һәм рәвешләрне, исемнәр һәм сыйфатларны) аеру өлкәсенә карый. Мәсьәләне ике төрле юл белән чишәргә мөмкин: әлеге очракларны сүз төркемнәре омонимиясе итеп карап, сүзләрне контекст ярдәмендә аерырга яисә һәр лексеманы аерым тасвирларга. Ике юлның да, үз өстенлекләре булган кебек, кимчелекләре дә бар һәм алар аерым карауны сорый.

Татар теленең килешләр системасы белән бәйле мәсьәлә шулай ук катлаулы очраклардан санала. Соңгы тикшеренүләр аның хәзерге грамматик теория кысаларында тулаем хәл ителәалмавын күрсәтте [Сулейманов, 1996]. Сүзформаларның аффикслар составы белән бәйле рәвештә әлеге мәсьәләнең ике аспекты аерылып чыга: нуль форманың интерпретациясе һәм кайбер аффиксларның килеш категориясенә карата статусын билгеләү. Безнең фикеребезчә, биредә телнең табигате белән грамматик теория өлкәсендәге традицияләр арасындагы балансны саклау зарур. Мәсәлән, аффикслар алмаган формалар

барлык очракларда да «баш килеш» буларак күрсәтелергә, ә статуслары ахырга кадәр ачыкланып бетмәгән аффикслар шартлы рәвештә килеш парадигмасына кертелергә тиеш.

Тагын бер катлаулы очракны татар фигыле өчен хас юнәлеш категориясе, аерым алганда сүз төрләндергеч һәм сүз ясагыч функцияләрне башкара алган юнәлеш кушымчаларына хас үзенчәлекләр тәшкил итә. Нәтиҗәдә юнәлеш аффиксларын алган фигыльләрне леммалаштыру (нигезен билгеләү) мәсьәләсе туа. Бу очракта альтернатива булдыру сорала һәм нигез сыйфатында бердән артык фигыль формасы күрсәтелә ала. Әлеге алымны инфинитив формаларына карата да кулланырга мөмкин, чөнки биредә дә күп кенә очракларда төрлелек күзәтелә.

**3.4. Татар теле корпусында морфологик тамгалауның форматы.** Корпуста сүзформасы турындагы морфологик мәгълүмат гомуми планда ике төп «кырдан» оеша: 1) сүз төркеме буларак тасвирламасы; 2) морфологик билгеләр (параметрлар) тупланмасы.

Татар теле өчен хас морфотактика үзенчәлекләрен, бер яктан, катлаулы һәм гади, икенче яктан, мәҗбүри һәм факультатив параметрларга бүлеп карарга мөмкин. Катлаулы параметрлар берничә мәгънәгә ия булып, нинди дә булса грамматик категориягә карыйлар (мәсәлән, килеш кушымчалары системасы). Гади параметрлар исә бер генә мәгънәгә ия булырга мөмкиннәр (мәсәлән, *-мы* сорау формасы). Параметрның мәҗбүрилеге һәм факультативлыгына килгәндә, мәҗбүри параметр билгеле бер сүз төркеменең нинди дә булса сүзформасына карарга тиеш (мәсәлән, исемнәр һәрвакыт нинди дә булса килештә торалар, «килешсез» исем формалар юк). Факультатив параметр, аерым бер конкрет мәгънәдән башка, кире мәгънәне дә алырга мөмкин (мәсәлән, билгенең юклыгы – татар телендә исемнәр тартым мәгънәсен белдермәскә дә мөмкиннәр).

**Йомгак.** Татар теле корпусының концептуаль моделе һәм татар текстларын морфологик тамгалау системасы алга таба татар телендәге теләсә нинди текстның морфологик үзенчәлекләренең формаль тасвирламасын электрон машина укый ала торган форматта төзергә мөмкинлек бирә. Корпусны эшләүнең башлангыч этабында морфологик тамгалау системасында эзлекле рәвештә билгеле бер аффикслар ярдәмендә белдерелгән грамматик категорияләр турында мәгълүмат бирү белән чикләнү дә җитә. Автомат рәвештә тамгалау системасының нәтиҗәлелеге морфологик анализатор өчен өстәмә фонологик һәм морфотактик кагыйдәләр кертү юлы белән арттырылырга мөмкин.

Хәзерге вакытта түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өлкәсендә эш алып барыла:

1) корпус кысаларында сүзформаларын контекст эчендә анализлау чараларын эшләү;

2) полифункциональ, омонимик аффиксларның, «нуль» формаларның мәгънәләрен билгеләүдә, тиңдәш кисәкләрне та-

нуда автоматик чаралар куллану мөмкинлекләрен ачыклау һәм кагыйдәләрен эшләү;

3) гомум кагыйдәләргә буйсынмаган сүзләр, иң беренче чиратта алынмалар өчен фонологик һәм морфотактик кагыйдәләрне булдыру мөмкинлекләрен тикшерү;

4) төрле аффикс чылбырлары ешлыгын, бер төркемдәге лексемаларга башка парадигма аффиксларының ялгану очракларын корпуслы анализ юлы белән лингвопроцессорларны «өйрәтү» һәм лингвистик модельләргә төзәтмәләр кертү алымнарын һәм чараларын эшләү;

5) татар теле корпусының синтаксик һәм семантик модельләрен, алар белән бәйле тамгалау системаларын эшләү.

**Әдәбият**

*Баранов А.Н.* Проблема репрезентативности корпуса данных (на примере политической метафорики) // Труды международного семинара по комьютерной лингвистике и ее приложениям «Диалог-2001». Аксаково, 2001. Т. 2. С. 13–15.

*Бухараев Р.Г., Сулейманов Д.Ш.* К концепции внедрения татарского языка в компьютерные технологии // Татарский язык и новые информационные технологии. Сер.: Интеллект. Язык. Компьютер. Казань: Казан. гос. ун-т, 1995. Вып. 2. С. 8–19.

*Бухараев Р.Г., Сафиуллина Ф.С., Сулейманов Д.Ш. и др.* К концепции Машинного Фонда Республики Татарстан // Татарский язык и новые информационные технологии. Сер.: Интеллект. Язык. Компьютер. Казань: Казан. гос. ун-т, 1995. Вып. 2. С.20–35.

*Гильмуллин Р.А.* Разработка файла морфотактических правил для глагольных групп татарского языка // Проблемы сохранения языка и культуры в условиях глобализации: материалы VII Международного симпозиума «Языковые контакты Поволжья» / науч. ред. И.А. Гилязов. Казань: Казан. гос. ун- т, 2009. С. 222–226.

*Гильмуллин Р.А., Невзорова О.А., Хакимов Б.Э.* Корпус татарских текстов: проблема репрезентативности // Труды международной конференции «Корпусная лингвистика – 2011». СПб.: С.-Петербург. гос. ун-т, 2011. С. 125–130.

*Сулейманов Д.Ш.* Регулярность морфологии татарского языка и типы нарушений в языке // Когнитивная и компьютерная лингвистика / науч. ред. Р.Г. Бухараев и др. Казань: Казан. гос. ун-т, 1994. С. 77–106.

*Сулейманов Д.Ш.* К вопросу о числе татарских падежей // Исследования в лингвистике / науч. ред. Р.Г. Бухараев и др. Казань: Фэн, 1996. С. 70–84.

*Сулейманов Д.Ш., Гатиатуллин А.Р.* Структурно-функциональная компьютерная модель татарских морфем. Казань: Фэн, 2003. 220 с.

Татарская грамматика / ред. М.З. Закиев, Ф.А. Ганиев, К.З. Зиннатуллина. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. Т. II. Морфология. 397 с.

Татарский национальный корпус «Туган тел» [Электронный ресурс] http://tugantel.tatar, дата обращения: 25.03.2017.

*Хакимов Б.Э., Гильмуллин Р.А.* К разработке системы параметров морфологической разметки для электронного корпуса татарских текстов // Труды Казанской школы-семинара по компьютерной и когнитивной лингвистике TEL–2008. Казань: Казан. гос. ун-т, 2009. С. 24–29.

*Шимкова М.* Репрезентативность корпуса как лингвистическая проблема // Труды международной конференции «MegaLing – 2005». СПб.: Изд-во «Осипов», 2005. С. 130–139.

*Suleymanov D.Sh., Guilmoulline R.A., Guilmoulline A.A.* Tatar phonological rules as a base of two-level morphological analyzer // Proceedings of LP'2000. Prague: The Karolinum Press, 2000. P. 495–504.

***Сөләйманов Җәүдәт Шәүкәт улы,***
*техник фәннәр докторы, профессор,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы,*
*ТР ФА Гамәли семиотика институты директоры*

***Хәкимов Булат Эрнст улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты Лев Толстой исемендәге*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының*
*белем бирү технологияләре һәм филологиядә*
*мәгълүмати системалар кафедрасы доценты*

***Гыйльмуллин Ринат Абрек улы,***
*физика-математика фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Гамәли семиотика институтының*
*когнитив тикшеренүләр бүлеге мөдире*

УДК 811.512.145'373:811.111

***И.Г. Әхмәтҗанов,***
***А.К. Гәрәева***

# ТАТАР ҺӘМ ИНГЛИЗ ТЕЛЛӘРЕНДӘ ДЕНДРОНИМНАР НИГЕЗЕНДӘ ЯСАЛГАН ТОПОНИМНАР

Статья посвящена сравнительно-сопоставительному анализу географических названий, образованных на основе дендронимов в татарском и английском языках. В частности, в ней рассматриваются вопросы классификации топонимов, определения общих принципов их образования и выявления основных лексико-семантических групп данных наименований в указанных языках. Для этого авторами используются сравнительно-сопоставительный, описательный методы исследования.

**Ключевые слова:** топонимика, топонимия, топонимы, дендронимы, классификация, сравнительно-сопоставительный метод, описательный метод, татарский язык, английский язык.

Мәгълүм булганча, кешелек җәмгыятендә тел, катлаулы һәм шул ук вакытта яхшы оешкан система буларак, төрле вазыйфалар башкара, ләкин иң беренче чиратта ул аралашу һәм мәгълүмат алмашу чарасы санала. Бүгенге көндә Җир шарында кулланыла торган телләрдә, аларның һәрберсе өчен генә хас үзенчәлекләр белән бергә, гомуми сыйфатларның булуы да күзәтелә. Әлеге билгеләрне татар һәм инглиз телләре кебек генетик яктан бер-берсе белән бәйләнмәгән телләрдә дә табарга мөмкин [Хисамова, с. 3].

Аерым телләрдәге уртак күренешләрне өйрәнүне максат итеп куйган типологик тикшеренүләр бүгенге тел белемендә мөһим һәм перспектив юнәлешләрнең берсен тәшкил итә. Алар үзара тугандаш булмаган һәм төрле структурага ия булган, шул исәптән аз өйрәнелгән телләрнең дә материалын җәлеп итеп, гомумлингвистик мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкинлек бирәләр [Сулейбанова, с. 41; Шайхуллин, с. 233].

Фәнни эшнең актуальлеге нәкъ менә югарыда әйтелгәннәр белән билгеләнә. Аның кысаларында татар һәм инглиз телләрендә дендронимнар нигезендә барлыкка килгән географик атамаларның лексик-семантик үзенчәлекләрен чагыштырма планда өйрәнү һәм шуның нигезендә аларның ясалыш принципларын, төп лексик-семантик төркемнәрен ачыклау максат итеп куелды. Бу үз чиратында «1) атамалар этимологиясен дөрес аңлатырга; 2) бүгенге көндә сирәк яисә бөтенләй кулланылмый торган, топонимик лексикада гына сакланып калган борынгы һәм искергән сүзләрне өйрәнеп, аларның мәгънәләрен торгызырга; 3) географик атамаларның барлыкка килү закончалыкларын

аңлатырга; 4) әлеге атамалар барлыкка килгән чорда халыкның мәдәни үсеш дәрәҗәсен, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирәчәк» [Гарипова, с. 22–23].

Дендронимнар, ягъни агач исемнәре, телнең иң борынгы лексик катламнарын тәшкил итәләр. Шуңа бәйле рәвештә бу сүзләр нигезендә ясалган топонимнарны фәнни яктан өйрәнү зур әһәмияткә ия. Аерым алганда, аларда кешенең табигатьне күзаллавы, аңа мөнәсәбәте һәм шуның белән бергә табигый объектлар, үсемлекләр дөньясы турында бай мәгълүмат чагылыш таба.

Семантик яктан географик атамалар күпкырлы һәм катлаулы күренеш тәшкил итәләр. А.В. Суперанская фикеренчә, топонимның семантикасында атама бирелгән объект, сөйләүченең объектка карата мөнәсәбәте, топонимның нигезен тәшкил иткән апеллятивның мәгънәсе һәм сөйләм вакытында әлеге сүзгә мөнәсәбәттә барлыкка килә торган ассоциацияләр турында мәгълүмат чагылыш таба. Шуңа бәйле рәвештә географик атаманың мәгънәсен аңлау өчен ул кулланылган типик ситуацияләрне белү кирәк [Суперанская, с. 322].

Бүгенге көндә дендронимнар нигезендә барлыкка килгән топонимнар чагыштырма планда башкорт һәм немец телләре материалы нигезендә А.Р. Хисматова тарафыннан өйрәнелгән. Галим атамаларның бер төркемнән икенчесенә күчешен (дендроним > гидроним / ороним > ойконим) өйрәнеп, әлеге процессның катлаулы һәм берничә баскычтан торган күренеш тәшкил иткәнлеген ачыклый [Хисматова, с. 12].

Тикшеренү кысаларында без бу төр атамаларны түбәндәге төп өч төркемгә аердык:

1. Җир өслегендәге агач-куаклыклар белән капланган мәйданнарның атамалары нигезендә барлыкка килгән топонимнар.

2. Ылыслы агачларның атамалары нигезендә барлыкка килгән топонимнар.

3. Яфраклы агачларның атамалары нигезендә барлыкка килгән топонимнар.

Тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, беренче төркем топонимнар арасында татар телендә *урман*, инглиз телендә *wood* ‘агачлык’, *forest* ‘урман’ һәм *hurst* ‘урман белән капланган калкулык’ апеллятивлары нигезендә барлыкка килгән атамалар еш очрый. Мәсәлән:

а) татар топонимиясендә:

*Урман – Яшел Үзән районындагы поселок;*

*Урманасты – Бөгелмә һәм Лениногорск районнарындагы поселоклар;*

*Урманасты Үтәмеш – Чирмешән районындагы авыл;*

*Урманасты Йорткүл – Спас районындагы авыл;*

*Урман Зәе – Көнчыгыш Кама аръягы төбәгендәге елга;*

*Урман күле – Кама Тамагы районы Олы Кариле авылында;*

*Урманай – Азнакай районындагы авыл;*

*Урмандәй –Аксубай районындагы авыл;*

*Урман күле – Идел алды, Көнбатыш Кама алды, Көнбатыш Кама аръягы төбәкләрендәге күлләр;*

*Урман Чишмәсе – Көнчыгыш Кама аръягы төбәгендәге елга;*

*Урманчы – Мамадыш районындагы авыл һ.б.;*

б) инглиз топонимиясендә:

*Forest and Frith – Дарем (Durhат) шәһәрендәге аучылык хуҗалыгы;*

*Forest Hill with Shotover – Оксфордшир (Oxfordshire) графлыгындагы урман белән капланган калкулык;*

*Woodthorpe – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Hazelwood – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Hurst – Дорсет (Dorset) графлыгындагы шәһәр һ.б.*

Икенче төркем топонимнар татар телендә генә очрыйлар, инглиз теле өчен алар хас түгел. Алар нигездә *нарат* һәм *чыршы* дендронимнары нигезендә барлыкка килгәннәр. Мәсәлән:

*Бикнарат – Биектау районындагы авыл;*

*Ишнарат – Арча районындагы авыл;*

*Нарат – Яшел Үзән районындагы поселок;*

*Наратасты – Сарман һәм Мөслим районнарындагы авыллар;*

*Наратасты урманы – Мөслим районы Наратасты авылы янындагы табигать тыюлыгы;*

*Наратлы – Идел алды төбәгендәге күл;*

*Наратлы – Көнчыгыш Кама аръягы төбәгендәге елга;*

*Наратлы – Әлмәт һәм Бөгелмә районнарындагы авыллар;*

*Наратлык – Арча һәм Биектау районнарындагы авыллар;*

*Наратлыкичү – Минзәлә районындагы авыл;*

*Наратъелга – Чистай районындагы авыл;*

*Югары Наратбаш – Буа районындагы авыл;*

*Түбән Чыршылы – Лениногорск һәм Сарман районнарындагы авыллар;*

*Чыршы – Алабуга һәм Биектау районнарындагы авыллар;*

*Чыршылы – Тукай районындагы авыл;*

*Чыршылы Елга – Балык Бистәсе районындагы авыл;*

*Югары Чыршылы – Лениногорск һәм Сарман районнарындагы авыллар;*

*Яңа Чыршылы – Лениногорск районындагы поселок һ.б.*

Татар һәм инглиз телләрендә яфраклы агачларның атамалары нигезендә барлыкка топонимнар да еш очрый. Татар топонимиясе өчен, нигездә, структураларында *каен, тал* һәм *юкә* дендронимнары урын алган атамалар хас. Мәсәлән:

*Каенлы – Түбән Кама районындагы авыл;*

*Каенлык – Актаныш, Буа һәм Кукмара районнарындагы авыллар;*

*Каенсаз – Мөслим районындагы авыл;*

*Каенсар – Арча, Әтнә, Балтач һәм Кукмара районнарындагы авыллар;*

*Кыр Каентүбә – Актаныш районындагы авыл;*

*Шикәрле Каен – Минзәлә районындагы авыл;*

*Каратал – Кама Тамагы районындагы авыл;*

*Таллыбүләк – Азнакай һәм Бөгелмә районнарындагы авыллар;*

*Таллыкүл – Баулы районындагы авыл;*

*Юкәле – Әлмәт районындагы авыл;*

*Юкәче – Мамадыш районындагы авыл һәм Көнбатыш Идел алды төбәгендәге елга h.б.*

Әлеге дендронимнар (*birch tree* ‘каен’, *willow tree* ‘тал’, *lime tree, linden* ‘юкә’) нигезендә барлыкка килгән топонимнар инглиз телендә дә теркәлде. Мәсәлән:

*Birchanger – Эссекс (Essex) графлыгындагы шәһәр;*

*Birches – Честер (Cheshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Birchdale – Ланкашир (Lancashire) графлыгындагы торак пункт;*

*Willington – Честер (Cheshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Willey – Шропшир (Stropshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Willenhall – Стаффордшир (Staffordshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Willitoft – Йоркшир (Yorkshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Lindhurst – Ноттингемшир (Nottinghamshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Limehouse – Зур Лондон (Greater London) административ берәмлегендәге торак пункт;*

*Linby – Ноттингемшир (Nottinghamshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Lindale – Камбрия (Cumbria) графлыгындагы шәһәр h.б.*

Шуның бергә инглиз топонимиясе өчен, татар топонимиясеннән аермалы буларак, *beech tree* ‘бүк агачы’, *elm tree* ‘карама’, *maple tree* ‘өрәңге’, *alder* ‘зирек’, *aspen tree* ‘усак’, *ash tree* ‘корычагач’ һәм *poplar* ‘тирәк’ дендронимнары нигезендә барлыкка килгән топонимнар да хас:

*Beech hill – Беркшир (Berkshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Beech – Стаффордшир (Staffordshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Elm – Кембриджшир (Cambridgeshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Elmton – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Elmsted – Кент (Kent) графлыгындагы торак пункт;*

*Elmore – Глостершир (Gloucestershire) графлыгындагы шәһәр;*

*Mapleton – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Mapperley – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Mappleborough – Уорикшир (Warwickshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Mappleton – Йоркшир (Yorkshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Alderley – Глостершир (Gloucestershire) графлыгындагы шәһәр;*

*Aldershot – Гэмпшир (Hampshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Alderwasley – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы торак пункт;*

*Aspley Heath – Бедфордшир (Bedfordshire) графлыгындагы торак пункт;*

*Aspenden – Хартфордшир (Hertfordshire) графлыгындагы торак пункт;*

*Aspull – Ланкашир (Lancashire) графлыгындагы шәһәр;*

*Ashover – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Ashton – Честер (Cheshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Ashfield – Саффолк (Suffolk) графлыгындагы шәһәр;*

*Ashcott – Сосерсет (Somerset) графлыгындагы торак пунк;*

*Poplar – Зур Лондон (Greater London) административ берәмлегендәге торак пункт һ.б.*

Йомгаклап әйткәндә, татар һәм инглиз топонимик системаларында аерым үзенчәлекләр белән бергә уртак күренешләр дә күзәтелә. Шуның белән бергә бирелә табигатьнең аерылгысыз өлешен тәшкил иткән агачларның әлеге халыкларның көнкүрешендә нинди урын алып торганлыгы да чагылыш таба.

**Әдәбият**

*Гарипова Ф.Г.* Татарская гидронимия (вопросы этногенеза татарского народа по данным гидронимии). Книга первая. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 1998. 572 с.

*Сулейбанова М.У.* Типология словообразовательных систем нахских и иноструктурных языков // Вестник Пятигорского государственного лингвистического университета. 2009. №1. С. 41–45.

*Суперанская А.В.* Что такое топонимика. СПб.: Авалон: Азбука-классика, 2009. 256 с.

*Хисамова В.Н.* Глагольная система татарского и английского языков: сопоставительный анализ в аспекте изучения английского языка на базе родного (татарского) языка (переработанное). Казань: Зур Казан, 2015. 328 с.

*Хисматова А.Р.* Дендронимы в башкирском и немецком языках: дис. … канд. филол. наук. Уфа, 2005. 145 с.

*Шайхуллин Т.А.* Языковая репрезентация отношений между родственниками в русских и арабских паремиях // Вестник ТГГПУ. 2011. № 4(26). С. 233–38.

***Әхмәтҗанов Илдар Габдрәшит улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтының*
*Халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чит телләрне*
*өйрәнү кафедрасы доценты*

***Гәрәева Альмира Кадыйр кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтының*
*Халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чит телләрне*
*өйрәнү кафедрасы доценты*

УДК 811.512.145'271

***Н.В. Максимов***

# СӨЙЛӘМ: АБСТРАКТ ҺӘМ КОНКРЕТ ТӨШЕНЧӘЛӘР

В статье рассматривается технология обучения татарскому языку как неродному. Обосновывается целесообразность обучения на синтаксической основе.

Выделение синтагматической модели речи в качестве основы обучения неродной речи позволяет акцентировать внимание обучаемого на алгоритме построения словосочетаний и предложений. Опора на алгоритмы помогает обучаемому варьировать стабильными синтаксическими конструкциями в процессе создания текста-основы и выстраивания диалога.

**Ключевые слова:** татарский язык, технология обучения языку как неродному, синтагматическая модель речи, алгоритм построения словосочетаний и предложений, синтаксические конструкции.

Җирдә яшәүче һәр халыкның мең еллар дәвамында буыннар аша аңына табигый рәвештә салынган, сеңдерелгән үзенчәлекле яңгырашлы һәм язылышлы, тирә-яктагы әйберләргә, гамәлләргә, күренешләргә һ.б.га үзенчә мәгънә салып аталган үз сүзләреннән, үзенә генә хас аһәңле әйтелешле, үзара ярашлы һәм үзенә генә хас эзлеклелектәге фикерләү рәвешенә корылган үз җөмлә калыпларыннан төзелгән *нигез теле – ана теле – сөйләмә теле* бар. Бу – беренчедән. Икенчедән, дөньядагы күпчелек телләрнең гасырлар дәвамында махсус фән белгечләре тарафыннан өйрәнелгән һәм төзелгән, кайтып-кайтып тулыландырылган һәм камилләштерелгән, рәсми кабул ителгән фәнни грамматикалары һәм аларда тупланган кагыйдәләр нигезендә барлыкка килгән *әдәби сөйләм теле* бар.

Математика терминнарын кулланып аңлатсак, ***гади сөйләм теле*** – бала өчен – *арифметика* дәрәҗәсе (*кушу, алу, тапкырлау, бүлү* гамәлләре); ***әдәби сөйләм теле*** – *алгебра* (*кушу, алу, тапкырлау, бүлү гамәлләрендә кулланылган саннарның зурлыкларын хәрефләр һәм саннар ярдәмендә бирелгән күләмдә аңлата белү*) һәм *геометрия* (*пространстводагы җисемнәрнең формасын, күләмен һ.б. формулаларда нигезләп таба һәм исбатлый белү*) дәрәҗәсе.

Илдә яки дөньяда яшәгән халыкның күпчелеге өйдә яки көндәлек тормышта, нигездә, *кушу* һәм *алу, тапкырлау* һәм *бүлү* гамәлләрен генә кулланып эш итә. Бик аз өлеше генә – махсус тармак белгечләре генә – көндәлек тормышта яки эш урынында алгебра һәм геометрия өлкәсенә караган терминнарны һәм гамәлләрне кулланып аралаша.

Сөйләмдә дә шулай: халыкның сөйләү һәм аралашу теле сорау һәм җавап сүзләргә нигезләнеп формалаша. Сөйләгәндә һәм сөйләшкәндә (аралашканда) бирәү дә, шул исәптән тел белгечләре үзләре дә, сөйләменең логик-грамматик (структур-семантик) төзелеше турында уйламый – сорау сүзенең

эчтәлегенә һәм формасына яраклаштырып, җавап сүзен әйтә. Бу очракта җавап сүз урынында, нигездә, кайсыдыр сүз төркеменә караган мөстәкыйль мәгънәле бер генә сүз дә, гади җөмләнең баш яки иярчен кисәге дә; иярчен җөмләле кушма җөмләләрнең баш җөмләсе дә, иярчен аналитик һәм синтетик формалары да; катлаулы төзелмәләрнең баш һәм иярчен җөмлә булган компонентлары да кулланылырга мөмкин.

Бала, мәктәптә укый башлаганчы, тел белеме фәненә кагылышы булган бер генә кагыйдәне белмәсә дә, өйдә әнисенә һәм әтисенә, әбисенә һәм бабасына – олыларга ияреп, белгән кадәрле сүз байлыгыннан һәм хәтерендә калган сорау һәм җавап белдерүче җөмлә калыпларыннан файдаланып, күргәне яки кемнәндер ишеткәннәре турында сөйләргә (*монолог-хикәя* төзергә) һәм шулар хакында, үз фикерен белдереп яки яклап, аралашырга (*диалогта* катнашырга) өйрәнә. Бу – баланың «Тел белеме» дигән фәннең иң гади сүзләр һәм җөмләләр белән бәйле үзенчәлекле төп гамәлләрен белү дәрәҗәсе.

Мәктәптә башлангыч сыйныфларда укый башлагач исә, балага «Тел белеме» дигән фәннең катлаулырак гамәлләрен, «Методика» дигән фән белән шөгыльләнүче галимнәр аңлатканча, сыйныфтан сыйныфка «гадидән катлаулырак эзлеклелектә» махсус әзерләнгән тел белгече – укытучы өйрәтә башлый. Нәтиҗәдә бала, акрынлап, өендә олылар белән аралашып, 4–5 ел дәвамында сорау һәм җавап сүзләр, сорау һәм җавап җөмләләр ярдәмендә сөйләшеп күнегелгән табигый сөйләм теленнән ераклаштырылып, фәнни терминнар һәм кагыйдәләргә нигезләнеп төзелгән логик-грамматик төшенчәләрне, аларның үзлекләрен өйрәнү теленә – үзе өчен ясалма сөйләшү телен өйрәнүгә күчерелә.

Шулай итеп, бала аңы өчен берсе икенчесе белән бөтенләй бәйләнеше булмаган ике төркем гомумиләштерү барлыкка килә: беренче төркемдә реаль чынбарлыкта булган предметлар; аларның төренә, эшенә төрле билгеләренә карап, халык тарафыннан мең еллар элек бирелгән атамалары (предмет = сүз, гамәл = сүз, сан = сүз, билге = сүз һ.б.) һәм шул предметларга, атамаларга карата гомумиләштереп кулланылган, сөйләмдә эчтәлекне бирү өчен кирәкле конкрет мәгънә белдерүче ***сорау*** һәм ***җавап сүзләр***; икенче төркемдә исә бала аңы өчен чынбарлык белән бәйләнеше бөтенләй булмаган, ләкин сөйләмнең логик-грамматик (структур-семантик) төзелеше өчен бик кирәк булган абстракт төшенчәләр: мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәре, модаль сүз төркемнәре; сүзтезмәләр, җөмләләр, җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре; тезмә кушма җөмләләр, синтетик һәм аналитик иярчен җөмләле кушма җөмләләр; катлаулы төзелмәләр; тыныш билгеләре, теркәгечләр, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр; төрле сызыклардан, парлы җәяләрдән, турыпочмаклыклардан һәм тыныш билгеләреннән торган схемалар туплана. Таблицада аларның бер өлешен, гомумиләштереп, түбәндәгечә күрсәтеп булыр иде:

| **Сүз** | | **Логик-грамматик** | |
|---|---|---|---|
| ***сорау*** | ***җавап*** | ***морфологик*** | ***синтаксик*** |
| **сүзләр** | | **кисәкләр** | |
| кем | мин, син, ул | *мөст. сүз төрк.* | *гади җөмлә* |
| | без, сез, алар | исем | |
| | кеше, бала | сыйфат | *баш кисәкләр* |
| нәрсә | күбәләк, куян | сан | ия, хәбәр |
| | алма, кишер | рәвеш | *тыныш билгеләре* |
| | китап, дәфтәр | алмашлык | |
| кайсы | бу, теге, ул | фигыль | *иярчен кисәкләр* |
| нинди | матур, кызыл | аваз ияртемнәре | аергыч |
| ничә | бер, унбер | | тәмамлык |
| ничек | тиз, салмак | *ярдәмлек сүз төрк.* | хәлләр |
| | утырып, көлеп | бәйлек, бәйлек сүз. | аныклагыч |
| | җәяү | теркәгечләр | |
| кайчан | бүген, иртәгә | | *кушма җөмлә* |
| | җәен, кышын | *модаль сүз төрк.* | тезмә кушма җөмлә |
| кая | авылга, шәһәргә | кисәкчәләр | синтетик, аналитик |
| | мәктәпкә, паркка | кереш сүзләр | иярчен җөмлә |
| нәрсәдә | машинада | эндәш сүзләр | катлаулы төзелмә |
| нишлә | чык, бар, кер | ымлыклар | текст |

Кеше, бала вакытта тәпи киткәч тә, гомере буе йөри: туган яки торган җиреннән башлап хәрәкәт итә, ягъни кая да булса **бара** – кайдан да булса **кайта**, **килә – китә**, **чыга** – **керә**, **менә** – **төшә**. Җөмлә кисәкләренең логик-грамматик бүленеше ягыннан караганда, без бу сүзләрне җөмләдә, **хәбәр** буларак, гадәттә түбәндәгечә билгелибез: 1) җөмләдә ия турында хәбәр итә һәм аңа грамматик буйсына торган кисәк; 2) фигыль хәбәр; 3) гади фигыль хәбәр. Ләкин хәрәкәтне белдерүче бу сүзләрнең җөмләдә хәбәр булуы да; хәбәр буларак, санап үтелгән билгеләренең дә татар телендә сөйләүче һәм үзара сөйләшүче кешеләр өчен әллә ни әһәмияте юк, тагын да ачыграк итеп әйтсәк, сөйләүче һәм аралашучы кеше өчен бу мәгълүматларны белү кирәк тә түгел.

Кемне дә булса (баланымы, мәктәп укучысынмы, олы кешеneme – яшь үзенчәлекләренә карамастан) татар телендә сөйләшергә өйрәтүчегә һәм татар телендә сөйләшергә үзлегеннән өйрәнүчегә, беренче чиратта: 1) бу сүзләрнең лексик мәгънәсен – *хәрәкәтне* белдерүен; 2) бу сүзләр ярдәмендә сөйләмдә *вакыт* төшенчәсенең – хәрәкәтнең сөйләү яки сөйләшү вакытына туры килүен, сөйләү яки сөйләшү вакытыннан соң үтәлүен, сөйләү яки сөйләшү вакытына кадәр булуы турындагы грамматик мәгънәләрнең белдерелүен; 3) бары тик бу сүзләрдә генә сөйләмдә катнашучы затларның – I һәм II затның – махсус кушымчалар ярдәмендә белдерелүен; бу сүзләр нәкъ менә шул кушымчалар ярдәмендә сөйләүче (мин) һәм тыңлаучы (син) зат белән берлектә һәм күплектә ярашуын бүлү һәм аңлау кирәк.

| **Кем**?<br>*кто*? | **Нишлим**?<br>*что делаю*? | **Нишлибез**?<br>*что делаем*? | **Нишләде**?<br>*что сделал*? | **Нишләмәде**?<br>*что сделали*? |
|---|---|---|---|---|
| **I**<br>**Мин** | бара**м** | бармый**м** | барды**м** | бармады**м** |
| **Без** | бара**быз** | бармый**быз** | барды**к** | бармады**к** |
| **II**<br>**Син** | бара**сың**? | бармый**сың**? | барды**ң**?<br>баргансың | бармады**ң**?<br>бармагансың |
| | бара**сың**мы? | бармый**сың**мы? | барды**ң**мы? | бармады**ң**мы? |
| | бар | барма | | |
| **Сез** | бара**сыз**? | бармый**сыз**? | барды**гыз**?<br>баргансыз | бармады**гыз**?<br>бармаган**сыз** |
| | бара**сыз**мы? | бармый**сыз**мы? | барды**гыз**мы? | бармады**гыз-**<br>мы? |
| | бар**ыгыз** | барма**гыз** | | |

Сөйләм конкрет һәм абстракт мәгънә белдерүче лексик материал, башта – җыйнак, соңрак җәенке җөмлә калыплары ярдәмендә генә сөйләм предметы турындагы темага нигезләнеп оеша; һәм, сөйләм оешсын өчен, беренче чиратта, **сөйләүче** – I зат – сөйләмдә конкрет яки абстракт мәгънә белдерүче предмет турында башкаларга яңалык әйтүче, яңа хәбәрне җиткерүче кеше кирәк. Сөйләүче генә сөйләмнең логик-грамматик (структур-семантик) нигезен төзи ала. Бары ул гына чынбарлыктагы җанлы һәм җансыз предметларны күрә, алар турында, аларга хас үзенчәлекле билгеләр турында кемгәдер (тыңлаучыларына) нәрсә дә булса хәбәр итә, яңалык әйтә ала. Башкалар да күрергә мөмкин, ләкин әйтә алмый. Алай гына да түгел, ул гына башка кешеләр әйткән фикергә үз мөнәсәбәтен белдерә ала: тыңлаучыларының – II һәм III затларның – чынбарлыктагы җанлы һәм җансыз предметларны ни рәвештә кабул итеп, күргәннәре турында тагын да башка тыңлаучыларга хәбәр итү, яңалык буларак әйтү рәвешен, эмоциональ халәтен дә ул гына сөйли ала; ул гына, башкаларның фикерен белергә теләсә, аларга сорау бирә ала.

**Сөйләүче** булмаса, 3 этаптан торган һәм бер-берсенә эзлекле бәйләнгән сөйләм буыннары үзара ялгана алмый, ягъни, беренчедән, сөйләмнең темасы билгеләнә алмый; икенчедән, сөйләүченең монолог – хикәясе төзелә алмый; өченчедән, димәк, I һәм II зат; I, II, III затлар арасында кара-каршы сөйләшү булсын өчен – диалог оешсын өчен, нигез (башлангыч) текст төзелә алмый; дүртенчедән, сөйләшүләр булмагач, сөйләшүнең эчтәлеге турында кемнеңдер (мәсәлән, булган хәл турында ишетеп

кенә белүчеләрнең) кемгәдер нәрсәдер сөйләү мөмкинлеге була алмый.

Мисал өчен, өч дус – Марат (I зат), Саша (II зат), Гүзәл (III зат) арасында 3 этапта барган сөйләшүнең эчтәлегенә һәм оештырылу формасына, ягъни сөйләм синтаксисының оешу үзенчәлегенә игътибар итик.

**1 нче этап**

**I затның (сөйләүченең) монолог-хикәясе:**

*Мин барам! Мин* ***кая*** *бараммы?! Мин* ***мәктәпкә*** *барам. Мин мәктәпкә* ***кем белән*** *бараммы?! Мин мәктәпкә* ***әнием белән*** *барам. Мин мәктәпкә* ***кайчан*** *бараммы?! Мин мәктәпкә* ***бүген иртән*** *барам. Әйе, мин мәктәпкә бүген иртән әнием белән барам.*

**2 нче этап**

**I (мин) һәм II зат (син) арасында кара-каршы сөйләшү (диалог):**

*– Марат, мин мәктәпкә барам. Әйт әле, син* ***кая*** *барасың?*

*– Саша, беләсең килсә – әйтәм: мин дә* ***мәктәпкә*** *барам. Мин мәктәпкә әнием белән барам, ә син, дустым, кем белән барасың?*

*– Мин* ***кем белән*** *бараммы?! Марат, беләсең килсә, мин дә* ***әнием белән*** *барам. Иртән барам. Әйт әле, Марат, син мәктәпкә* ***кайчан*** *барасың?*

*– Шулаймыни?! Иртән барасыңмыни?! Мин мәктәпкә* ***төштән соң*** *барам, беләсең килсә!*

**3 нче этап**

**I (мин), II зат (син), III зат (ул) арасында кара-каршы сөйләшү (диалог):**

*– Саша, мин дә мәктәпкә барам, син дә мәктәпкә барасың. Сора әле, Гүзәл мәктәпкә барамы?*

*– Гүзәл, әйт әле, син бүген мәктәпкә барасыңмы?*

*– Саша, беләсең килсә – әйтәм: мин дә мәктәпкә барам.*

*– Марат, Гүзәл дә бүген мәктәпкә бара икән.*

*– Саша, мин дә мәктәпкә әнием белән барам, син дә мәктәпкә әниең белән барасың. Сора әле, Гүзәл бүген мәктәпкә әнисе белән барамы?*

*– Гүзәл, әйт әле, син бүген мәктәпкә кем белән барасың?*

*– Саша, мин бүген мәктәпкә кем белән бараммы?! Дустым, беләсең килсә, мин бүген мәктәпкә әбием белән барам.*

*– Марат, Гүзәл бүген мәктәпкә әбисе белән бара икән.*

*– Саша, сора әле, Гүзәл мәктәпкә төшкә кадәр барамы, әллә төштән соң барамы?*

*– Гүзәл, әйт әле, син мәктәпкә төшкә кадәр барасыңмы, әллә төштән соң барасыңмы?*

*– Саша, мин бүген мәктәпкә төштән соң барам, чөнки төшкә кадәр бассейнга барам.*

*– Марат, Гүзәл бүген мәктәпкә төштән соң бара икән, чөнки төшкә кадәр бассейнга бара.*

*– Димәк, мин мәктәпкә бүген иртән барам; син, Саша, төштән соң барасың; Гүзәл дә төштән соң бара. Мин әнием белән барам, син дә әниең белән барасың, ә Гүзәл әбисе белән бара.*

Сөйләм калыбында III зат, әгәр аңа I зат турыдан-туры мөрәҗәгать итмәсә, сөйләмдә

бөтенләй катнаштырылмый, шул сәбәпле ул I затка – сөйләр, I һәм II затка, үзара сөйләшү өчен, билгеле яки билгеле булмаган кайсыдыр бер яки берничә объект (мәсәлән: I яки II затка караган *кешеләр: әнием, әтиең, апаң* һ.б.; җанлы һәм җансыз предметлар: *урман, табигать, кибет, агач, сандугач, аю, су анасы, шүрәле* һ.б.) ролен генә үти, шуңа күрә сөйләмдә ул зат еш кына үзе дә абстракт мәгънә генә белдерә, конкрет мәгънә белдерсен өчен, үзен аныклауны таләп итә. Бу вазыйфаны да сөйләмдә, нигездә, сөйләүче генә башкара ала.

**Әдәбият**


*Закиев М.З.* Татарская грамматика. Т. 3. Синтаксис. Казан: Таткнигоиздат, 1995. 576 б.

*Максимов Н.В.* Словосочетания как основа обучения неродному языку // Вестник КГТУ, Т. 16. № 7. 2013. С. 325–328.

*Максимов Н.В.* Сөйләм калыбы – гади җөмлә. Казань: Изд-во РИО ГБУ «РЦМКО», 2013. С. 286–294.

*Максимов Н.В.* Сөйләм калыбы өч этапта формалаша // Сохранение и развитие родных языков в условиях многонацио-нального государства: проблемы и перспективы. V Междуна-родная научно-практическая конференция, 19–22 ноября 2014 г. Казань: Отчество, 2014. С. 180–183.

*Максимов Н.В.* Сөйләм калыбы ул – сөйләмгә өйрәтүнең нигезе // Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы. Материалы региональной научно-практической конференции, посвящённой 190 летию со дня рождения Каюма Насыри. Казань, 2015. С. 139–147.

*Максимов Н.В.* Сөйләшергә өйрәтү формуласы. Казан: Мәгариф. Татар теле. 2016. № 1. 42 б.

*Максимов Н.В.* Телгә өйрәтү технологиясе // Фәнни Татарстан. 2014. № 3. С. 106–112.

*Максимов Н.В.* Технология обучения татарскому языку на основе моделей речи. (На русском и татарском языках). Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 255 с.

*Сафиуллина Ф.С.* Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Хәтер, 2001. 432 б.



***Максимов Николай Валентинович,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар тел белеме кафедрасы доценты*

УДК 811.512.145

***Б.К. Миңнуллин***

# ГОМУММИЛЛИ ТЕЛНЕҢ ЯШӘЕШ ФОРМАСЫ БУЛАРАК ӘДӘБИ ТЕЛ ҺӘМ АНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ СТИЛЬЛӘРЕ

В статье рассматриваются вопросы научного изучения функциональных стилей. По мнению некоторых ученых-языковедов функционально-стилистическая система современных развитых языков состоит в среднем из пяти функциональных стилей. Другие же ситают, что в языке, кроме разговорного, научного, официально-делового, публицистического и художественных стилей, выделяются еще обиходно-деловой, официально-документальный, церковно-религиозный стили. Существует также мнение о том, что выделение художественного и публицистического стилей в качестве самостоятельных является неверным.

**Ключевые слова:** литературный язык, функциональные стили, разговорный стиль, научный стиль, официально-деловой стиль, публицистический стиль, художественный стиль.

Тел белемендә функциональ стильләрне өйрәнү күптәннән алып барылса да, функциональ стилистика аерым фән тармагы буларак узган гасырның урталарында оеша. Аның фәнни-теоретик нигезләре А.М. Пешковский, Л.В. Щерба, Г.О. Винокур, В.В. Виноградов, Х.Р. Курбатов, В.Х. Хаков, И.Б. Бәширова, Ф.С. Сәфиуллина һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә чагылыш таба.

XX гасыр урталарында телдә алты функциональ стиль – көндәлек-көнкүреш, көндәлек-эш, рәсми-документаль, фәнни, газета-публицистик һәм әдәби стильләр булуын күздә тота торган бүленеш киң тарала [Виноградов, 1963, с. 5–93]. Галимнәрнең бер өлеше әлеге бүленештә әдәби стиль урын алырга тиеш түгел дигән караштa торса, икенче төркем исә публицистик стильгә каршы чыга. Алар фикеренчә, вакытлы матбугатта басыла торган материаллар арасында башка стильләрнең характерлы сыйфатларын үз эченә алган текстлар да очрый, шуннлыктан теге яки бу стилистик сыйфатка ия булган текстларны кайсы стильгә каратып өйрәнергә дигән сорау туа. Аерым галимнәр исә, телдә функциональ стильләр белән бергә алар эчендә подстильләрне дә аерып чыгарырга тәкъдим итәләр.

1954 елда «Вопросы языкознания» («Тел белеме мәсьәләре») журналында танылган рус галиме Ю.С. Сорокин тарафыннан стилистикага караган мәсьәләләр турында фикер алышу башлап җибәрелә. 1955 елда «Итоги обсуждения вопросов стилистики» («Стилистика мәсьәләләре белән бәйле фикер алышуның нәтиҗәләре») дип аталган мәкаләсендә В.В. Виноградов әлеге фикер алышу барлык мәсьәләләрне дә чишәргә ярдәм итмәде, ләкин фәнни җәмәгатьчелек алдында күп кенә

файдалы сораулар куйды дигән нәтиҗә ясый.

Әлеге чарада XX гасырның әйдәп баручы телче галимнәреннән барысы да диярлек катнаша. Алар арасында Г.В. Степанов, Р.А. Будагов, И.Р. Гальперин, В.Д. Левин һ.б. галимнәрне атарга була. Бүгенге көн күзлегеннән чыгып караганда, ул, һичшиксез, уңай нәтиҗәләргә китерә. Мәсәлән, аның барышында В.В. Виноградов тарафыннан «стиль» төшенчәсенә билгеләмә бирелә, стильләрнең тарихилыгы, аларның күптөрлелеге һәм үзара мөнәсәбәте белән бәйле мәсьәләләр куела, стилистикадагы яңа юнәлешләр, аерым алганда функциональ стилистика турындагы фикерләр яңгырый. Шул рәвешле, журналдагы фикер алышуның нәтиҗәсе буларак, узган гасырның 60нчы елларында рус тел белемендә функциональ стилистика белән шөгыльләнүче бер төркем тел галимнәренең фәнни хезмәтләре дөнья күрә. Алар арасында А.Н. Васильева, Т.Г. Винокур, Б.Н. Головин, М.Н. Кожина, В.Г. Костомаров, Э.Г. Ризель һ.б. хезмәтләрен атап китәргә була.

Югарыда әйтелеп киткәнчә, кайбер галимнәр, телнең функциональ-стилистик бүленешен тагы да төгәлрәк формага китереп, стильләр эчендә подстильләрне аерып карарга тәкъдим итәләр. Мәсәлән, И.Р. Гальперин публицистик стильне ике подстильгә – газета һәм публицистика подстильләренә бүлеп карый [Гальперин, 1958, с. 383]. Газета подстиленә ул газета мәкаләсен (баш мәкаләләр, критик мәкаләләр, фельетоннар, күзәтүләр) һәм газета хәбәрен (заметка) кертә. Публицистик стильдә исә журнал мәкаләләрен, эссе һәм оратор сөйләмен аера. Күренгәнчә, И.Р. Гальперин биредә тел стильләрен түгел, ә жанрларны алгы планга чыгара.

В.Д. Бондалетов, С.С. Вартапетова кебек галимнәрнең фикеренчә, функциональ стиль – ике яклы күренеш. Ул иҗтимагый тормышның төрле өлкәләренә караган максат һәм бурычлар нигезендә барлыкка килә, ләкин шул ук вакытта ул лингвистик табигатькә ия [Бондалетов, Вартапетова ..., с. 22]. Шуңа бәйле рәвештә функциональ стильләрнең бүленеше гадәттә ике – экстралингвистик һәм лингвистик нигездә тормышка ашырыла. Бер төркем галимнәр телнең функциональ стильләрен өйрәнгәндә иң элек аралашу өлкәсенә, аралашу эчтәлегенең типологик үзенчәлекләренә, иҗтимагый аң формасына, фикерләү төренә һ.б. игътибар итәләр. Башка галимнәр шулай ук экстралингвистик факторларның мөһимлеген кире какмыйлар, ләкин тикшеренү барышында күбрәк лингвистик күрсәткечләргә – стилистик чараларга, типик стилистик сыйфатларны өйрәнүгә басым ясыйлар.

Башка галимнәр стильне нормалар системасы буларак билгелиләр. Мәсәлән, В.В. Виноградов фикеренчә, әдәби стиль – ул социаль группа яки мөстәкыйль әдәби шәхескә караган сөйләм һәм әдәби зәвык нормаларының системасы [Виноградов, 1982, с. 12–13]. Д.Н. Шмелев фикеренчә исә, без телдә булган стильләрне, аларны кулланырга

өйрәнгәннән соң, баш тартырга мөмкин булган аерым бер нормалар системасы буларак кабул итәбез [Шмелев, с. 46].

Аерым галимнәр стильне форма белән тәңгәл дип табалар. Иң мөһиме – форма турында сүз йөрткәндә тышкы калып турында гына түгел, ә бәлки эчке закончалык һәм бизәлешне дә аңларга кирәк. Телдәге стильләрне өйрәнгәндә эчтәлеккә күбрәк игътибар бирүче галимнәрнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә исә тарихи, дидактик, рәсми стильләр аерылып чыгарыла [Хуринов, с. 43].

Стиль белән стилистик чараларны тәңгәлләштерү тарафдарлары булган галимнәр фикеренчә, теге яки бу стилистик элемент кайсыдыр бер стильнең характерлы үзенчәлеге булып саналырга тиеш. Мәсәлән Л.В. Щерба әдәби стильгә каршы рәсми стильне куя (1957), ә А.Н. Гвоздев рәсми һәм фәнни стильләрне бер төркемгә берләштерә (1965).

Гомумән алганда рус телендә өчтән алып җидегә кадәр функциональ стиль булганлыгы билгеләнә [Рахманин, с. 10; Андреев, с. 128]. Төрле галимнәр тарафыннан тәкъдим ителгән функциональ-стилистик бүленешләрдәге стильләрнең исемнәре дә аерылып торырга мөмкин. В.В. Виноградов тәкъдим иткән бүленештә, югарыда әйтелеп киткәнчә, алты стиль аерылып чыгарыла. Шул ук вакытта, әлеге алты стиль арасындагы көндәлек-эш һәм рәсми-документаль стильләрне берләштереп карау тенденциясе бар [Гальперин, 1981; Кожина, 1977]. Рус тел белемендә тагын бер стиль – дини стильне аерып чыгаручы галимнәр дә бар [Кожина, 2008, с. 285]. Татар тел белемендә И.Б. Бәширова дини-дидактик стильне шулай ук мөстәкыйль стиль буларак аерып чыгару ягында [Бәширова, с. 20–25].

Сөйләмә стиль көндәлек сөйләмдә кулланыла, ләкин аерым очракларда ул язма формаларда да чагылыш таба, мәсәлән, шәхси хатларда. Сөйләмә стиль аралашу функциясен үти, автор рәсми булмаган сөйләшү вакытында әйләнә-тирәдәгеләргә үзенең уй-фикерләрен җиткерә, көндәлек мәсьәләләр буенча фикер алыша. Әлеге сөйләшү барышында гадәттә гади сөйләм лексикасы кулланыла. Сөйләмә стиль диалог, шәхси хатлар, телефоннан сөйләшү кебек жанрларда актив кулланыла.

Фәнни стиль – иҗтимагый үзаңның бер формасы булган фән белән тыгыз бәйләнештә тора. Фәнни текстлар берничә төркемгә бүленә. Алар арасында иң киң таралганнары – махсус (профессиональ публикага юнәлдерелгән) һәм фәнни-популяр (төрле катлам укучылар өчен) текстлар. Әлеге стильнең максаты – фән өлкәсенә караган күренешләрне һәм законнарны аңлату, ачышларны тасвирлап бирү, өйрәтү һ.б. Фәнни стиль гадәттә фәнни мәкалә, дәреслек, монография кебек жанрларда язма монологик формада чагылыш таба.

Рәсми-эш стиле сәяси, дипломатик, коммерция, юридик һ.б. характердагы документларда урын ала. Әлеге документларның текстларына императивлык, төгәллек, стандарт лексик

формалар һәм терминнарның кулланылуы, эмоцияләрнең урын алмавы хас. Рәсми стильнең төп функциясе – хәбәр итү, ә төп яшәеш формасы – язма форма. Бу – мәгълүматны документлаштыру зарурлыгы белән бәйле.

Публицистик стиль аралашу һәм тәэсир итү функцияләренә ия булуы белән аерылып тора. Публицистик текстлар халыкка язма яки сөйләмә формадагы мәгълүмат чаралары аша җиткерелә, аларның язма формалары гадәттә мәкалә, очерк, репортаж, фельетон, интервью жанрларында чагылыш җаба. Функциональ-стилистик күзлектән чыгып караганда, үзенең күпкырлы максат-бурычларына бәйле рәвештә, публицистик стиль иң катлаулы стильләрдән санала.

Әдәби стиль матур әдәбият жанрларында чагылыш таба. Ул телнең барлык лексик байлыгын, башка стильләрнең мөмкинлекләрен файдаланып, авторның фикер һәм тойгыларын укучыга җиткереп, аңа йогынты ясый. Л.Ю. Максимов, Н.М. Шанский, Д.Н. Шмелев кебек галимнәр фикеренчә, әдәби стильдә башка стиль үзенчәлекләре зур урын алып тора, шул сәбәпле әдәби стильне мөстәкыйль стиль буларак аерып чыгару дөрес булмый. Алар фикеренчә, әдәби тел кысаларында, бернинди дә стильгә бәйләп карамыйча, мөстәкыйль бер күренеш – «әдәби әсәр теле»н аерып чыгару дөресрәк була. Башка бер төркем галимнәр (В.В. Виноградов, А.И. Ефимова, Р.А. Будагов) исә әдәби әсәрләр телен аерым стиль буларак кабул итәләр һәм аны «эстетик-коммуникатив стиль» дип атыйлар.

Шулай итеп, функциональ стилистика рус тел белеменең мөстәкыйль тармагы буларак XX гасырның 50 нче елларында барлыкка килә. Соңрак рус тел белеме казанышларына нигезләнеп, татар теленең функциональ-стилистик бүленеше дә өйрәнелә башлый. Кайбер галимнәр фикеренчә, бүгенге көндә алга киткән телләрнең функциональ-стилистик системасы, нигездә, биш стильдән оеша. Шул ук вакытта сөйләмә, фәнни, рәсми-эш, публицистик һәм әдәби стильләр белән бергә көндәлек-эш, рәсми-документаль һәм дини стильләрне аерып чыгаручы галимнәр дә бар. Аерым галимнәр исә телнең функциональ-стилистик системасына әдәби һәм публицистик стильләрне кертеп карамау яклы. Шул рәвешле, функциональ стилистика өлкәсендә бүгенге көндә дә ачыкланып бетмәгән мәсьәләләр кала бирә.

## Әдәбият

*Андреев Н.Д.* Статистико-комбинаторные методы в теоретическом и прикладном языкознании. Л.: Наука, 1967. 404 с.

*Бондалетов В.Д., Вартапетова С.С., Кушлина Э.Н., Леонова Н.А.* Стилистика русского языка. Л.: Просвещение, 1982. 286 с.

*Бәширова И.Б.* Татар стилистикасының теоретик нигезләре. Казан, 2005. 30 б.

*Виноградов В.В.* Стилистика. Теория поэтической речи. Поэтика. М.: АН СССР, 1963. 256 с.

*Виноградов В.В.* Очерки по истории русского литературного языка XII–XIX веков. М.: Высшая школа, 1982. 528 с.

*Гальперин И.Р.* Очерки по стилистике английского языка. М.: Издательство литературы на иностранных языках, 1958. 462 с.

*Гальперин И.Р.* Текст как объект лингвистического исследования. М.: Наука, 1981. 140 с.

*Кожина М.Н.* Стилистика русского языка. М.: Просвещение, 1977. 223с.

*Кожина М.Н., Дускаева Л.Р., Салимовский В.А.* Стилистика русского языка. М.: Флинта: Наука, 2008. 464 с.

*Рахманин Л.В.* Стилистика деловой речи и редактирование служебных документов. М.: Высшая школа, 1997. 239 с.

*Хуринов В.В.* Функционально-стилистическая дифференциация англоязычных научных и газетно-публицистических текстов (на мат. англ. языка): дис. … канд. филол. наук. Москва, 2009. 272 с.

*Шмелев Д.Н.* Русский язык в его функциональных разновидностях. М.: Наука, 1977. 168 с.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителде*

***Миңнуллин Бәхтияр Ким улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге мөдире*

УДК 811.512.145

***И.Ф. Миргалимов***

# ТАТАР ДӨНЬЯ КАРТИНАСЫНДА ПРОСТРАНСТВОНЫ ГОРИЗОНТАЛЬ ЯССЫЛЫКТА КҮЗАЛЛАУ МОДЕЛЬЛӘРЕ

Каждый народ имеет свой метод познания пространства и комплекса представлений о его устройстве и космогонии. Многие народы приходят к пониманию данной категории в связи с первобытными представлениями о природных явлениях. В статье анализируются представления пространства у татар в горизонтальном устройстве мироздания.

**Ключевые слова:** горизонтальная плоскость, татарская языковая картина мира, концепт, пространство, модель мира.

Табигый ки, һәр мәдәниятнең үзенә генә хас кыйммәтләр системасы була. Алар арасында гореф-гадәтләр, традицияләр, йолалар, кешенең үз-үзен тоту рәвеше стереотиплары, дөньяны күзаллау белән бәйләнгән кыйммәтләр аеруча мөһим.

«Дөнья моделе», «дөнья картинасы», «дөнья тел сурәте», «концепт» һ.б. терминнар рус тел белемендә XX гасырның 60 нчы елларында ук, ә татар тел белемендә XX гасырның 80–90 нчы елларында гына яктыртыла башлый. Дөнья картинасы – кеше һәм тел, кеше һәм әйләнә-тирә мөнәсәбәтенең чагылышы, Г.А. Брутян билгеләвенчә, берничә буын эшчәнлеге нәтиҗәсе булып тора. Тел ярдәмендә традицияләр, еллар буе тупланган тәҗрибә киләчәк буынга тапшырыла [Брутян, с. 42].

Дөнья моделен иҗат итүнең үзенчәлекле милли ысуллары бар. Халык дөньяны нинди күз белән күрсә, аның аңында шундый дөнья төзелеше формалаша. Бу – әлеге халыкның яшәешне ни рәвешле итеп күрүен аңлатуы һәм ул дөньяның милли образын тәшкил итүе [Сибгаева, б. 123].

Соңгы вакытта тюркологиядә дөньяны тел чаралары ярдәмендә сурәтләү мәсьәләләрен өйрәнүгә игътибар арта башлады. 2006 елда Ә.Р. Тенишев редакциясендә төрки халыкларның дөнья картинасы модельләренә багышланган хезмәт басылып чыкты. Бу хезмәттә авторлар, төрки халыкларның дөнья моделенә вертикаль һәм горизонталь яссылыклар хас, дип язалар [СИГТЯ, с. 326].

Җиһан без яшәгән Җир өсте дөньясы белән генә чикләнми: анда башка – икенче, хәтта өченче дөньялар да бар икән. Шулай булгач, аларда гомер итүче затлар да төрле-төрле булырга тиеш. Җирдә булмаган һәм һич тә була алмаган күренешләрнең, затларның барысы да Җир асты яки Су асты патшалыкларында була. Тулаем алганда, бу патшалыклар, бу дөньялар билгеле бер

дәрәҗәдә Җир өсте патшалыгының киресен гәүдәләндерәләр [Урманче, б. 20–21].

Төркиләргә хас булган кебек үк, татарлар өчен дә дөнья вертикаль һәм горизонталь яссылыкта күзаллана. Вертикаль моделе өч өлештән торса (күк – җир – җир асты), горизонталь дөнья исә дүртпочмаклы яссылыктан гыйбарәт (дөнья яклары – аның дүрт почмагы, уң – сул, ал – арт).

Татар дөнья картинасында пространствоның *горизонталь яссылыгы* ал – арт (ян – як), киң – тар модельләрендә чагылыш таба.

1) *ал – арт, ян – як* моделе.

*Ал – арт, ян – як* пространствоны горизонталь яссылыкта характерлый торган берәмлекләр булып исәпләнәләр. Иң элек бу сүзләргә аңлатма биреп китик.

Аңлатмалы сүзлектә пространство белән бәйле *ал* сүзенә түбәндәге аңлатма бирелә: күз караган як; *киресе* арт [ТТАС, б. 32]; *арт* сүзенә: күз караган якка капма-каршы як [ТТАС, б. 48]; *ян*: нәрсәнең дә булса уң яки сул ягы // янга урнашкан, ян-якка урнашкан, яндагы [ТТАС, б. 732].

Р. Харис икътисад, сәүдә якларыннан үсеш һәм яңарыш кичергән, алдынгы цивилизацияле дәүләтләрне *алга* киткән дәүләтләр дип атый:

*Үз-үземә туа үтенеч:*
***алга кара*** *– тормыш* ***алда*** *гына,*
***ян-як*** *– гыйбрәт,* ***артта*** *–*
*үкенеч...*
(«Тормыш алда гына»)

Р. Харис бу шигырендә пространствоны горизонталь яссылыкта характерлый торган сүзләр ярдәмендә тормышка бәя бирергә тырыша. Тормышның үткәне күңелдә үкенеч калдыра, кешегә тәҗрибә, гыйбрәт өсти. *Алда* кешене киләчәге көтә. Үткәнне автор *арт,* киләчәкне *ал* дип атый. Ул *алга кара* гомумтел фразеологик берәмлеге аша киләчәк белән яшәү мәгънәсен җиткерә:

*Без дигәнчә бармый тормыш-сыер:*
***Алга кусаң – артка борыла...***
(«Тормыш-сыер»)

Әлеге шигырендә авторның тормыш турындагы күзаллавы пространствоны горизонталь яссылыкта характерлый торган *ал – арт* берәмлекләре белән җиткерелә.

Алдагы мисалда шагыйрь лирик геройның хис-кичерешләрен табигать күренеше белән параллель тасвирлый. Ул бу очракта да пространствоны горизонталь яссылыкта характерлый торган *арт* сүзенә мөрәҗәгать итә:

*Кояш бата зәңгәр* ***тау артына...***
*Яшел алан моңга күмелә...*
*Сагынудан шашам бугай инде –*
*Син кайларда хәзер?*
(«Кояш бата зәңгәр
тау артына...»)

Зөлфәт *алда* лексик берәмлеген лирик геройның киләчәк, алдагы тормышка карата булган якты өметләрен тасвирлаганда куллана:

Ә безнең бит – яшиселәр **алда**
Еллар ямьле, юллар күңелле!
Еласак та, көлсәк-елмайсак та,
Ашыктырмыйк әле күңелне...
(«Таң җилендә кипсен
керфекләр...»)

Нәтиҗә ясап әйтсәк, *ал – арт, ян – як* модельләре пространствоны горизонталь яссылыкта сурәтләгәндә, төп вазифаларыннан тыш, поэзиядә фәлсәфи төшенчәләрне, күзаллауларны җиткерү өчен ачкыч сүз буларак та кулланылалар.

2) *киң – тар* моделе.

*Киң* 1) буйга, озынлыкка сузылган яссылыклар, өслекләр, мәйданнар турында. Иңе чагыштырмача зур; 2) зур араларга җәелгән, җәенке; 3) *сөйл.* иркен; күләмле; 4) зур; 5) *күч.* чикләнмәгән, мул; тулы, юмарт [ТТАС, б. 261].

*Тар* – 1. *сф.* 1) иңе чагыштырмача зур булмаган, киң түгел; 2) сыю, сыйдыру, үтәли узу кыен булган (*һәртөрле ачыклыклар, аралыклар тур.*); 3) таманыннан яисә гадәттәгедән ныграк тәнгә ятып тора торган (*кием-салым тур.*); 4) кысан, уңайсыз; 5) *күч.* колачсыз, масштабсыз, кимчелекле; 6) *күч.* эгоистик, көнчелекле; хөсетле, хөсетчән; 2. *рәв. мәгъ. күч.* берьяклы рәвештә, бер яктан гына; 3. *хәб. сүз.* аз, кысан (*мөмкинлекләр, сәмән һ. б. тур.*); аз, ашыгыч (*вакыт тур.*) [ТТАС, б. 516].

Г. Зәйнашева «Менәргә иде Урал тауларына» җырында пространствоны киңлектә сурәтли. Лирик герой илен *киң* итеп күрә. Аның Урал тауларына менеп, *киң илен* нурга күмеп таң атканын күрәсе килә:

*Каршыларга иде **киң илемне,***
*Нурга күмеп таңнар атканын*
(«Менәргә иде Урал тауларына»).

Авторның «Сөембикә» исемле шигъри монологы тарихны яктырта. Шагыйрь дошманнарның Казан ханлыгын яулап алып, олуг һәм *киң* булган илне җимереп, яндырып, халкын кол итүләре турында яза. Ул Сөембикә исеменнән сөйли, әсәр структур яктан ханбикә монологына корылган:

*Илем-йортым олуг иде,*
*Олуг иде, **киң** иде*
(«Сөембикә»).

Зөлфәт «Язмышлар ярында» шигырендә төп мәгънәне яшереп бирә. Мөмкинчелек, яшәү шартлары туры килмәү, күңел тарлыгы мәгънәләрен *урамым тар булган* индивидуаль автор фразеологизмы белән җиткерә:

Артык зур булгандыр бәхетең,
*Я минем **урамым тар булган***
(Зөлфәт).

Шул рәвешчә, татар шигъриятендә шагыйрьләр пространствоны киңлектә, киң итеп сурәтлиләр. Шуның белән бергә *киң – тар* сүзләре индивидуаль автор фразеологизмнары составында да мул кулланыла.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, пространство яки урын-ара ул, иң беренче чиратта, безне чолгап алган дөнья, галәм, яшәеш, барлык, тереклек. Ягъни ул – киңлек; җир, урын; аралык, бушлык; мәйдан; материя яшәешенең төп объектив формаларның берсе; ачык урын, ачыклык; фәлсәфи төшенчә; *ал, арт, өс, ян* һ.б.

**Әдәбият**

*Брутян Г.А.* Язык и картина мира // Философские науки. 1973. № 1. С. 108–119.

*Сибгаева Ф.Р.* Пространство в картине мира поэтической фразеологии татарского языка // Ученые записки Казанского университета. Серия: Гуманитарные науки. 2008. Т. 150. № 8. С. 123–127.

СИГТЯ – Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика / под ред. Э.Р. Тенишева. М.: Наука, 2001. 986 с.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты. 2005. 849 б.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек: өч томда. 2 т. Казан: Мәгариф, 2009. 343 б.

***Миргалимов Илдар Флүс улы,***
*Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары*
*E-mail: ildarfm.kazan@gmail.com*

УДК 821.512.145:784

***И.М. Газиев***

# ГРАММОФОН ЯЗМАЛАРЫНДА ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕ

Статья посвящена истории создания граммофонных записей произведений Г. Тукая в начале XX века; поиску и выявлению этих записей, хранению и введению их в научный оборот.

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, граммофонные записи произведений Г. Тукая, «Пате», «Граммофон», «Русское Акционерное Общество Граммофонов».

Миңа «Тукай энциклопедиясе» өчен Тукай һәм татар музыкасы темасына караган мәкаләләрнең бер өлешен язу бәхете насыйп булды. Энциклопедиянең баш мөхәррире хөрмәтле Зөфәр әфәнде Рәмиев мөрәҗәгатен кабул итеп, мин бик зур теләк һәм җаваплылык белән бу эшкә керештем. Язылган мәкаләләр Г. Тукайның замандашлары – музыкантлар һәм җырчылар турында. Бу очраклы хәл түгел дип уйлыйм, чөнки минем гыйльми эзләнүләрем XX гасыр башындагы татар музыкасы мәдәниятенә карый. Инде байтак еллар мин шул чорның музыкаль мохитен өйрәнү өстендә эшлим. Бу эзләнүләренең нәтиҗәсе төрле гыйльми мәкаләләрдә, телевизион музыкаль фильмнарда, концерт программаларында чагылыш тапты. Әйтик, Татарстан – Яңа Гасыр телерадиокомпаниясе «И. Газиев тәкъдим итә...» дип аталган телевизион музыкаль фильмнар циклында Г. Тукайның иҗатына багышланган «Ишеттем мин кичә берәү җырлый...» дип аталган фильм төшерде. Мин анда сценарий авторы, алып баручы һәм музыкаль номерларны – Г. Тукай яраткан халык җырларын, аның шигырьләренә җырланылган халык җырларын башкаручы сыйфатында чыгыш ясадым. Ә инде «Татар җыры – йөз ел элек» дип аталган фильмда мин тамашачыларны Г. Тукай чорындагы җыр сәнгатенең торышы белән таныштырдым. XX гасыр башында үзләренең эшчәнлеген алып барган җырчыларның һәм музыкантларның репертуарын реконструкцияләү өлкәсендә дә шактый гына эш башкарылды һәм әлеге вакытта да бу эш дәвам итә.

Җитди музыка өлкәсендә күренекле татар композиторы А. Монасыйпов махсус минем өчен «Тукай аһәңнәре» вокал-симфоник поэмасының икенче редакциясен язды. Бу әсәрне мин төрле оркестрларга кушылып берничә тапкыр Казанда башкардым, шулай ук аны Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург, Уфа шәһәрләренең музыка сөючеләренә дә тәкъдим иттем. Шунысын әйтә алам: озак еллар буена Г. Тукайның шигърияте минем иҗатымның төп юнәлешен билгеләп килде.

Гыйльми өлкәдә дә Г. Тукайның тормышын һәм иҗатын

өйрәнү алгы планда тора. Тәкъдим ителәчәк эшемдә Г. Тукай мирасының үзенчәлекле бер өлешенә – шагыйрь әсәрләренең аның замандашлары – җырчылар, артистлар тарафыннан граммофон тәлинкәләренә теркәлгән язмаларга тукталып китәм. «Тукай энциклопедиясе»ндәге «Граммофон язмаларында Тукай әсәрләре» дип исемләнгән мәкаләдә дә сүз шул мирас турында бара.

XX гасыр башында үзенчәлекле киңкүләм мәгълүмат чарасы ролен үтәгән граммофон Россиянең күп төбәкләрендә яшәгән татарларга, башка язмалар белән беррәттән, шагыйрьнең әсәрләре язылган тәлинкәләрне җиткерде, Г. Тукайның дөнья күргән китап һәм җыентыклары белән бергә аның иҗатын тирәнрәк өйрәнү мөмкинлеген бирде.

Төрле чыганаклар өстендә эшләү вакытында шунысы ачыкланды: Г. Тукайның әсәрләре Россия территориясендә үзенең эшчәнлекләрен алып барган «Пате», «Граммофон», «Зонофон», «Лирофон», «Метрополь-рекорд», «Русское Акционерное Общество Граммофонов» (РАОГ) ширкәтләре тарафыннан чыгарыла.

Эзләнүләр барышында миндә бер сорау туды: Г. Тукайның әсәрләрен граммофон тәлинкәләренә беренчеләрдән булып кемнәр яздырган соң? Кайсы ширкәттә, кайсы шәһәрдә, ничәнче елны яздырганнар? Шуны ачыклау юлында төрле чыганакларга мөрәҗәгать итәргә туры килде. Алар – традицион басма чыганаклар (газета-журналлар, җыр җыентыклары, каталоглар), традицион булмаган чыганаклар (граммофон тәлинкәләрендәге, «Пате» дискларындагы язмалар, тәлинкәләрнең этикеткалары). Күренекле инглиз дискографы, үзенең 60 елга якын гомерен «Граммофон» ширкәтенең архивларын өйрәнүгә багышлаган Алан Келли (1928–2015) әфәндедәнең миңа тапшырган «Көнчыгыш каталогы» кулъязмасы эзләнүләрдә аеруча ярдәм итте [The Gramophone Company…]. Бу каталогта татар җырчылары, музыкантлары һәм артистлары башкаруында 500 гә якын язма булуы ачыкланды. Әлбәттә, төп чыганак – ул сакланып калган граммофон язмалары. Кайчакта, ярылган, сынган-чатнаган, гасыр тузаны кунган тәлинкәләрне уйнаткычта әйләнер хәлгә китергәннән соң, андагы кыштырдау аша 10–15 секунд кына булса да яңгыраган җырны, көй һәм тавышны эләктереп алу безнең өчен бигрәк тә әһәмиятле. Чөнки бу авазлар, бу фон – XX гасыр башы, Г. Тукай чоры аһәңнәре.

Кайбер басма чыганакларда шагыйрьнең әсәрләре теркәлгән граммофон язмаларының дөньяга чыгуы Г. Тукайның вафатыннан файдаланган коммерсантларның эшчәнлеге белән бәйле булуына ишарәләү күренсә дә [Фридерик, с. 85], язмаларның хронологиясен билгеләү барышында шунысы ачыкланды: Тукай үзе исән чакта ук аның әсәрләре граммофон тәлинкәләренә яздырылган була. 1913 елда шагыйрьнең үлеменнән соң бер ай үтмәс борын тәлинкәләр сатылуга куелган икән, бу – граммофон ширкәтләре тарафыннан инде элегрәк

язылган фонограммаларга даими рәвештә кайтып, аларның тиражларын кабатлауны аңлата. Ул гына да түгел, граммофондагы язмалар Г. Тукайның 1906–1909 еллар арасында иҗат иткән әсәрләрен үз эченә ала.

А. Келлиның «Көнчыгыш каталогы»ндагы мәгълүмат буенча Г. Тукай әсәрләренең иң беренче граммофон язмасы 1908 елның февраль аенда дөнья күрә. «Зонофон» ширкәте Мәскәүдә узган тавыш язу сессиясендә Г. Тукайның 1906 елда иҗат иткән «Татар кызларына. Сөям дә, сөймим дә...» дигән шигырен музыкант, актёр, режиссёр Ильяс бәк Кудашев-Ашказарский башкаруында яздыра. Күптән түгел бу язма теркәлгән тәлинкәне мин Татарстанның Милли музее фондында табып алдым.

Г. Тукайның укытучысы һәм остазы, татар халкының беренче профессиональ җырчыларыннан булган Камил Мотыйгыйның (Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин, 1883–1941) граммофон өлкәсендәге эшләре бик нәтиҗәле була. Танылган җырчы Г. Тукай сүзләренә иҗат ителгән җырларны әдәби-музыкаль кичәләрдә, үзенең аерым концертларында гына башкарып калмый, ул аларны граммофон тәлинкәләренә дә яздыра. Г. Тукайның шигырьләре аша К. Мотыйгый үзенең җырларында мәхәббәт темасын яңгырата, кыюлык белән үз чорына хас булган социаль темаларны күтәрә, җырлары аша байлыкка, ялганлыкка каршы чыга, татар милләтенең киләчәге турындагы борчылуларын алгы планга куя. К. Мотыйгыйның Г. Тукай шигырьләренә башкарган җырларының беренче язмалары «Зонофон» ширкәтенең Мәскәүдәге студиясендә 1910 елның 7 сентябрендә тормышка аша. Фортепианога кушылып җырчы граммофон тәлинкәләренә «Тотса мәскәүләр якаң», «Кемне сөяргә кирәк», «Зиләйлүк» («Эштән чыгарылган татар кызына»), «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?», «Мәгъшукамә» җырларын яздыра.

Франция Милли китапханәсенең аудиовизуаль документлар департаменты коллекциясендә К. Мотыйгый башкарган «Пар ат», «Мәгъшукамә», «Тулган шәһәр чәйханәсе», «Тотса мәскәүләр якаң» һәм «Кичке азан» җырларының язмалары булуы ачыкланды [BnF]. Алар «Пате» ширкәтенең 1911 елда Мәскәүдә узган татар сессиясе барышында фортепиано аккомпанементы белән язылган. Беренче тапкыр бу язмалар белән мин 2011 елда таныштым. Шул ук елны «Пате» дискларындагы татар язмаларына кагылышлы эзләнүләрем «Казан утлары» журналындагы күләмле мәкаләдә чагылыш тапты [Граммофон тәлинкәләре ни сөйли?]. Соңрак, 2012 елның февраль аенда, Тукай музеенда узган «Граммофон тәлинкәләре нәрсә сөйли?» дип исемләнгән лекция-концертымда тәфсилләп сөйләп, әнә шул язмаларны ишеттердем.

Мәскәүдә урнашкан «Метрополь-рекорд» ширкәтенең 1911 елда чыгарылган татар тәлинкәләре арасында К. Мотыйгыйның фортепианога кушылып Г. Тукай шигырьләренә җырланган 9 язмасы барлыгы беленде.

Бу язмаларның оригинал матрицалары Россиянең дәүләт фонодокументлар архивы фондында саклананалар. Ә менә җырчының 1913 елдагы язмалары арасында Г. Тукай шигырьләренә җырланган әлегә ике генә язмасы табылды. «Кичке азан» һәм «Тотса мәскәүләр якаң» әсәрләренең язмаларын Санкт-Петербург шәһәрендә урнашкан «Русское Акционерное Общество Граммофонов» (РАОГ) ширкәте үзенең граммофон тәлинкәләренә бастырып чыгара. Күптән түгел Казандагы бер шәхси архивта «Кичке азан» язмасы теркәлгән тәлинкә табылды. Моны мин бик зур уңыш дип саныйм.

Эзләнүләр барышында К. Мотыйгыйның «Граммофон» ширкәтенең «Пишущий Амур» тәлинкәләре өчен Түбән Новгород шәһәрендә 1912 елның 26 августында, Мәкәрҗә ярминкәсе вакытында эшләнгән сессиядәге язмасы теркәлгән тагын да бер тәлинкә табылды. Татарстан милли музее фондында табылган тәлинкәнең бер ягындагы этикеткасына «Гыйбрәтле сүзләр» дип язылган. Аны тыңлаганда әлеге язма эчендә өч әсәр булуы ачыкланды. Һәрбер язма башында К. Мотыйгый нәрсә башкарасын үзе игълан итә. Иң башта «Байлар хакында» дип исемләнгән шигырь укый:

Гыйбрәт аласыңыз килсә,
барыгыз гастинсага,
Анда байлар кесәсендән су
аккандай акча ага;
Милләт файдасына килгәндә –
акча һич бирдә булмый,
Тәтәйләргә килгән чакта
портмонентлар ябылмый...

Шунысына игътибар итәргә кирәк – К. Мотыйгый бу сатирик әсәрнең нечкәлекләрен аңлап, бик эмоциональ, бирелеп башкара. Бу шигырьдән соң икенче шигырь игълан ителә: «Егет берлән бер кыз арасында булган сөйләшү». Анысын укыгач К. Мотыйгый «Төрлечә җырлар» дия дә, «Баламишкин» көенә музыкасыз гына шаян такмакларын җырлап җибәрә. «Егет берлән бер кыз арасында булган сөйләшү» шигыре – ул Г. Тукайның 1908 елда иҗат иткән «Егет илә кыз» исемле шигыре булып чыкты. Бу шигырьне укыганда К. Мотыйгый, егет белән кызның диалогын аерыр өчен, Г. Тукайның шигъри юллары алдыннан «Егет әйтә», «Кыз әйтә», – дип, өстәп укый.

Шулай итеп, бүгенге көндә Г. Тукай шигырьләренә К. Мотыйгый тарафыннан башкарылган 22 җырның һәм укылган бер шигырьнең язмалары булуы ачыкланды – барысы 23 язма. Кайбер язмаларның исемнәре кабатланса да, сакланып калган тәлинкәләрне өйрәнү барышында без бер үк исем астында башкарылган җырларның бер-берсеннән аерылып торуларын күрәбез. Кайбер очракта монда җырчының шигырь строфаларының урыннарын алыштыруы күренә, башкарылган җырның тональлеге һәм аккомпанемент характерының үзгәрүе, җырның йомгаклау өлешенең (коденциясенең) төрлечә башкарылуы ишетелә. Бу – бер үк җырның төрле вакытта, төрле музыкантлар белән төрле ширкәтләрдә язылуы нәтиҗәсе булса кирәк. Мәсәлән,

К. Мотыйгый башкарган «Тотса мәскәүләр якаң», «Кичке азан» җырларының язмаларында югарыда әйтеп узган үзенчәлекләр бик ачык күренә.

Г. Тукайның остазларыннан булган К. Мотыйгыйның язмышы һәм иҗаты мине күптәннән кызыксындыра. Шуның өчен дә аның репертуарын ачыклау, язмаларын өйрәнү барышында миндә бер уй туды: табылган граммофон язмаларына нигезләнеп җырчы репертуарын реконструкцияләү. Бүгенге көнгә К. Мотыйгыйның 11 җырын өйрәнеп, Татарстанның халык артисткасы М. Хәбибуллина җитәкчелегендәге инструменталь трио белән бергә «Татарстан – Яңа гасыр» радиосы фонды өчен яздырдык. Бу язмалар арасында Г. Тукай шигырьләренә «Тулган шәһәр чәйханәсе», «Пар ат», «Мәгъшукамә», «Тотса мәскәүләр якаң» һәм «Кичке азан» җырлары да бар.

«Пате» ширкәте дисклары арасында Казан татар хоры башкаруындагы «Ай, Дунай» дип аталган бер җыр минем игътибарны җәлеп итте. Анда солист башлап җырлаган беренче строфаны тыңлаганда, Г. Тукайның ике юллык «Бәет» исемле әсәре искә килеп төште:

Бәгъзеләрмез бик суфи, көн дә
бишнамаз укый;
Бурычка йөз мең алгач, аны
кесәгә салгач...
[Тукай, б. 102].

«Пате» ширкәте дискындагы язмада текст болай яңгырый:

Солист: «Безнең байлар бик суфи,
көн дә биш намаз укый»,
Хор: «Ай, Дунай, вай, Дунай,
Ай весёлый, шулай!».
Солист: «Унике сәгать йок(л)ый,
ашый да тагын йок(л)ый»
Хор: «Ай, Дунай, вай, Дунай,
Ай весёлый, шулай!».
Солист: «Мәскәүдән йөз мең
алгач, аны кесәгә салгач»,
Хор: «Ай, Дунай, вай, Дунай,
Ай весёлый, шулай!».
Солист: «Кулда ун тәңкә калгач,
кыладыр ул барып хаҗ»,
Хор: «Ай, Дунай, вай, Дунай,
Ай весёлый, шулай!».
Солист: «Мәккәмезни ярату кыла,
яман эштән тыела» һ.б.

Язмада бу бәет 4 строфаны тәшкил итә. Шулай итеп, 1911 елда язылган «Ай, Дунай!» җырының төп тексты Г. Тукайныкы булырга мөмкин бит дигән фараз туа.

Г. Тукай әсәрләрен граммофон тәлинкәләренә яздыручылар арасында Троицк шәһәрендә яшәгән җырчы-гармунчы Мөхәммәтҗан Гобәйдуллинны искә алып китәргә кирәк. Бу җырчы турында Мәҗит Гафури «Татар җырчысы» исемле мәкаләсендә язып чыккан. Автор анда М. Гобәйдуллинның җитди карашлы, көчле, чиста, матур тавышлы, тирән хисле, моңлы җырчы-гармунчы булуы турында яза. М. Гафури М. Гобәйдуллинны чын мәгънәсендәге «милли җырчы» дип атый: «...якын арада Мөхәммәтҗан әфәнде, “Общество Граммофон”га барып җырлап кайтып килгәндә, Уфага дәхи төште. <...> Мөхәммәтҗан әфәнде үзенең матур тавышы белән мөхтәрәм шагыйремез Габдулла Тукаевның “Теләнче”, “Алтынга каршы”, “Тотса мәскәүләр якаң!” вә

гайре шигырьләрене <...> тәэсир иттерерлек дәрәҗәдә килештереп җырлый, гармунины уйный иде. Мин, борыннан Габдулла Тукаев шигырьләренең мөфтүне булуы өстенә, аның матур шигырьләрене матур тавышлы бер агыздан ишеткәч, бигрәк тә сокландым <...> Югарыда исемнәре аталган шигырьләрне Мөхәммәтҗан әфәнде граммофонга җырлаган. Тиз көннән матур тавыш белән җырланган матур шигырьләрне, яңа көйләрне һәркем ишетә алачактыр...» [Гафури, б. 348].

«Граммофон» ширкәте М. Гобәйдуллин башкарган 23 җырны 1910 елның 14 сентябрендә Санкт-Петербургта яздыра. Бу язмалар арасында Г. Тукай шигырьләренә яңа көйләр белән җырланган «Тотса мәскәүләр якаң», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр», «Теләнче», «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?», «Алтынга каршы», «Дөньяда торыйммы? – дип киңәшләшкән дустыма», «Дөнья» («Дөнья» көенә) җырлары да бар.

Г. Тукайның замандашы, шәкерттәше, дусты, актер Габдулла Кариев (1886–1920) үзенең репертуарындагы әсәрләрнең кайберләрен шулай ук граммофонга яздыра. «Пате» дисклары арасында Г. Кариев башкаруында Г. Тукайның ике әсәренең язмалары бар. Беренчесе – «Ысулы кадимче» – көлке, ә менә икенчесе – язманы тыңлаганда гына, очраклы рәвештә, һич тә көтелмәгәндә пәйда булды. Г. Кариев яздырган дискның чокырлатып бастырылган этикеткасында «Зилзилә» (көлке) дип аталган хикәя күрсәтелгән. Г. Кариев менә шул «Зилзилә»сен 1 минут эчендә сөйләп бетерә дә, ике-өч секундлык паузадан соң, үзе үк «Теләнче» дип башкарылачак шигырьнең исемен игълан итә һәм укый. 2 минут 30 секунд барган әлеге язманың яңгыравын ишетү минем өчен, чынлап әйтәм, зур бер ачыш булды һәм бик тә шатландырды.

«Граммофон» ширкәте тарафыннан 1909 елның июль аенда Казанда эшләнгән язмалар арасында XX гасыр башында татарлар җәмәгатьчелегендә популярлык казанган, танылган куплетчы, хикәяче Г. Камаев Г. Тукайның «Тотса мәскәүләр якаң» шигырен куплет итеп җырлый һәм «Ысулы кадимче» исемле әсәрен укып яздыра. Тагын да бер куплетчы, комик актёр Г. Мамай укуында Г. Тукайның өч әсәре граммофон тәлинкәләренә языла. Германиянең Лейпциг шәһәрендә төпләнгән «Лирофон» ширкәтенең 1910 елгы язмалары арасында Г. Мамай башкаруында «Тотса мәскәүләр якаң», «Ысулы кадимче» һәм «Хатынлар хөррияте» (хәҗәр) исемле әсәрләр дөнья күрә.

Шулай итеп, эзләнүләр барышында шунысы ачыкланды: Г. Тукайның замандашлары тарафыннан граммофон тәлинкәләренә һәм Пате дискларына җырлап һәм укып яздырылган әсәрләрнең саны бүгенге көндә 40 ка җитә. Киләчәктә бу юлда безне яңа ачышлар көтүенә, әлбәттә, ышаныч бар, шагыйрь әсәрләренең язылуы турындагы яңа мәгълүматлар һәм, иң мөһиме, яңа язмалар табылуына зур өмет баглана.

**Әдәбият**

Граммофон тәлинкәләре ни сөйли? // Казан утлары. 2011. № 10. Б. 134–145.

*Гафури М.* Әсәрләр: 4 томда. III т. Проза һәм публицистика (1902–1917). Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.

*Тукай Г.* Әсәрләр. Академик басма: алты томда. I т. Шигъри әсәрләр (1904–1908). Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 407 б.

*Фридерик Михаиль.* Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы / пер. с нем. И.А. Гилязев. Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. 343 с.

The Gramophone Company Limited ZONOPHONE RECORDS THE ORIENT CATALOGUE. Compiled and Edited by Alan Kelly. March, 2000 (каталог CD форматында китерелә)

BnF (Bibliothegue nationale de France, departement Audiovisuel) // URL: http://gallica.bnf.fr. (мөрәҗәгать итү датасы: 20.04.2011)

***Газиев Идрис Мөдәрис улы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Россиянең атказанган,*
*Башкортостанның һәм Татарстанның халык артисты,*
*Башкортостанның С. Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты,*
*Уфа дәүләт сәнгать институты профессоры*
*gazievidris60@gmail.com*

УДК 821.512.145

***З.З. Рәмиев***

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ҺӘМ ФАТИХ ӘМИРХАН (1917 елга кадәр)

В статье сделана попытка раскрыть суть творческих взаимоотношений и взаимовлияния двух классиков татарской литературы – Фатиха Амирхана и Галимджана Ибрагимова. Показана реакция Г. Ибрагимова на опубликованные произведения Ф. Амирхана, эволюция его взглядов на творчество писателя.

**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, Фатих Амирхан, татарская литература начала XX века, татарская литературная среда начала XX века.

Теге яки бу әдип-язучының иҗат дөньясы, сәнгатьчә фикерләве турында сүз барганда, һәрвакыт диярлек аның чордаш каләмдәшләре белән бәйләнешләрен ачыклау зарурияте дә туа. Бу аңлашыла да, чөнки бер генә иҗатчы да япа-ялгыз мохиттә яшәми. Әлеге бәйләнеш, билгеле ки, төрле характерда була: кайсы – якыннан, кайсы – читтән торып, кайсы – бер яклы гына, кайсы – кара-каршы...

Күптән түгел басылып чыккан һәм татар филологиясе өчен уникаль фәнни хезмәттә – Габдулла Тукайның персональ әдәби энциклопедиясендә дә бу нәрсә күз алдында тотылган иде. Китап белән танышып өлгергән кешеләр күргәндер, анда Тукайның замандаш әдипләре белән галәкасе турында да тыгыз фикерле мәкаләләр урын алган, мәсәлән, «Әмирхан Фатих», «Ибраһимов Галимҗан», «Исхакый Гаяз», «Камал Галиәсгар» кебек мәкаләләр – шундыйлардан. Аларның авторлары чордаш әдипләрнең Тукайга шәхсән һәм басылып чыгып торган әсәрләренә, китапларына үзенчәлекле мөнәсәбәтләрен һәм, билгеле инде, шагыйребезнең дә каләмдәшләре иҗатына, үз-үзләрен тотышларына уңай яки тискәре карашын ышанычлы фактларга нигезләнеп тасвирларга омтылдылар.

Киләчәктә дә, мондый персональ (шәхси) энциклопедияләр төзелә калса, әдипләр арасындагы мөнәсәбәтләрне шәрехләү һәм укучыга җиткерү мәсьәләсе дә алга килеп басачак. Шуны истә тотып, мин андый хезмәтләрнең Фатих Әмирхан һәм Галимҗан Ибраһимовларга да багышланганнарын тудыру эшенә керештем, хәтта ки икесендә дә урын алырдай бер мәкалә язып карарга ниятләдем. Ул «Ибраһимов Галимҗан» дип тә, «Әмирхан Фатих» дип тә исемләнә ала, әмма эчтәлекләре исә тулысынча диярлек тәңгәлләшәчәк («Библиографик күрсәткеч»ләрендә композиция үзгәрә).

Бер үк чорларда яшәп иҗат иткән бу ике әдипнең реаль тормышта беренче мәртәбә очрашу-аралашуларына кагылышлы мәгълүматлар истәлекләрдә дә, матбугат битләрендә дә, хатларында да бик аз очрый. Ибраһи-

мовның 1936 елгы «Автобиография»сеннән күренгәнчә, ул Казанга 1909 елда (көзгә таба) университетка укырга керү нияте белән килеп чыга [Ибраһимов, т. 9, б. 54] (1912 елга кадәр яши, димәк ки, очрашу шул вакытларда гына була ала). Әмма аңа кадәр инде алар бер-берсен белгәннәр. 1907 елда Кавказда мөгаллим булып торган чагында Ибраһимов «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемле беренче хикәясен яза һәм кулъязма тиздән Ф. Әмирхан кулына килеп керә (әсәр авторы «Мөхәрриреннән» дигән аңлатмасында: «Фатих Әмирханов җәнабләренең кулына төшеп...» – ди [Ибраһимов, т. 1, б. 504]). И. Нуруллин, әсәрнең кулъязмасын Г. Ибраһимов үзе Казанга килеп чыгып, «Әлислах»ка тәкъдим итә, дип яза [Нуруллин, б. 115] (Ф. Ибраһимова исә хикәягә язган комментарийда: «Әлислах» редакциясенә кулъязма сентябрь ахырында алына», – ди [Ибраһимов, т. 1, б. 504–505]). И. Нуруллин сүзе дөреслеккә туры килсә, очрашу 1907 елның сентябрь – октябрь башларында ук булыр иде. Чөнки газета редакциясендәге даими хезмәткәрләр, шул исәптән Г. Тукай да, хикәяне бастырырга теләмәсәләр дә, Ф. Әмирхан аны дөньяга чыгару фикерен яклый [Нуруллин, б. 115]. Әсәр газетаның 1907 елның 10 октябрь (2 нче) саныннан укучылар игътибарына тәкъдим ителә башлый (унҗиде санда чыга). «Хикәяне алып укыгач, Ф. Әмирхан, тәүге уңышы белән тәбрикләп, яшь авторга хат яза; аңа әдәби иҗат эшендә зур уңышлар тели, дусларча киңәшләр бирә; шунда ук яшь әдипкә газетаның Уфа губернасындагы хәбәрчесе булырга тәкъдим итә» (Ф. Ибраһимова сүзе [Ибраһимов, т. 1, б. 505]). Г. Ибраһимов бу тәкъдимне кабул итә. Газетаның 1908–1909 елларгы саннарында аның сигез язмасы басылган. Язучының хатыны Г. Мөхәммәдова «Эзләнүләр» исемле китабында Ибраһимовның, кулъязманы «Әлислах» редакциясенә тапшыру өчен, 1907 елда «көзнең соңгы бер көнендә» Казанга махсус килеп чыгуын, ләкин анда Ф. Әмирханны очратмавын, ике сәгатьтән пристаньнан кузгала торган пароход белән кире Уфага китеп баруын яза [Мөхәммәдева, б. 190].

1908–1915 еллар – Г. Ибраһимовның прозада, ә Ф. Әмирханның исә прозада һәм драмада актив иҗат иткән вакытлары. Билгеле ки, алар бер-берсенең язганнары белән эледән-эле «очрашып» торганнар (китаплары басылган, вакытлы матбугат битләрендә еш чыгыш ясаганнар). 1910 ел башында Г. Ибраһимов, татар шагыйре дигәч тә, укучы зиһенендә Тукаев пәйда була, дип яза [Ибраһимов, т. 5, б. 7], ә «Татар кызы»н асаре шигърияга (чәчмә белән язылган шигъри әсәрләр рәтенә) кертеп, «Татар матбугаты» исемле мәкаләсендә бу вакытларда хикәячелек мәйданында алгы урынны биләүче итеп нәкъ менә Ф. Әмирханны күрсәтә. Шул ук вакытта «үзенең бөтен тәнкыйтьләрен реальный ноктадан йөрткән бу әфәнде» хыялга корылган (яисә хыял һәм хакыйкать катыш) әсәрләр язуга авыша дип саный, моның

сәбәпләре итеп «иске татар тормышын белмәүне, шәхси «тормыш рәвеше тәэсире»н күрсәтә, каләменең шигърияте исә Г. Исхакыйныкыннан яктырак дип тәкуя [Татар матбугаты]. 1901 елның 22 январенда Ф. Әмирханга Томскидан җибәргән хатында И. Бикколов та: «Габдинең сезнең тугрыдагы заметкасы бик тугры. Сез үзегез реализмнан ераграк йөрисез», – ди, Ф. Әмирханның «Танымаганнан таныштык» хикәясендәге Разия, студент Мортазин образларын «реальный түгел» дип, ә Гайсаны исә нәкъ татар байбәтчәсе итеп саный [Ибраһим Бикколов хатлары, б. 164]. Ике кешенең шактый охшаш бәя бирүләрен Ф. Әмирхан игътибарсыз калдырмаган шикелле, чөнки И. Бикколов 18 көн соңра язган хатында бу мәсьәләгә кабат кагыла, аныңча, Гайса образы шактый дәрәҗәдә тормыштан алынган (әсәрне «бөтенләй алай бушка чыгарып булмый» [Ибраһим Бикколов хатлары, б. 167]; Ф. Әмирхан хаты сакланмаган). Г. Ибраһимов, шул ук елгы «Әдәбият мәсьәләләре» исемле шактый күләмле язмасында төрек әдәбиятын күзаллаганда хәтергә Әхмәд Мидхәд, Мәхмүд Әсгадь, Тәүфикъ Фикрәтләрне килүен искәртеп, татар әдәбияты әһелләре арасында беренчеләр итеп нәкъ менә Тукай һәм Әмирхан исемнәрен атый [Ибраһимов, т. 5, б. 21].

Г. Ибраһимов – каләмдәшенең «Хәят» һәм «Урталыкта» әсәрләренә башлап сүз әйтүчеләрдән дә. Шул заман проза әсәрләрендәге җитди кимчелекләрне (һаман саен муллаларга тию, шәкерт тормышын, хәлфәләрне, мәдрәсәләрне яманлау, татар хатынының зарлы язмышын тасвирлау) күрсәтеп, ул «Хәят» повестеның басылып чыгуын бик урынлы күрә, анда «җиңеллек, каләм осталыгы, бәйрәм, яшьлек вә шатлык хис кыйлын»уын әйтә, гомумән, әдәбият мәйданындагы вакыйгага тиңли. Әмма, аның фикеренчә, әсәрдә «сай чыккан җирләр дә күп»: яшьләрнең беренче мәхәббәте дә сыек чыккан, Хәят тибының табигыйлыгы шөбһәле (И. Нуруллин фикеренчә, Ибраһимов Хәятне типик образ итеп карый алмый); «милли хикәя» диелсә дә, анда «миллилек» җитми: теманың үзәгендә «татарлык аңкып торырга, каһарманнар татар рухы илә мөкәммәл рәвештә сугарылган булырга кирәк» [Ибраһимов, т. 5, б. 57–59] (хәзерге заманда да бик актуаль таләп!). Шул ук вакытта Ибраһимов әсәрнең беренче кисәге генә нәшер ителгәнлеген дә онытмый, әдәби кыйммәте турындагы фикерен икенче кисәге чыккач әйтәчәген искәртә. «Урталыкта» романына бәя бирүне дә Ибраһимов соңгарак калдыра, чөнки «урта кулда мең битләр чамасы булуы ... гөман ителгән» [Ибраһимов, б. 57–58]; әле беренче кисәге генә басылып чыккан (икенче кисәге бераз соңрак – шул ук 1912 елның ахырында чыга). Аныңча, әсәрнең теле ачык, «ләкин бераз ясалмарак татарчага якын», эчтәлегендә төп урынны укучы яшьләр һәм туташлар тормышы били. Авторның бу чорда, гомумән, роман жанрына биргән бәяләмәсе дә дикъкатькә лаек: ул үзенең бөтен

тәмамы вә бөтен торышы белән аерым, билгеле һәм бөтен бер мәгънәне күрсәтергә тиеш.

Г. Ибраһимовның каләмдәше әсәрләренә тәнкыйди фикерләр дә әйтүе ике әдип арасындагы мөнәсәбәтләргә сизелерлек тәэсир-йогынты ясамаган булса кирәк. Мәсәлән, бу Ф. Әмирханның Ибраһимовка 1912 елның көзендә Киевкә китәр алдыннан тиздән чыга башлаячак «Аң» журналында язышырга рәсми рәвештә мөрәҗәгать итүендә күренә. Ләкин журналның 1912 елның 15 декабрендә басылган беренче номеры, 1913 елның 3 январенда Х. Кайбышевка юллаган хатыннан аңлашылганча [Ибраһимов, т. 9, б. 69–70], ни сәбәпледер, бу вакытка кадәр Ибраһимов кулына килеп керми. Әлеге фактны Әмирханның (һәм нашир Ә. Хәсәнинең дә) мәгънәсезлеге итеп бәяләсә дә, ул, Киев вакыйгаларыннан исәнимин котылгач, аларның чакыруын истә тотып, Казанга килеп чыга (1913 ел, 16 сентябрь) һәм «Аң» журналының сәркатибе вазифасын ала; журнал 21 нче саныннан аның карамагында чыга башлый (бу санда Ф. Әмирханның «Корбан» хикәясе дә бар). Әлеге хатта Ибраһимов Әмирханның «Халык кызлары» исемле әсәрен ошатмавын да белдерә: аның Айга менгән Зөһрә турында язарга алынганлыгына баштарак ачуы килгән булса, әсәрне күргәч, ачуы инде таралуы, хәтта авторны кызгануын хәбәр итә («бик озаклап көлә»). Ул «халык кызлары» Айсылу (Зөһрә) турында Х. Кайбышев һәм Зөлхәбирә турында «бичара» З. Бәшири язган хикәяләрне Ф. Әмирханның «Халык кызлары» китабындагы текстларыннан югарырак куя, үзенең Сөембикә турында башкачарак язарга уйлавын да әйтеп уза. 1913 елда гына басылып чыккан китапның ахыргы битендә текстның 1912 елның сентябрендә үк язып тәмамлануы әйтелгән, димәк, Әмирханның яисә нәшрияттә эшләүчеләрнең рөхсәте беләндер, Г. Ибраһимов Казанда чакта ук әсәр тексты белән танышкан була. Хат ахырында «бер минутлык тәэсир астында, гайре табигый халәттә языла. Эчендә җүләрлекләре булса, шул халәттән күрерсез» диюеннән, Ибраһимовның андагы үз фикерләре гаять субъектив икәнлеген тануы сизелә. Әдип, аңга килеп дияргәме, соңрак, 1914 елда, «Яңа әдәбият» исемле хрестоматиясен төзегәндә, Ф. Әмирханның «Искергән баһадир» исемле парчасы белән бергә, әлеге «Халык кызлары» эчендәге «Ай өстендәге Зөһрә кыз»ны – «әкият вә тарихлардан алынып язылган хикәя»сен дә урнаштырган, аны «әдәби мәҗмуганың кадерле урынын зиннәтләрлек парчалар»ның берсе итеп бәяләгән [Ибраһимов, т. 5, б. 171]. Шул ук елгы «Матбугат вә әдәбиятымызның барышы» исемле еллык хисабында, Ф. Әмирханны да телгә алып, ул әдипнең 1913 елда аз язуын, «әдәбияттан бигрәк журналистикага бирелеп» баруын әйтә. Аның фикеренчә, әлеге «Халык кызлары» «матур вә милли мәүзугъны җиңел вә мәгънәле бер эслүб илә ифадәдән гыйбарәт» [Әмирхан, т. 3, б. 16]. М. Хәсәнов «Галимҗан

Ибраһимов» исемле монографиясендә 1914 елның февралендә Казанда уздырыласы яшьләр җыелышында әдип «Татар яшьләренең бурычлары» дигән доклад ясарга алынганын яза. Җыелышка Ф. Әмирхан да чакырылган була [Хәсәнов, б. 83].

Г. Ибраһимов Ф. Әмирханның XX гасыр башы татар прозасы казанышы булырдай әсәрләр иҗат итүен таныган, үзе романтик хис-кичерешләргә, тасвирларга зур урын биргән булса да, каләмдәше әсәрләренең реалистик эчтәлекле булуын теләгән. Ә менә ул заман матбугаты битләрендә, хатларында, истәлекләрдә ике әдипнең якыннан аралашып яшәүләре хакында мәгълүматлар бик аз. Монда икесенең дә холык-фигыльләрендәге үзенчәлекләр роль уйнаган шикелле. Фактлар Яңа Бистәдә туып үскән Ф. Әмирханның, аяксыз хәлдә дә, шәһәр атмосферасында үзен иркен тотуы, төрле мәдәни чараларда бик теләп катнашуы, зыялы кешеләр, яшьләр белән очрашырга, уен-көлке сөйләшергә дә яратканлыгы турында сөйли. Г. Ибраһимов исә Казанда вакыт-вакыт кына яшәп ала, ул – чит җирдән – башкорт тарафыннан килгән чит кеше; матди тормышын да тәэмин итү өчен иҗат эше белән аеруча актив шөгыльләнергә кирәк булгандыр. Икенче бер нәрсә дә мәгълүм: 1910 ел башында «Хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле һәм иң галәбәле рольне мөхтәрәм Тукаев уйный» дип язып чыккан Г. Ибраһимовның шагыйрь иҗатын бәяләве бераздан башка төс ала. Тукай вафаты көннәрендә басылган «Татар шагыйрьләре» исемле җитди хезмәтендә ул хәтта аның шагыйрьлеген шөбһә астына ала. Ә 1908 елдан Тукай белән «мәхрәм» (сер яшерми торган) дуслар булып [Әмирхан, т. 4, б. 119] киткән, аны татарларның «иң мәшһүр, иң сөекле шагыйре» итеп күргән Әмирхан Г. Ибраһимов белән шагыйрь арасындагы мөнәсәбәтләрдә матурлык булмаганын күреп, сизеп торган һәм мондый бәя белән килешмәгән булырга тиешле...

Ике әдип тә 1917 елгы Февраль революциясен рухланып каршы ала: Г. Ибраһимов беренче публицистик мәкаләсен («Куәт – халыкта») «Тәхет җимерелде. Богаулар өзелде...» дип башлап җибәрсә [Ибраһимов, т. 6, б. 115], Ф. Әмирханныкы исә «Богаулар өзелделәр» дип исемләнгән дә [Әмирхан, т. 3, б. 324]. Икесе дә Октябрьне кабул итә, 1917 елдан сул эсерлар партиясендә булган Г. Ибраһимов бераздан большевиклар партиясенә дә керә. Гражданнар сугышы елларында икесе дә вакытлы матбугатта большевиклар хакимиятен хуплап чыгыш ясыйлар. Илдә тынычлык урнашты дип торганда гына Идел буенда килеп чыккан фаҗигале ачлык күренешләре дә аларны бик нык борчый. Бу Г. Ибраһимовның совет чорындагы басмаларыннан читләштерелгән «Адәмнәр» повестенда, Ф. Әмирханның көндәлекләрендә (дүрттомлы «Әсәрләр»ендә кыскартылып кына урнаштырылды) чагылыш тапкан. Яңа чынбарлыкта алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең кайбер мөһим яклары соңгы елларда Н. Вәлиев,

М. Әхмәтҗанов кебек галимнәрнең китап һәм мәкаләләрендә күрсәтелде. Аларны тәфсилләп өйрәнү, хакыйкатьтә барынча ачыклау киләчәк эше булып кала.

**Әдәбият**


Аң. 1912. № 1.

Аң. 1914. № 1.

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 3 т. 512 б.

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 4 т. 390 б.

Ибраһим Бикколов хатлары // Духовное наследие: поиски и открытия. Казань: ИЯЛИ, 2016. Вып. 2. С. 164–169.

*Ибраһимов Г.* Әсәрлә: 9 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 1 т. 510 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 9 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т. 616 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 9 томда. Казан: Татар. кит. нәшр, 1986. 6 т. 606 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 9 томда. Казан: Фикер, 2000. 9 т. 464 б.

*Мөхәммәдева Г.* Эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 376 б.

*Нуруллин И.* Фатих Әмирхан. Атаклы кешеләр тормышыннан. Казан: Татар. кит. нәшр.,1988. 279 б.

Татар матбугаты // Йолдыз. 1910. 12 январь.

*Хәсәнов М.* Галимҗан Ибраһимов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. 332 б.



***Рәмиев Зөфәр Зәйни улы,***

*филология фәннәре докторы,*

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Ж.А. Жакупов***

# КАЗАКЪ-ТАТАР РУХИ ЭЛЕМТӘСЕНЕҢ БЕР КҮРЕНЕШЕ ХАКЫНДА (Г. Ибраһимов һәм А. Байтурсынов)

В статье в сопоставительном плане показаны некоторые моменты биографии и творчества классика татарской литературы, общественного и государственного деятеля Г. Ибрагимова и казахского ученого-лингвиста, тюрколога и общественного деятеля А. Байтурсынова. Основной акцент делается на схожести взглядов и общественной позиции обозначенных личностей.

**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, Ахмет Байтурсынов, татарская литература начала ХХ века, проблема перевода письменности татар на латиницу.

2016 елда Казан китапханәсендә А. Байтурсыновның иҗаты хакында библиографик исемлекләргә әлегә кадәр кертелмәгән бер мәкалә табылды. Ул мәкалә Татарстанда гарәп графикасы белән татар телендә нәшер ителә торган «Безнең юл» журналында (1928 ел, 2 нче сан) дөнья күргән. Автор «Галимҗан Ибраһимов төрек-татар уйчысы (*фикер иясе*), төрек-татар белгече, төрек-татар язучысы» дип исемләнгән бу язмасын 1928 елның 24 гыйнварында Кызылордадан җибәргән була [Байтурсынов].

Мәкаләнең герое – галим, әйтеп үтелгән журналның редакторы, төрки халыклар бердәмлеге өчен көрәшүче әдип, безнең Алаш Орда татарларының фикердәше, төрки халыклар язмасын латин алфавитына күчерүгә каршы чыккан Әхмәт Байтурсыновны хуплаучы Галимҗан Ибраһимов. Әлеге хезмәттә казакъларның һәм башка төрки халыкларның рухи язмышы чагыштырып яктыртыла.

Кардәш халыкларның бу ике олуг вәкиле бер дәвердә яши. Шунысы мәгълүм, казакълар белән татарлар арасындагы бәйләнешнең башы борынгы төрки заманнарга ук барып тоташа. Ә менә бу ике халыкның да рухи яңарышы 1905 елдан – Россиядәге буржуаз-демократик инкыйлаблар чорыннан башлана. Мәгълүм булганча, бу вакытта төркичелек идеологиясе көчәя. Нәкъ менә шул тарихи вакыйгалар белән бәйле елларда Әхмәт Байтурсынов белән Галимҗан Ибраһимов шәхесләре фикри яктан башка замандашларыннан аерылып торалар. Аларның тарихи аренага чыгарган юллары да бер-берсенә охшаш. Инде шул юлларны чагыштырып карыйк.

А. Байтурсынов (1873) та, Г. Ибраһимов (1887) та авыл җирендә туганнар.

Икесе дә дини мәктәпләрдә башлангыч белем алганнар.

Аннан соң икесе дә рус мәктәбендә укыйлар: А. Байтурсынов 2 сыйныфлы рус-казакъ мәктәбен 1891 елда тәмамлап,

Оренбургтагы 4 еллык мәктәпкә укырга керә; Г. Ибраһимов исә рус мәктәбеннән соң «Галия» мәдрәсәсендә белем ала.

Хезмәт юлларын икесе дә укытучы булып башлыйлар: Г. Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсендә мөгаллимлек итә, 1920–1924 елларда мәгариф системасында эшли; А. Байтурсынов исә башта авыл мәктәбендә укыта, 1921–1925 елларда Оренбургта, 1926–1928 елларда Ташкентта казакъ әдәбияты һәм теле, шулай ук мәдәният тарихы буенча белем бирә. 1928 елдан Алматыдагы Казакъ дәүләт пединституты ректоры тәкъдиме белән профессор дәрәҗәсендә хезмәт куя.

Әдипләрнең икесе дә журналистлар һәм мөхәррирләр буларак та танылалар: Россиядәге Февраль инкыйлабыннан соң Г. Ибраһимов, Сәйфи Фәйзи белән бергә, «Ирек» газетасы чыгара, сентябрьдән «Безнең юл», «Мәгариф» журналларын һәм «Чулпан» газетасын редакцияли; А. Байтурсынов 1913–1918 елларда үзенең иң ышанычлы дуслары А. Бакыйхан һәм М. Дулатов белән «Казакъ» дип исемләнгән беренче гомуммилли газетаны чыгара.

Галимнәр икесе дә фәнни процесслар белән идарә итәләр: Г. Ибраһимов 1919–1920 елларда Үзәк мөселман хәрби коллегиясе әгъзасы, 1925–1927 елларда ТАССР Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Гыйльми үзәкне җитәкли, В.И. Ленин хезмәтләрен татарчага тәрҗемә итү комиссиясе рәисе урынбасары һ.б. [Большая советская энциклопедия, т. 9, с. 621]; А. Байтурсынов 1919–1921 елларда Казакъстанда Халык мәгарифе комиссары, 1922 елда Край мәгариф комиссариаты каршындагы Академүзәк рәисе, 1922–1925 елларда Казакъстан краен өйрәнү җәмгыяте рәисе була.

Бу җәмәгать эшлеклеләренең икесе дә 1926 елда Бакуда уздырылган тюркологлар съездында язмачылыкны латин графикасына күчерүгә каршы чыгалар.

Аларның фәнни хезмәтләре юнәлешләрендә дә охшашлыклар күп:

– Г. Ибраһимов 1911 елда «Татар сарыфы»н әзерләп бастыра һәм шуның белән татар грамматикасы теориясенә юл сала. А. Байтурсынов 1912 елда «Оқу құралы» хезмәте белән казакъ алфавитын нигезли (бу дәреслек 1925 елга кадәр берничә мәртәбә басылып чыга), 1914–1916 елларда казакъларның нигез теленең беренче фонетикасын, морфологиясен һәм синтаксисын эшли [Байтұрсынұлы, 2013];

– милли әдәбият өлкәсенә килгәндә, Г. Ибраһимов 1914 елда «Әдәбият дәресләре»н, А. Байтурсынов 1926 елда «Әдәбиет танытқыш»ны яза [Байтұрсынұлы, 1989];

– ике галим дә туган телне укытуның яңа методикасына нигез салалар. А. Байтурсынов 1912 елда «Оқу құралы» һәм шушы өлкәгә караган берничә мәкалә яза; Г. Ибраһимов 1916 елда «Татар телен ничек укытырга?» китабын бастырып чыгара.

Сәяси карашлары буенча да бу шәхесләрдә уртак юнәлешләр аз булмый (монда максат аларның

нинди сәяси юл сайлавын күрсәтү түгел. – *Авт.*). Иҗтимагый-сәяси эшлеклеләр буларак алар икесе дә милли юнәлешкә өстенлек бирәләр. Аларның бу юлдагы каршылыклары да бер үк төрле [https://ru.wikipedia.org/wiki; https://kk.wikipedia.org/wiki].

Бу язучылар икесе дә халык арасыннан күтәрелеп чыкканнар. Әсәрләрендә тасвирланган мотивларның да охшашлыгы бәхәссез. Әдипләрнең иҗат хәзинәләрен махсус рәвештә янәшә куеп өйрәнү күп төрле яңа нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирәчәк.

Казакъ язучысы, әдәбият галиме М. Ауэзовның А. Байтурсынов турындагы түбәндәге фикерләрен һич икеләнми Г. Ибраһимовка карата да әйтергә була: «Казахская школа, открытая Ахметом, родной язык, возрожденный Ахметом, гимн национализма в литературе – «Қырық мысал», «Маса», «Казах», огромный труд на благо казахского народа – все это даже если мы забудем, история не забудет. Это знает весь народ. Никто и не сомневается в истинности этого».

Г. Ибраһимов белән А. Байтурсынов язмышларын янәшә баручы күренешләр дип бәяләү һич кенә дә дөрес булмас иде. Чөнки аларның максатлары уртак. Аларны без уртак язмышлы шәхесләр дип ныклы ышаныч белән әйтә алабыз.

Г. Ибраһимовның казакълар белән рухи бәйләнешләре хакында башка мәгълүматлар да бар. Казакъларның танылган шагыйре Магжан Жумабаев Кызылжар (Петропавловск) мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Уфага китеп, «Галия» мәдрәсәсендә укый. Мәдрәсә мөгаллиме Галимҗан Ибраһимов талантлы яшь казакъ шагыйренә игътибар итә һәм Магжанга башка уку йортына китеп белем алырга, сүз сәнгате серләренә тирәнрәк үтеп керергә киңәш бирә. Г. Ибраһимов үзенең «Казак кызы» романына эпиграф итеп Магжан Жумабаевның түбәндәге юлларын сайлый:

*Кең дала, көресің ғой, ана жатқан,*
*Жібектей жасыл шөптер бетін жапқан.*
*Асқар тау, балдан тәтті сулары бар –*
*Әне, сол анам еді мені тапқан.*

Казакълар илендә А. Байтурсынов эше, аның идеяләре дәвам итә, казакъ-татар әдәби һәм мәдәни бәйләнешларга игътибар кимеми [Ысқақов; Сәтбаева].

Хәзер сезнең игътибарыгызга А. Байтурсыновның 1928 елда «Безнең юл» журналында басылып чыккан Г. Ибраһимов турындагы мәкаләсен тәкъдим итәбез.

**Галимҗан Ибраһимов төрк-татар уйчысы, төрк-татар белгече, төрк-татар язучысы**

Мәдәният юлында артда калган илнең алга чыгып, күзгә күренерлек адәмләре бармак белән генә санарлык була. Бу – бер. Икенчедән, андый адәмләрнең үз халкыннан артдырып, эшенең сәмәрәсен читкә чыгарырлыклары да аз була. Шул азларның берсе – Галимҗан Ибраһимов.

Еракда – далада яткан без – Казак туганларның күзенә Галимҗан юлдаш күгдән төшкән

бер азамат, анын эшләгән эшләре, уйлаган фикерләре татар мохитендән читкә чыгып, безгә дә арткан бер кеше. Шунлыкдан анын 20 еллык фикер, тел хезмәтен искә алыб, аңа хөрмәт күрсәтеб, үз халкы туй кылыб яткanda, без дә бер-ике авыз сүз әйтүне тиешле табдык.

Иң элек шуны әйтергә кирәк: бер халык икенче халыкка төрле ягы белән якынлаша, төрле якдан бәйләнешә, ялгана, нинди генә халык булса да беренең мәдәниятендән бере файдаланыб, берендән бере үрнәк күреб, өлге алыб алга басканы мәдәният тарихындан билгеле. Шул берендән бере өлге алыб файдалану ике халык арасында тормыш ягындан, гореф-гадәт ягындан, тел ягындан якынлык булу белән дә бик нык бәйләнгән. Шундый якынлык булганда гына берендән бере файдалану җиңел була; андый якынлык булмаса, файдалану аз була.

Шул канундан төрк халыклары да котыла алмаган һәм котыла алмый да. Ләкин боларның арасы якынлыкдан «уң кул биргәнне суңысы белми» калыб, үз араларындагы йогынты сизелми кала. Мисалга безнең Казак халкын алсак – ул тирә-ягындагы халыкдан һәркайсының якынлыгына караб файдаланганы күренеб тора. Казакның тирә-ягындагы халыкның иң мәдәниятлесе нимес, андан соңгысы урыс, аның артында татар белән үзбәк тора. Казак халкы шуларның мәдәниятендән файдаланганда азындан аз алыб, күбендән күб алыб файдаланганы юк, бәлки якынлыгына караб файдаланды. Нимес мәдәниятендән Казак төрк дә алганы юк. Урыс мәдәниятендән үз ирке белән алганы – иген чәчү. Татар белән үзбәкдән алганы: үзбәк Казакка ишан бирде, татар – мөгаллим бирде.

Патша заманында Казакка мөгаллим әзерләп биргән, Казакка төрки танытыб, укырга-язарга өйрәткән татар булды. Патша хөкүмәте татар мөгаллимен Казак арасына җибәрмәскә төрле чаралар эшләсә дә, аңа карамады, татар мөгаллиме Казак эченә тулып китде.

Урыс татардан күб, аның мәдәнияте дә татардан көчле иде, учительләре нигә Казак арасына чыкмады, нигә Казакка уку-язу өйрәтмәде? Аларның Казак эченә баруына патша хөкүмәте каршы булмак түгел, баруына ярдәмләшә иде. Татар мөгаллимен Казак эчендән куыб бетерә алмыйча патша хөкүмәтенең азаблануының сәбәбе ни иде? Аның сәбәбе югарыда әйтелгән якынлык иде. Урыс белән Казакның арасында күршелекдә якынлык бар, кәсебенең төрендә якынлык бар: икесе дә иген игә. Кәсебенең төре якын булганлыкдан Казак урысдан өлге алыб иген игәргә өйрәнде. Андан башка, ни телендә, ни тормышында, ни гореф-гадәтендә якынлык булмагач, урыс учителе Казак тормышына көйләнә алмады, Казак тормышы урыс учителен күбләб үз эченә тартыб ала алмады.

Мондан ни күрәбез? Мондан шуны күрәбез: арасында якынлык бар халык берәве алга басса, башкалары да шундан өлге алыб алга омтыла икән, берсенә берсе йогынты ясый икән.

Соң әнә шул йогынты һәм якынлыкны өзмәскә нинди чаралар бар? Мәсьәлә шунда. Юлның төрле якка караб таралуы шул җирдә. Берәүләр: төрк халыкларының арасы ераклашмасын өчен теле бер булу кирәк, диләр. Теле бер булу өчен мәдәниятдән түбәнләре үз телләрен ташлаб, мәдәнияте югары булганларының телен кулланыб, шул тел белән укытыб, шул тел белән әдәбият тудырсын диләр (*Атаклы Гаспринский 30 ел буена шул фикерне чәчде. Җәмал Вәлидидә дә шундый уй бар иде («Татар әдәбиятының барышы» дигән китабын карагыз). Ләкин боларның чәчкән фикере һич бер җимеш бирмәде. Казак үз алдына әдәбият тудырды. Башкорт, кыргыз кебек саны аз халык та совет хөкүмәте аркасында үз телен тергезеп, үз әдәбиятын аякка бастырды*). Берәүләре төрк халыкларының телләрен берләштерү, әүвәле мөмкин була торган эш түгел; икенчедән, мөмкин булганда да аңа күб көч белән, күб эш кирәк, ул эш төрк халкының кулындан килми; максат төрк халыкларының барын да бер телдә сөйләштерү түгел, берендән бере өлге алыб, мәдәният юлында берендән бере файдаланырлык итү, аның өчен телен берләштермичә генә, беренең әдәбиятын икенчесе аңларлык булса җитә, диделәр.

Менә шул мәсьәләдә Галимҗан юлдаш төрк уйчыларының кай тарафында торып Казак күзенә күренгәнен әйтеп үтмәкче булам.

1. Без – Казак халкы саф Казак телендә матбугат тудырыб, әдәбиятыбызны тергезгәндә, балаларыбызны үз телебездә укыта башлаганда татар туганнарыбызның ул вакытда алдагы сафдагыларының күбесе бу эшкә каршы булды. Ул вакытда татарча гәзит-журналларда безгә каршы язылган фикерләргә урын бирелде. Шул вакытда безнең юлыбызның турылыгын әйтеб, безнең эшебезне кулалаган татар азаматларыннан Галимҗан Ибраһимов белән Хәсән Гали булды.

2. Беренче тюркология корылтаенда ясаган докладыы буенча Галимҗан юлдашны Казакларның тануы тагы башкарак булды. Мәсьәлә – төрк халыкларының хәзерге кулланмакда булган язуы белән хәреф мәсьәләсе иде. Галимҗан: «Телне беректерү кыен эш, ул кулыбыздан килми; мәдәният казнасы булган әдәбиятдан төрк халыклары уртак файдалану өчен тел бер булу кирәк иде, ләкин алай түгел, тел башка-башка. Аны беректерү мөмкин дә түгел. Шулай булгач, төрки әдәбиятны төрк халыклары бары да файдаланырлык мөлек, уртак казна итү өчен башка чара эзләргә, башка әмәл табарга кирәк», – дип чыкды.

Ул әмәл, Галимҗанның фикеренчә, 1) төрк телләрендәге барына уртак нәрсәләрне дөресләп, уртак файдалана белүдә, 2) төрк халыклары үзара аңлашыб күгезүдә (?) булачак.

Төрк телләрендә, бер ягындан, берендән берен аера торган хосусиятләр булса, икенче ягындан, беректерә торган хосусиятләр дә бар, ди Галимҗан. Мәсәлән, фонетика законы барына да бер; морфология ягыннан сүзләрнең тамырындагы

авазларда уртаклык бар. Шуларны тәртибкә салыб, уртак файдаланырлык итәргә кирәк. Алай итәр өчен Галимҗан шундый нигезләрне тәкъдим итә:

А) имляда тик фонетика нигезенә таянмыйча, сүзләрнең тууышы нигезенә дә карарга кирәк;

Б) имляны шивәләргә бәйләүдән качу, бәйләүчеләр белән көрәшү;

П) аваз тамгалары (хәрефләр) бер булу, яңа тамга алганда бергә аңлашыб алу;

Т) яңа фән атамаларын алганда уртак куллануга ярарлыкларын алу;

Ж) шуларның барын тел корамалары аркылы үткәзү.

Төрк әдәбияты төрк халыкларының уртасындагы уртак казна булуы турысында Галимҗанның ничек уйланыб, нинди чаралар эзләгәне мондан ачык күренеб тора.

Менә шул әйткән нәрсәләр бары да Галимҗан юлдашны татар чигендән чыгарыб, киңерәк мәйданда йөзә торган гомумән төрк-татар уйчысы, төрк-татар белгече, төрк-татар язучысы итеб таныта торган эшләр. Галимҗан юлдашны без шулай таныйбыз. «Юлдаш» дигән сүзне мин бу җирдә гадәтдә нәзакәтән әйтелә торган юлдаш мәгънәсендә алмыйм, чын мәгънәсе белән юлдаш диб алам. Чөнки йөрешебез башка булса да, юлыбыз бер. Юлыбызда төрле сикәлтәләр булыр, кай урында төшеб дә калырбыз, эш анда түгел, эш ниятдә. Ниятебез дөрес булса, юлның сикәлтәсендән күб зарар булмас.

Сүзнең азагында Галимҗан юлдашка теләгебез озын гомер белән саулык. Гомере булса, ниятенә җитүенә иманыбыз камил.

Әхмәт Байтурсын улы.
24/28 – Кызыл Урда.

**Әдәбият**

*Байтурсынов А.* Галимҗан Ибраһимов төрк-татар уйчысы, төрк-татар белгече, төрк-татар язучысы // Безнең юл: Татарстан җөмһүрияте Мәгариф халык комиссариаты органы. 1928. № 2. Б. 17–18.

*Байтұрсынұлы А.* Қазақ тіл білімінің мәселелері. Алматы: Абзал-Ай, 2013. 640 б.

*Байтұрсынұлы А.* Әдебиет танытқыш // Байтұрсынұлы А. Шығармалары. Алматы: Жазушы, 1989. Б. 137–298.

Большая советская энциклопедия: в 30 т. 3-е изд. М., 1969–1978. Т. 9. С. 621.

*Сәтбаева Ш.* Әдеби байланыстар. Алматы: Жазушы, 1974. 215 б.

*Ысқақов Б.Ы.* Қазақ-татар әдеби байланысы. Алматы: Ғылым, 1976. 175 б.

https://ru.wikipedia.org/wiki

https://kk.wikipedia.org/wiki

***Жакупов Жантас Алтай улы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Л.Н. Гумилев исемендәге Евразия милли университеты*
*профессоры (Астана, Казакъстан)*

УДК 821.512.145

*Г.Р. Насибуллова*

# «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

В данной статье рассматривается отражение современной татарской литературы на страницах журнала «Казан утлары». Изучаются пути и способы влияния журнала на развитие и определения основных тенденций литературы.

**Ключевые слова:** современная татарская литература, литературный журнал, «Казан утлары».

Әдәби әсәрләрне халыкка беренчеләрдән булып җиткерүдә, төрле иҗат көчләрен туплауда һәм үстерүдә, әдәбият үсешенә этәргеч бирүдә һәм аны халыкка танытуда, кешелекне тәрбияләүдә журналлар-басмалар әһәмиятле роль башкара. Дөрес, соңгы елларда яшәешебезнең зур тизләнеш алуы, төрле электрон мәгълүмат чаралары, Интернет челтәренең үсеш алуы язма әдәби басмаларның мөһимлегенә йогынты ясамыйча калмый. Әмма республикабызның төп әдәби басмасы булган, гасырга якын тарихи дәвердә үз юнәлешен, үз урынын булдырган «Казан утлары» журналының дәрәҗәсе әлеге бу үзгәреш җилләре тәэсирендә җуелмый.

«Казан утлары» журналы үзенең яшәешендә татар әдәбиятының җәүһәргә тиң әсәрләрен халыкка җиткерүче мәйдан булып кына калмыйча, тагын да камилрәк әсәрләр иҗат итүгә этәргеч вазифасын да башкара. Басмалар аша татар әдәбиятының үсеш тарихын, үзенчәлекләрен күрергә мөмкин. Журнал һәрвакыт заман белән бергә атлый. Әгәр «Казан утлары»ның барлык саннарын бергә тупласаң, татар әдәбияты тарихын тулаем күрергә мөмкин, бу үзенә күрә бер антологиягә тиң җыентыкка әверелер иде.

«Казан утлары» укучысын яңа әсәрләр белән алар китап булып басылып чыкканчы ук, беренчеләрдән булып таныштыра. Бер яктан, башлап язучы өчен журналда әсәре басылу язучы яисә шагыйрь статусы алу белән тәңгәлләштерелсә, икенче яктан, укучыга барып җитү, танылу өчен киң мәйдан ача. Журнал күпсанлы яңа әсәрләрдән иң-иңнәрен сайлап алырга тырыша. Мәсәлән, 2016 елда журналда 36 шагыйрь иҗатына урын бирелә, 4 яңа роман, 13 хикәя, 8 бәян, 1 драма, 2 поэма жанрындагы әсәрләр басыла. Бу соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләр күләменең азлыгын билгеләми (алар бу саннардан шактыйга күбрәк), ә редакция хезмәткәрләре хезмәтенең катлаулылыгын күрсәтә.

Соңгы биш-алты елда «Казан утлары» журналында басылып чыккан әсәрләргә игътибар итсәк, проза әсәрләренең саны да, сыйфаты да үсү-үзгәрештә булуы күзгә ташлана. Басма аша хәзерге татар әдәбиятының темати-

касын билгеләргә мөмкин. Язучыларыбыз күбрәк игътибарны үткәнне тасвирлауга юнәлтә. Нигездә авылда туып-үсеп шәһәргә чыгып киткән кешенең язмышы яисә үткәнен сагынуы сурәтләнә. Мәсәлән, Ахирнең «Таш калада баш кала» (2014) романында әлеге проблема үзәктә тасвирлана. Шулай ук журналның соңгы елларында күп саннарда урын алган хикәя-бәяннар да күбесенчә үткәнне тасвирлау, үткәнне сагынуга багышланган. К. Кәримовның «Тургайлы болытлар» (2015) роман-элегиясендә дә бүгенге тормыш үткәннәр белән бәйләп тасвирлана. Бүгенге вазгыятьне, бүгенге проблемаларны чагылдыручы әсәрләр юк дәрәҗәсендә. Әдәбият галиме Т. Галиуллин да бер әңгәмәдә әлеге күренешкә борчылуын белдерә: «Язучылар арасында шундый күренеш сизелә – күбесе тарихка кереп киттеләр. Тарих – ул бер яклы трамвай. Артка чигенеп, аны тикшереп булмый. Теләсә нинди фантазия, хыял уены тарихи әсәрләргә бата. Әдәбиятны тарихи әсәрләр басты. Шуның аркасында диимме инде, хәзерге тормышыбызны чагылдырган әсәрләргә кытлык. Тарихны тикшереп булмый, анда ничек язсаң да ярый. Ә хәзерге тормышны чагылдырсаң, ул бөтен кешенең күз алдында. Алдалап язып булмый. Язучыга шуңа күрә дә хәзерге тормышыбызны чагылдыру күп тапкырлар кыенрак. Ләкин бүгенге хәлләрне без язып калдырмасак, киләчәктә хәзерге вазгыятебезне аңламаячаклар» [http://tatar-inform.tatar/news/2017/02/28/135910/]. Галим фикере әлеге күренешнең «Казан утлары» журналы кимчелеге генә түгеллеген, ә хәзерге татар әдәбиятының бүгенге халәте икәнен раслый.

Әлбәттә, «Казан утлары» журналы, республикабызның төп әдәби басмасы буларак, татар әдәбияты белән бергә атларга бурычлы. Журнал бүгенге үзгәреш-үсешләрне чагылдырып кына калмыйча, язучыларыбызга юл күрсәтергә, җитешсез якларны сиземләргә, аларны төзәтү яисә юкка чыгару өстендә эшләргә, үзгәрешләр кертергә дә сәләтле. Бу максаттан чыгып, «Казан утлары» журналы татар әдәбиятының «авырткан» урынын сизеп алырга һәм аңа ярдәм итәргә омтыла. Әдәбиятны төрле жанрлар ягыннан баету өлкәсендәге эшчәнлеге моңа дәлил. Әдәбиятны җанландыру, төрләндерү максатыннан журнал төрле конкурслар оештыра. Мәсәлән, «Иң яхшы хикәя», «Хикәя яза аласызмы?», «Иң яхшы чәчмә әсәр», «Яңа дәвер кешесе» кебек конкурслар хикәя жанры үсешенә йогынты ясамый калмады, хәтта әлеге өлкәдә эшләүчеләрнең күплеген һәм төрлелеген ачыкларга да ярдәм итте. Моннан берничә ел элек журнал иң яхшы повесть жанрындагы әсәрләргә конкурс игълан иткән иде, ул татар әдәбиятында сүлпәнләнеп баручы әлеге төр әсәргә уңай тәэсир ясады, язучыларыбызны дәртләндереп җибәрде. Әлеге конкурс аша авторларны эзләнүләргә этәргән яңа әсәрләр, яңа алымнар, яңа сюжетлар белән таныштык. Мәсәлән, бәйгегә килгән повестьлар арасында З. Хәкимнең бүгенге дөньяның саркастик

моделен чагылдырган «Сәер никрут», Р. Зариповның тормыш дөреслеген тасвирлаган «Милициянең йөз аклыгы» бәяннары игътибарга лаек. Әлеге конкурс-бәйгеләрнең әдәбият үсеше өчен тагын бер әһәмияте – яңа исемнәрне әдәби мәйданга чыгару.

«Казан утлары» журналы яңа исемнәрне, башлап язучыларны конкурс-бәйгеләр аша гына түгел, ә аларга аерым рубрикалар багышлап та эзләп табарга, әдәби мәйданга күтәрергә омтыла. Журнал басылып чыга башлаган көненнән үк әдәбият өлкәсенә аяк басучылар өчен үзенә күрә «әдәби капка» ролен башкарган. Татар әдәбияты тарихында урын алган олпат язучыларыбыз да заманында аның аша әдәби мәйданга үткән, танылу алган. Дөрес, бүгенге көндә әдәби басмалар шактый, вакытлы матбугат та әдәби әсәрләргә киң урын бирә, Интернет челтәре аша да укучы аларны табып укый ала. Әмма «Казан утлары» журналының рәсми булмаган «әдәби иләк» вазифасын үтәүче дәрәҗәле исеме актуальлеген югалтмый. Мәсәлән, соңгы елларда барлыкка килгән «Яңа исемнәр» рубрикасы әдәбият дөньясында билгеле булмаган яңа иҗатчыларны мәйданга чыгарды. Журналның 2016 елгы саннары аша без Эльвира Сафина, Лилия Фәттахова, Айсылу Хафизова кебек каләм тибрәтүчеләр белән танышабыз.

Соңгы елларда яңа бәйгеләр, рубрикалар белән беррәттән юкка чыккан, журнал битләреннән төшеп калган сәхифәләр дә бар. Мәсәлән, «Китапка күзәтү» рубрикасы соңгы еллар саннарында пассивлашты. Әлеге сәхифә яңа басылып чыккан китапларга күзәтү ясап, язучының хезмәтенә беренче бәясен биреп, укучыны яңалык белән таныштырып, аны укырга этәрүдә әһәмиятле роль башкара иде. Әлеге традиция дәвам иттерелсә яисә журнал битендә аерым әсәр хакында сөйләшүләр оештырылса, аңа анализ бирелсә, бу юнәлеш башлап язучылар өчен үзенә күрә бер дәрес, заманчалаштырып әйтсәк, мастер-класс булыр, татар әдәбиятын пропагандалауда, укучыны әдәби әсәрләр укырга этәрүдә мөһим роль уйнар иде.

«Казан утлары» журналы хәзерге әдәбият белән таныштырып кына калмыйча, бүгенге үзгәрешләргә укучысының бәясен, фикерен дә белергә омтыла, шулай ук әдәбият галимнәренең уйланулары, бәяләмәләре белән таныштырып бара. Мәсәлән, 2004–2005 елларда «Безнең заман герое кем ул?» дигән сорау куеп, әдәбият галимнәрен, тәнкыйтьчеләрне, язучы-шагыйрьләрне, укучыларын уйланырга, бәхәсләшергә этәрде. Соңгы елларда әлеге фикер алышулар төрле темаларга багышланган түгәрәк өстәл формасын да алды. Шулай ук журнал 2001 елда «XXI гасыр бусагасында. Әдәбиятыбыз кая бара?» дигән сорау куеп, галимнәрне, әдәбият белгечләрен уйланырга мәҗбүр иткән иде. Журналның берьеллык басмаларына бәя бирүгә багышланган, традициягә әверелеп бара торган «түгәрәк өстәлләр» укучыларга әдәбият галимнәре, тәнкыйтьчеләр фикерләрен җиткерү белән беррәттән язучыларга үз әсәрләренә

бәя ишетү, юнәлеш-алым сайлауда да зур роль башкара.

Соңгы елларда басылган саннарны күзәтсәк, мөхәррирләрнең язучы-авторларны төрлеләндерергә тырышуын күрербез. Дөрес, араларында бик еш яңгыраучы исемнәр дә бар. Мәсәлән, Айгөл Әхмәтгалиева, Әмирҗан Моталлапов. Әлеге күренеш бу язучыларның актив иҗат итүе белән беррәттән югары әдәби кимәлдә әсәрләр иҗат итүгә сәләтле икәнлеген дә аңлатадыр. Әмирҗан Моталлаповны мин, гомумән, «Казан утлары» журналының табышы дип атар идем. Бу язучы соңгы елларда укучыларны матур тел белән, кеше психологиясен һәм тормышны, милли үзенчәлекләрне тоеп язган әсәрләре белән сөендерде. Аның «Гамь», «Йөзә торган арба» әсәрләре әдәбият тарихында үз урынын алырга лаеклы.

Бүгенге көндә татар әдәбиятын башка халыкларга җиткерү шулай ук иң авыр мәсьәләләребезнең берсе булып кала бирә. Дөрес, рус теленә, соңгы елларда төрек теленә тәрҗемәләр башкарылуы сөендерә, ләкин Европа телләренә тәрҗемә бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Әйтик, классик әдәбиятыбызны инглиз теленә тәрҗемә итә алсак, ул мирас чит ил вәкилләре арасында үз укучысын тапмый калмас иде. Ә бит «Казан утлары» журналы башка халыкларның әдәби мирасын, тәҗрибәсен татар укучысына җиткерүдә зур роль башкарып килә. Соңгы елларда А. Егинның «Үзбәк хан» әсәре тәрҗемә ителеп, басма битләрендә урын алуы, казакъ язучылары әсәрләре белән танышу әнә шундый матур мисаллардан.

«Казан утлары» журналы бүгенге әдәбиятта барган үзгәрешләр хакында галим-әдәбиятчыларның фикерләре белән таныштыруга гына урын биреп калмый, ә басма саннарында урын алган әсәрләргә карата укучысының фикеренә дә зур игътибар бирә. Журналның «Кайтаваз» сәхифәсе әнә шул мөһим функцияне башкара. Биредә укучыларның уйланулары, төрле теләк-тәкъдимнәре, журнал эшчәнлегенә бәясе урын ала. Үзенә күрә журнал белән укучы арасында күпер формалаштырган әлеге сәхифә әдәбиятыбызның яшәеше-үсешенә үз өлешен кертә. Мәсәлән, соңгы саннарда без журналда күтәрелгән мәсьәләләргә карата Руфина Фаттахованың «кайтавазын» ишеттек. Әгәр язма укучыны битараф калдырмыйча, аны үз фикерен җиткерергә этәрә икән, бу инде журналның эшчәнлегенең дәрәҗәсен дә билгели.

«Казан утлары» журналы бөтен тарихы буена тел, милләт, аның яшәеше һәм үсеше сагында торды. Әдәби басма бүген дә әлеге әһәмиятле һәм катлаулы миссиясен дәвам итә.

**Чыганаклар**

1. http://tatar-inform.tatar/news/2017/02/28/135910/
2. http://kazanutlary.ru/

***Насибуллова Гүзәл Ришат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*

УДК 398.22:82.512.1-131

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова,*
*Г.Р. Әхмәтгалиева*

# «КАҺАРМАН КАТИЛ» ДАСТАНЫНДА УТКА ТАБЫНУ ЙОЛАСЫ ҺӘМ ДИНИ-МИФИК ИБЛИС ОБРАЗЫ ЧАГЫЛЫШЫ

В настоящей статье рассматривается отражение обряда поклонения огню, характеризуется религиозно-мифический образ Иблиса в дастане «Кахарман Катил», широко распространенном с XVIII в. у поволжских татар. Раскрывая глубину и оригинальность отражения огнепоклонничества и образа Иблиса в татароязычном письменном эпическом памятнике, авторы подчеркивают, что сюжет и мифические образы данного произведения поддерживают древние тюрко-иранские литературно-фольклорные взаимовлияния, а также пронизаны мусульманской идеологией.

**Ключевые слова:** дастан, текст, сюжет, Кахарман Катил, исламское войско, Иблис, религиозно-мифологический.

Татар дастаннары арасында «Каһарман Катил» яисә «Каһарман» дастаны исеме белән мәгълүм бик күркәм әсәр бар. Идел – Урал буе татарларында язма формада таралган әлеге эпосның XVIII йөздә Казан татарлары тарафыннан күчерелгән кульязмалары төрле фәнни үзәкләрдә саклана, ә XX йөз башыннан ул Казан типографияләрендә берничә кат басылып та чыккан.

Әлеге әсәрнең исеме татар әдәбияты тарихында күптәннән – XX гасырның егерменче елларыннан ук – билгеле булса да [Ибраһимов, б. 339], халыкта сакланган вариантларын табып алып, кабат басылып чыгуы XX йөз ахырында гына башкарылды. Гарәп язулы, татар телле «Каһарман Катил»не текстологик эшкәртеп, фәнни әйләнешкә кертүче – әдәбиятчы-текстолог, филология фәннәре докторы М.И. Әхмәтҗанов. Галим дастанның борынгы кульязмаларын эзләп тапкан, текстларны укып-өйрәнеп, телен бүгенге сөйләмгә якынайтып, этрафлы кереш сүз белән әсәрне аерым китап рәвешендә бастырып чыгарган [Каһарман Катил, 221 б.]. XXI гасыр башында филология фәннәре докторы Л.Х. Мөхәммәтҗанова тарафыннан бу әсәр беренче тапкыр, китаби дастан буларак, фәнни яктан шактый җентекле өйрәнелде [Мухаметзянова, с. 129–179].

Моннан тыш дастанның иң беренче табылган һәм иң тулы, камил саналган күләмле (270 кәгазьдән гыйбарәт) нөсхәләреннән бер өзек Төркиядә төрекчә дөнья күргән «Төркиядән читтәге төрки әдәбиятлар антологиясе»нең «Татар әдәбияты» дигән томына кертелгән [Каһарман китабы, б. 183–197].

Мәкаләбез «Каһарман Катил» дастанында әһәмиятле урыннарны алып торган сюжет-

ларның берсенә – утка табыну йоласы һәм уттан яратылган Иблис образының чагылышын күзәтүгә багышлана. Ул, төп чыганак буларак, дастанның бүгенге көндә иң тулы рәвешендә бастырылган вариантына – 1918 елгы гарәп язулы басмасы нигезендә М. Әхмәтҗанов тарафыннан китап итеп чыгарылган текстка [Каһарман Катил] нигезләнеп язылды.

Дастан гаять бай эчтәлекле. Биредә зур гына ике сюжет сызыгы аерылып чыга: аның берсе – дини-героик, ә икенчесе – әкияти-мифологик өлеш [Мухаметзянова, с. 148]. Дастан вакыйгалары аша алар бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә торалар. Әсәрдәге иң төп фикер – ислам диненең куәтен арттыру, иң төп вакыйга – ислам гаскәренең утка табынучы һиндләрне хак дингә бастыру өчен көрәшүе. Аллаһыга буйсыну, һәр эшне аңа тапшырып үтәү, Аллаһ кодрәтенә баш ию һәрвакыт әсәр вакыйгаларының төп таяну ноктасы булып кала.

Татар «Каһарман Катил»е үз эчтәлегенә борынгы Иран пластын да, фарсы мәдәниятенең мөселманлык дәверенә нисбәт итәрлек традицияләрне дә иркен сыйдыра. Биредә мөселман Ираны мәдәниятеннән күп иртә булган күренешләргә юлыгырга мөмкин. «Каһарман Катил»дә дошман патшасының һәм гаскәренең утка табынулары, утка сәҗдә кылулары турында берничә урында телгә алына. Сугыш тынып торган арада һәр ике як үзләренең мәетләрен урнаштыралар. Ислам гаскәренең вафат сугышчыларын җирләү оештырылса, һиндләр үз мәетләрен утта яндыралар.

Утка табынуның һәм мәетне утта яндыруның нигезләре бик борынгы чорлардан, хәтта утка табынучыларның шактый куәтле системаны тәшкил иткән китабы – Авестадан да күп иртә барлыкка килгән булуы мәгълүм. Үлгән кешене яндыру аның җаны югарыдагы зат – Аллага тизрәк күтәрелсен дигән максаттан башкарылган.

Тарихка мөрәҗәгать итсәк, борынгы Иран территориясендә, гарәп яулап алуларына кадәр, төгәлрәк әйткәндә VII–VIII гасырларгача, утка табынучылар дине – зәрдөштлек хөкем сөргән. Борынгы Иран диненең изге китаплар җыелмасы Авеста исеме белән мәгълүм, ә зәрдөштлек төшенчәсе шушы дингә нигез салган легендар пәйгамбәр Зороастр (Заратуштра) исеменнән килеп чыккан [Урманче, б. 37–39]. Диннең нигезендә Коръән белән бергә иңгән ислам дине тәгълиматына капма-каршы булган утка табыну ята. Шуның нәтиҗәсе буларак, мәңгелек ут гыйбадәтханәләре зәрдөштлек йолаларында хәлиткеч роль уйный. Үз чорында Иран территориясе тулысынча зәрдөштлек тәэсирендә булган. Авестаның аерым идеяләре Азия һәм Урта диңгез халыкларының дини карашларына, сәнгатенә, әдәбиятына көчле йогынты ясаган.

«Каһарман Катил» дастанында утка табынучыларның мәетләрне яндыру гадәте зәрдөштлек традициясе чагылышы булуы ихтимал. Әмма «зәрдөштлектә торучылар мәетне җирләмиләр

дә, яндырмыйлар да, кыргый хайваннар һәм кошлар ашап бетерсен дип, ачык килеш ташлап калдыра торган булганнар» [Урманче, б. 39] дигән мәгълүматка нигезләнсәк, мәетне яндыру гадәтен Авеста дине белән генә бәйләүнең хакыйкатькә туры килеп бетмәве ачыла. Дастанга һинд-иран дин тарихына бәйле реаль вакыйгалар да йогынты ясаган булырга мөмкин. Биредә бер нәрсә төгәл билгеле: мәетне борынгы зәрдөштлектәге кебек җир өстендә калдыру яисә яндыру бик борынгы гадәтләрдән булган, ислам исә моңа чик куйган. «Мәетне яндыру гадәтенең тамырлары Авестадан да күп иртә яшәгән традицияләргә үк барып тоташа. Әмма «Каһарман Катил» дастанында бу традицияләргә бәйлелек бик күренми, биредә әлеге йола исламда тыелган гамәл буларак кына килеп кергән булырга тиеш» [Мухаметзянова, с. 153]. Дастанда дошман ягының ислам гаскәре тарафыннан үтерелгән сугышчыларын яндырулары турында сүз алып баруны, чыннан да, исламның өстенлеген ассызыклау, ислам тәртипләренә каршы килә торган күренешне тәнкыйтьләү өчен кулланылган чара дип уйларга нигез бар. Үлгән кешене мөселманча күмү-җирләү тәртипләре дастанда утка табынучы дошманның үз мәетләрен яндыру ритуалына каршы куела. Биредә ислам гаскәренең төп дошманы – утка табынучы һиндләр гаскәре. Утка табынуның да, мәетне яндыруның да тарихи тамырлары б.э.к. чорларга ук барып тоташса да, дастанда бу традицияләрнең фәкать риваять характерында һәм фольклор контаминациясе кичергән булуы хак.

«Каһарман Катил»дәге утка табынучыларның Авеста нигезенә иярүчеләрдән шактый ерагайган булуын, шул сәбәпле күп кенә яклары белән зәрдөштлек традицияләрен ислам күзлегеннән яктыртып, бозып сурәтләвен дастандагы дини-мифик зат Иблис ачык чагылдыра. Авестада Иблис юк. Иблис (яисә аның Шайтан, Сатана һ.б. исемнәре) турында Зәрдөштлек китабында гомумән мәгълүматлар бирелми. Авеста китапларында утка табыну төп урыннарның берсен алып торса да, биредә ут Иблис белән бәйләнештә каралмый. Иблис – тамыры күп төрле чыганакларга барып тоташа торган гаять борынгы чыгышлы үтә катлаулы образ. Кайбер дини тәгълиматларда ул күренекле урын алып тора, ә кайберләрендә (мәсәлән, яһүдләр динендә) аның роле бик томанлы [Большая энциклопедия, с. 265].

Иблис – «дьявол»ның исламдагы исеме. Ә «дьявол» сүзенә «Зур энциклопедик сүзлек»-тә түбәндәге билгеләмә бирелгән: «грек сүзеннән – *diabolos* – сатана, җен, Иблис, кайбер диннәрдә (христиан, ислам һ.б.) явыз рух яки явыз рухларның башлыгы, Алла белән каршылыклы мөнәсәбәттә тора, җәһәннәм хакиме. Кайбер диннәрдә (христианлык, ислам һ.б.) Аллага каршы торучы явыз рух һәм явыз рухларның башлыгы; тәмуг хуҗасы» [Большой энциклопедический..., с. 419]. Иблис образы татар халык иҗатына һәм язма

әдәбиятка шактый тирән үтеп кергән. Әйтик, татар халкының «Күрәзәче карчык» әкиятендә ул – шайтаннар патшасы буларак тасвирланган мөстәкыйль персонаж. Фольклор жанрларыннан мөнәҗәтләрдә дә Иблис образы еш очрый.

Коръәндә Иблис (Шайтан, Сатана) – Аллаһы Тәгалә фәрештәләрне, җеннәрне һәм беренче пәйгамбәр Адәм галәйһиссәламне бар иткән вакытта ук яралтылган зат. Аллаһы әмере буенча нурдан яралтылган фәрештәләр дә, уттан яралтылган җеннәр дә Адәм галәйһиссәламгә баш ияргә тиеш булалар. Әмма җеннәрдән берсе – Газазил исемлесе Аллаһ әмереннән баш тарта:

– Мин аннан өстенрәк, чөнки мине уттан яралттың, аны балчыктан гына, – ди («Әгъраф» («Пәрдә») сүрәсе, 7: 12). «Иблис» сүзе гарәп телендәге «ул өметсез» дигән мәгънәне белдерә торган тамырга барып тоташа, ягъни Аллаһ рәхмәтеннән чыккан, төзәлергә өмете бөтенләй юк зат дигәнне аңлата. Димәк, Иблис зәрдөштлектән дә күп алда барлыкка килгән булып чыга. Иблискә Коръәндә шактый ачык характеристика бирелгән булуга карамастан, Иблисне Коръән персонажы дип тәкърарлау дөреслеккә туры килми, чөнки ул Коръәнгә кадәр Тәүратта (Торада) да, аңа кадәр дә шактый телгә алына. Әмма алай да Коръәнгә кадәр үк күп иртә барлыкка килгән бу зат турында мәгълүматның татарларга нәкъ менә Коръән аша кергән булуы бәхәссез, чөнки Коръәндә Иблис турында шактый тулы аңлатылган («Кәһаф» («Мәгарә») сүрәсе, 18: 48, 18:50; «Хиҗр» («Хиҗр иле» сүрәсе, 15:27; «Рахман» («Рахман») сүрәсе, 55: 15).

Татарларда дини эчтәлекле маҗаралы хикәят жанры гаять популяр булып, оригиналь сюжетлы, әмма аноним характердагы мондый әсәрләрдә дә Иблиснең бик еш тасвирлануы шулай ук әһәмиятле [Исмәгыйлев, б. 17–22; Гыйбрәтле хикәятләр]. «Кызыклы һәм гыйбрәтле мондый хикәятләрдә Иблис Коръәндә бирелгән характеристикасына тугрылыкны тулысынча саклый» [Мухаметзянова, с. 157].

«Каһарман Катил»дә дошман патшасы һәм гаскәре утка табына. Әмма каршы як, ягъни Һушән шаһның ислам гаскәре күзаллавы буенча, дошманнарның уты артында Иблис утыра, бу зат – аларның аллалары да. Һиндлар, имеш, «олуглап утка сәҗдә итәләр», аларның падишаһлары Раи Һинд утка: «Әй, минем мәгъбүдем, нур вә нур – ут!» дип мөрәҗәгать итә, уттан киңәш сорый. Һинд патшасы Раи Һинд уттан, Иран падишаһы белән сугышыргамы, әллә килешергәме, дип сорап торган бер вакытта «адәмнәрнең һәм диннең дошманы, Җәнабе Хактан сөрелгән Иблис ләгыйнь, утның артыннан ачулы тавыш белән» җавап бирә һәм җавабында, әлбәттә, сугышырга өнди, ягъни адәм балаларын котырта. Иблис образында сурәтләнгән Ут-аллаларыннан җиңү вәгъдә ителгәч, һиндләр сугышка күтәреләләр һәм шактый тәфсилле сурәтләнгән сугыш-орышлардан соң, ахырда, җиңеләләр.

«Каһарман Катил»дә утка табынучылар тоткан кыйбланың, Коръәндә тасвирланганча, уттан яралтылган, Аллаһ кушканны үтәмәве аркасында «өметсез» мөһере сугылган Иблис образына ни өчен килеп бәйләнгәнлеге аңлашыла. Утка табынучы кавемгә бәйле вакыйгаларны Иблис арадашлыгында сурәтләү татарларның уттан яралтылган бу зат белән Коръән аша таныш булуларыннан килә. Шуңа күрә архаик Иран катламына хас Авеста өйрәтүләре дастанда соңгырак чор күзаллаулар белән керешеп киткән дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Бу – утка табынучыларны тәнкыйтьләгән дастанның нигезен Коръән тәфсирләре белән бәйли торган игътибарга лаек элемент. Тамырлары Коръәннән дә алдарак торган чыганакларга барып тоташуына карамастан, бу эпизод «Каһарман Катил» дастанына Коръән сюжетлары аша кергән дигән нәтиҗәгә киләбез. Биредә Иблиснең дастандагы дини-мифологик өлештә түгел, ә дөньяви өлештә, ягъни әсәрнең дини-героика белән сугарылган өлешендә тасвирлануы да бу образның борынгы Иран яисә мәҗүси төрки мифологик эпосы белән бернинди уртаклыгы булмавын һәм аның әсәргә бөтенләй башка максатларда килеп кергәнлеген дәлилли.

Шулай итеп, татар дастаны үзенең сюжетында, образ-персонажларның исемнәрендә, әсәрнең типологик үзенчәлекләрендә фарсы-иран һәм төрки-иран эпик традицияләренә шактый зур тугрылык саклаган. Әмма биредә дини һәм мифологик мотивлар дастанның үзебезнең җирлектә дини-идеологик үзгәрешләргә дучар ителгәнлеген дә раслый. Утка табыну йоласын һәм Иблис образын бирүдә шулай ук татар-мөселман карашлары өстенлек алган. Ислам гаскәре дошманы булган һинд гаскәре сугышчыларының утка табынулары «Каһарман Катил» дастанында Идел буе татарларына хас дини фәлсәфәгә яраклаштырылган. Бу – дастанның шушында яшәүче халык ихтыяҗларын үтәүгә хезмәт итә торган әсәр булып формалашкан булуыннан килә. Димәк, «Каһарман Катил»дәге дини-мифик образлар, ислам динен тарату яисә ныгыту максаты белән бергә, халык яшәеше кануннарына, җирле үзенчәлекләргә буйсынганнар. Утка табыну йоласына бәйле һәм Иблис образына мөнәсәбәттә дастанда очрый торган күп кенә тарихи төгәлсезлекләр, фольклор контаминациясе – болар, һичшиксез, дастанның Идел буе мөселман татарлары карашларына ярашлы үзгәреш кичерүе нәтиҗәсе.

**Әдәбият**

Большая энциклопедия: в шестидесяти двух томах. М.: Терра, 2006. Т. 16. 592 с.

Большой энциклопедический словарь: в 2-х т. М: Советская энциклопедия, 1991. Т. 1. 863 с.

Гыйбрәтле хикәятләр / кульязмаларны басмага әзерләүче, хәзерге әдәби телгә күчерүче һәм рәссам-бизәүче – Нәҗип Нәккаш-Исмәгыйль. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 175 б.

*Ибраһимов Г.* Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Т. 5. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). 615 б.

*Исмәгыйлев Н.* Татар хикәятләрендә Иблис образы // Әдәби мирас һәм текстология. Икенче чыгарылыш. Казан, 2011. 148 б.

Каһарман Катил (дастан). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 221 б.

Каһарман китабы. (XVIII Yuzyil) // Baslangicindan Gunumuze Kadar Turkiye disindaki Turk Edebiyatlari antolojisi. T. 18. Tatar Edebiyati. II. Ankara: Kultur Bakanligi, 2001. 480 s.

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос: книжные дастаны. Казань: ИЯЛИ, 2014, 380 с.

*Урманче Ф.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. Казан: Мәгариф, 2008. Т. I (А – Г). 303 б.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*
*e-mail: lilmuhat@mail.ru*

***Әхмәтгалиева Гөлназ Рәфикъ кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге аспиранты*
*e-mail: gulnazero@mail.ru*

УДК 94(47).08

*И.К. Заһидуллин*

# МӨСЕЛМАН РУХАНИЛАРЫНЫҢ 1905 ЕЛГЫ УФА КОРЫЛТАЕ

В статье вкратце рассматриваются причины и проведение известной в исторической литературе как «Собрание улемов», или «курултай», совещания мусульманского духовенства, состоявшего 10–15 апреля 1905 г. в г. Уфе в здании Оренбургкого магометанского духовного собрания. Также перечисляются основные проекты по реформированию управления духовными делами мусульман округа. Констатируется, что уфимское совещание улемов стало важным событием на начальным этапе становления национального движения мусульман в 1905 г. Статья написана в качесте предисловия к проектам, публикуемым из книги Муса Бигиева «Ислахат әсаслары».

**Ключевые слова:** Первая русская революция 1905–1907 гг., уфимский курултай мусульманских духовных лиц (10–15 апреля 1905 г.), проекты реформирования управления духовными делами в округе Оренбургкого магометанского духовного собрания, Муса Бигиев, оренбургский муфтий М. Султанов, Р. Фахретдин.

Атеистик Россиянең дөньяви җәмгыятькә йөз белән борылуы, совет һәм марксистик-ленинчыл идеологиягә нигезләнгән фәнни эзләнүләргә тәнкыйди караш көчәю тарих фәнендә моңарчы өйрәнелмәгән яки махсус рәвештә тыелып килгән темаларга һәм фәнни юнәлешләргә юл ачты. Бу яңа күренешләр Татарстан гуманитар фәнен дә читләтеп узмады.

Диннең халкыбызның гореф-гадәтләрен, көнкүрешен, әхлак нормаларын, мәдәниятен формалаштыруга зур йогынты ясавы мөселманнар арасында ислам институтларының төрле тарихи чорларда тоткан урынын ачыклау мәсьәләсен махсус өйрәнү бурычы куйды. Соңгы елларда бу юнәлештә башкарыла торган фәнни эзләнүләрнең һәм теоретик, һәм сәяси, һәм гамәли әһәмияте артты. Мондый ихтыяҗның ике зур сәбәбен атап үтү зарур. Беренчесе – соңгы дистә елда дөньяда һәм илебездә мөселманнарга террористлар, экстремистлар һәм кешелек җәмгыятенә, гомумән гуманизмга каршы кара көч итеп карауның җәелүе һәм кайбер очракларда мондый карашларның хәтта өстенлек ала башлавы. Әлбәттә, исламофобия күренешләренә һәм нахакка гаепләүгә каршы төрле юллар белән каршы тору, көрәшү сорала. Икенчесе – диннең дәүләттән аерылган булуы шартларында җәмгыятебездә шәригать нормаларының яшәеше, төрле-төрле исемдәге мөфтиятләрнең, ислам институтларының үсеше, аларның эшчәнлеген заман ихтыяҗларына яраклаштыру мәсьәләсе.

Россия составында яшәгән дәвердә дәүләт – ислам мөнәсә-

бәтләренең эчтәлеге сугышчанлыктан килешүчәнлек ягына үзгәреш кичерә. Екатерина II заманында ислам диненә карата урнашкан түземле мөнәсәбәт Кавказ сугышы һәм 1863 елгы Польша восстаниесе йогынтысында кабат начар якка үзгәрә башлый. XIX гасырның икенче яртысында империя хакимиятенең мөселман булган кешегә шикчел мөнәсәбәте гадәти күренешкә әверелә. XX гасыр башында татарларны рәсми рәвештә панисламизмда, пантюркизмда, пантатаризмда гаепләгәннәр. Шул ук вакытта татарлар үзләренең дини һәм гражданлык хокуклары өчен мөмкин булганча көрәшкәннәр дә, яңа иҗтимагый шартларга яраклашырга да мәҗбүр булганнар. Гомумиләштереп әйткәндә, татар җәмгыятендәге моннан 100 элек булган халәт белән бүгенге иҗтимагый тормыш арасында күп кенә уртаклыклар табып була.

Югарыда аталган сәбәпләр йогынтысында Татарстанда соңгы ун-унбиш елда гуманитар өлкәдә мөселманнарның фикер сөрешенә һәм социаль тәртипләренә бәйле тема-сюжетларны өйрәнүгә игътибар арту күзәтелә.

Бүгенге тормышыбызга турыдан-туры кагылган шундый вакыйгаларның берсе – тарихи әдәбиятта «Голәмә җәмгыяте», яки «Корылтай», исеме белән мәгълүм булган 1905 елның 10–15 апрель көннәрендә Уфа шәһәрендә Мәхкамәи шәргыя Ырынбургия бинасында узган руханилар корылтае. Бу вакыйга хакында фәнни даирәләрдә мәгълүмат аз булуның берничә сәбәбе бар. Беренче сәбәп – Корылтайда кабул ителгән документның матбугат битләрендә күренмәве, ягъни киң җәмәгатьчелеккә барып җитмәве, һәм Эчке эшләр министрлыгының архивында югалуы. Чыннан да, беренче карашка, төрле купшы сүзләр сөйләп һәм азактан берни эшләнмәгән, кем әйтмешли, бәлеш ашау мәҗлесләре тарихыбызда аз түгел бит! Икенчесе – Мәхкамәи шәргыя Ырынбургия казыйлары һәм зыялылар тырышлыгы белән корылтай әзерләгән документ-проект мөселманнарның дини идарәләрен үзгәртеп коруга һич кенә дә йогынты ясамый. Корылтай карарларының исәпкә алынмавына һәм тормышка ашырылмавына империя хакимияте гаепле иде.

Безнең игътибарны Корылтайда яңгыраган яңа фикерләр җәлеп итте. Анда тикшерелгән мәсьәләләрдә, бирелгән тәкъдимнәрдә, проектларда Идел – Урал төбәгендә көн итүче төрле социаль катламга караган һөнәр ияләренең һәм җәмәгать эшлеклеләренең, гомумән, милләт язмышына битараф булмаган шәхесләрнең киләчәкне фаразлау планнары чагылыш тапкан. Аларда сүз дини идарәгә реформа ясау, ислам институтларының хокукларын киңәйтү, башка конфессияләр белән тигез хокукларга ирешү кирәклеге, шуның юллары турында бара. 1905–1907 еллардагы Беренче рус революциясе алып килгән демократия һәм сүз иреге шартларында якты киләчәк турындагы хыял һәм илдә тигез хокуклы гражданнар булу планнары белән сугарылган мөселман кардәшләребезнең моннан 112 ел элек

яңгыраган сүзләре тирән мәгънәгә ия булуы, ә кайвакыт самимилеге белән дә игътибарга лаек.

«Иттифак әл-мөслимин» партиясенең өч съездының дә сәркатибе сыйфатында утырышларның протоколларын алып барган, күренекле җәмәгать эшлеклеләре белән аралашкан Муса Бигиев, Россиядә һәм мөселманнар арасында җәелгән иҗтимагый хәрәкәтнең милли тарих өчен олы әһәмиятен аңлап, XX гасыр башы ислахат хәрәкәтенең барышын, аның күренекле сәхифәләрен киләчәк буыннарга җиткерү бурычын куя. Муса Бигиевнең 1904–1915 еллардагы Идел – Урал төбәгендә яңарыш хәрәкәтенә багышлаган «Ислахат әсаслары» исемле хезмәте 1917 елда Петроградта М.-А. Максутов типографиясендә басыла.

Китапның эчтәлеген күз алдына китерү өчен, аның бүлекләрен, аларда кузгатылган темаларны искә төшерү мәслихәт булыр. Алар түбәндәгеләр: Габдерәшит Ибраһимовның, 1904 елның көзендә һәм кышында Идел – Урал төбәге мөселман лидерлары белән аралашып, хөкүмәт исеменә гаризалар бирү кампаниясен һәм фирка оештыру буенча иҗтимагый эшчәнлеге; 1905 елның 10–15 апрелендә Мәхкамәи шәргыя Ырынбургия бинасында узган мөселман руханилары корылтае, анда каралган проектлар һәм кабул ителгән проект, аңа бәйле текстлар; 22, 23 һәм 25 июнь көннәрендә узган Уфа губернасы мөселман вәкилләре җыелышы карарлары; Министрлар комитетына петицияләр бирү кампаниясе һәм Идел – Урал һәм Кавказ мөселманнарының гаризаларында билгеләнгән төп мәсьәләләр; «Иттифак әл-мөслимин» партиясенең өч съезды һәм аларның карарлары; 1905–1907 елгы инкыйлаб көннәре һәм 1905 ел 17 октябрь манифесты; Русиянең көнчыгышында һәм көньяк-көнчыгышында яшәгән инородецлар башлангыч мәктәпләре өчен Халык мәгарифе министрлыгы кабул иткән 1906 ел 31 март Кагыйдәләре; китап төзүченең дини мәктәпләр, мәдрәсәләр хакында фикерләре; Дәүләт думасы карарлары һ.б. урын алган. Әйтергә кирәк, бу материалларның кануннарга, хакимият карарларына һәм эшчәнлегенә кагылышлылары – гомумбилгеле фактлар. Бүгенге көндә бу хезмәтнең «Иттифак әл-мөслимин» партиясе съездына кагылышлы өлешләре киң әйләнешкә кертелгән. XX гасыр татар иҗтимагый хәрәкәтенең төп юнәлешләрен һәм этапларын «дөрес бәяләмәләр» куеп билгеләгән Галимҗан Ибраһимов үзенең «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» [Ибраһимов, б. 212–435] исемле китабында Муса Бигиев текстын астөшермәләр куеп та, куймыйча да киң файдалана. Большевик-язучы шушы китаптан алган фактларга сыйнфый көрәш күзлегеннән бәя бирә. Муса Бигиевнең китабын шул рәвешле Беренче рус революциясе, «Иттифак әл-мөслимин» партиясе турында хезмәтләр язган башка татар тарихчылары да файдаланалар [Хасанов, 1985].

1905 елда Уфада узган мөселман руханилары корылтаен

яңача, уңай күренеш һәм җәелеп килүче яңарыш хәрәкәтенең мөһим бер вакыйгасы буларак, беренче булып, Төркиядә яшәп иҗат итүче тарихчы Надир Дәүләт бәяләде, үзенең «Русия төркиләренең милли көрәш тарихы (1905–1917)» исемле китабында шулай ук Корылтайда тикшерелгән проектларны да кыскача тасвирлады [Дәүләт, б. 75–79].

Россия галимнәре бу корылтай турында баштарак сүз уңаеннан, Беренче Рус революциясе елларында Идел – Урал төбәгендә формалашкан мөселман либераль хәрәкәтен өйрәнү кысаларында яки 1905 елгы милли хәрәкәтнең бер күренеше буларак, шул исәптән петицияләр бирү кампаниясенә бәйле рәвештә яздылар [Сенюткина, с. 31–32; Исхаков, с. 124; Фархшатов, с. 81 һ.б.]. А.Ю. Хабетдинов беренчеләрдән булып Корылтайда яңгыраган Ризаэддин Фәхретдин һәм Йосыф Акчура (тагын берничә татар бае) проектлары турында хезмәтләр бастырды [Хабутдинов, 2010, с. 166–167; Хабутдинов, 2011, с. 30–35; Хабутдинов, 2013, с. 73–75], И.К. Заһидуллин Йосыф Акчураның шушы өлкәдәге проектлары турында [Загидуллин, 2016, с. 123–127], Л.Ф. Байбулатова Ризаэддин Фәхретдиннең 1905 елгы проектын бәян итте [Байбулатова, с. 35–40] .

Ягъни корылтайда тикшерелгән Ризаэддин Фәхретдин һәм Йосыф Акчура, аларның фикердәшләре төзегән проектлар бүген инде фәнни әйләнешкә керде, дип әйтергә мөмкин. Ә менә башка, төрле яшьтәге, төрле фикердәге мөселманнар төзегән проектлар һаман да күз уңыннан читтә калып килә.

М. Бигиев, үзе корылтайда булмау сәбәпле, аның утырышлары турында катнашкан кешеләрдән ишеткәннәрен яза. Ул Корылтайда тикшерелгән проектларның текстларын кулга төшереп[1], аларны китабында сүзгә-сүз китергән дияргә мөмкин. Бу нәүбәттән «Ислахат әсасларын» хаклы рәвештә документлар чыганагы дип тә бәяләргә мөмкин. Дөрес, автор аларның кайберләрен бераз үзгәртеп, мәсәлән, Р. Фәхретдинекен [шунда ук, б. 75], яки кыскартып (Г. Дибердиевның 25 маддәдән торган проектыннан үзе мөһим санаган 14 маддәсен, Ш. Минушевның 33 маддәдән торган проектыннан башкаларда кабатланмаган 7 маддәсен генә урнаштыра) яза; шулай ук мөфти төзегән 70 маддәдән торган проект тәрҗемәсенең үзенең китапханәсендә сакланганын искәртә [шунда ук, б. 107], М. Солтановның премьер-министр С.Ю. Виттега 1905 ел 12 май көнне юлланган хатын татарчага шактый гадиләштереп тәрҗемә итә [шунда ук, б. 139–142].

Рус-япон сугышында Россия хурлыклы рәвештә җиңелүгә дучар булгач, җәмгыятьтә хакимияттән ризасызлык хисе көчле ташкын булып тышка бәреп чыга, төрле катлам вәкилләренең протесты хакыйкать, ирек һәм кимсетү-рәнҗетүгә каршы чыгышларга әверелә. Үзәк хакимияткә Санкт-Петербургта 1905 елның 6–8 ноябрь көннәрендә күпчелеге дворяннардан – самодержавиенең таянычы булган катлам вәкилләреннән –

торган губерна земство оешмалары җитәкчеләренең һәм башка земство әһелләренең съезды искитмәле йогынты ясый. Әле йокы халәтендә булган татарларны уятуда Габдерәшит Ибраһимовның иҗтимагый эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Төркиядән кайтып, руслар арасындагы иҗтимагый хәрәкәтне күреп, земство вәкилләренең съезды резолюциясендә язылган ил халыкларына демократик ирекләр бирү, һәркемнең канун алдында тигезлеген тәэмин итү һәм башка хокуклар турында таләпләрен укып әсәрләнгән Габд. Ибраһимовның якын киләчәккә планнарын формалаштыруда эчке эшләр министры либерал фикерле Святополк-Мирский белән очрашу хәлиткеч роль уйный. Илдәге «тәртипсезлекләр» турында хәбәрдар булган һәм хөкүмәтнең «җәмгыятькә ышаныч сәясәтен» тормышка ашыручы министр мөселманнарга да үз таләпләре белән үзәк хакимияткә мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә. Озак та үтми, 1904 елның 12 декабрендә, императорның махсус Указы дөнья күрә, анда илдә, шул исәптән дәүләт-чиркәү мөнәсәбәтләре өлкәсендә дә, киң масштабта реформалар уздырылачагы хакында хәбәр ителә. Һәркемнең канун алдында тигезлеген тәэмин итеп, кимсетүгә корылган кануннар юкка чыгарылачак, дип император Николай II үзе белдерә. Ышанмый кара.

Габд. Ибраһимовның төбәкләргә сәяхәт итеп, җирле мөселман җәмәгать эшлеклеләре белән аралашу-фикерләшүенең зур бер нәтиҗәсе булып 1905 ел 23 гыйнвар көнне аның инициативасы белән оештырылган һәм аның рәислегендә Казанда Әхмәт бай Хөсәенев йортында узган мәҗлесне атарга кирәк [Татария..., с. 47]. Анда хөкүмәт исеменә мөселманнарның ихтыяҗлары турында русча петиция бирү хакындагы карар кабул ителә, текстны язу Сәетгәрәй Алкинга йөкләнә. Габдулла Апанаев, Сәетгәрәй Алкин, Йосыф Акчура Казан мөселманнары вәкилләре итеп сайлана. Соңрак аларга сәүдәгәр Әхмәтҗан Сәйдәшев тә кушыла. Шушы вакыйгадан соң мөселманнар арасында Министрлар комитеты исеменә петицияләр бирү хәрәкәте җәелә, казанлылар депутациясе, мөселманнар арасында беренчеләрдән булып, 1 март көнне ул петицияне Министрлар комитеты рәисе С.Ю. Виттеның кулына тапшырып та кайта.

Шушы тарихи мәҗлеснең икенче көнендә Габд. Ибраһимов, Йосыф Акчура һ.б. кайбер фикердәшләр җыелып, Санкт-Петербургта гомум Русия мөселманнары исеменнән бер съезд ясау өчен, Кырым, Кавказ, казакъ, Төркестан мөселманнарына чакыру язу карарын кабул итәләр. Шулай итеп, Казанда Габд. Ибраһимов инициативасы белән ике зур чара бер вакытта диярлек башланып китә.

Министрлар комитетына төрле төбәкләрдән килгән петицияләрдә, үзәк мәсьәлә буларак, дини эшләр белән идарә итүне үзгәртеп кору, ислам институтларының хокукларын киңәйтү турында гозерләр еш кабатлана, шул сәбәпле 1905 елның 10 март көнне премьер-министр С.Ю. Витте

мөфти Мөхәммәдъяр Солтанов белән очрашканда руханилар катнашында мәҗлес ясап, шушы мәсьәләләрне тикшереп, «бер нәрсә» әзерләп хөкүмәткә җиткерү зарурлыгын күрсәтә [Исхаков, с. 124]. Биредә мөфтине һәм казыйларны мактап бер кәлимә сүз әйтәсе килә. Алар, тарихи мизгелнең әһәмиятен тирәнтен аңлаган хәлдә, С.Ю. Витте әйткән «бер нәрсә»не Мәхкамәи шәргыя һәм аның округына кергән ислам институтларының уставы рәвешендә эшләргә карар кылалар. Бу юнәлештә инде шактый фикер тупланган була.

Мөфти, озакка сузмыйча, гыйлемле, авторитетлы руханиларга телеграмма-чакырулар юллап, Уфага эндәшә. Чакыруның сәбәбе күрсәтелми: күпчелек яңа устав проекты әзерләү мәҗлесенә бернинди әзерлексез килә. Әмма әзерләнеп килүчеләр дә була.

Мөфти чакыруын игътибарга алып килгән 27–30 рухани һәм шәһәргә очраклы яки махсус рәвештә килгән берничә мулла, һәммәсе 39 имам[2] катнашында 10 апрельдә, якшәмбе көнне, иртә сәгать сигездә Мәхкамәи шәргыя Ырынбургия бинасының флигель залында корылтайны ачып, мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов кыска гына нотык тота. «Җәмәгать! Дини-иҗтимагый әхвалемезне ислах итмәк, әлбәттә, җөмләмезнең матлубыдыр. Шул көнге хәлемезне төзәтү үземез өчен никадәр матлуб исә, дәүләт өчен дә, хөкүмәт өчен дә матлуб улса кирәк. Төзәтү юлларын, ислах рәвешләрен һәрбер халык үзе, әлбәттә, яхшырак белер. Ислах итү тиеш хәлләрен халык күрсәтсә, хөкүмәт, әлбәттә, мөмкин кадәр кабул итәр.

Минем фикеремчә, ислах эшләре иң элек дини мәсьәләләрдән башланмак тиештер. Әлбәттә беләсез, дини эшләремез 11 нче том беренче кыйсем 6 нчы китапта язылган низам маддәләренә муафыйк иҗра кылынып килә. Буңа күрә, дини эшләремезне ислах итәек дисәк, әлбәттә, 6 нчы китап маддәләрен тәкъмил итеп тәгъдил итү [гадел хәл итү] тиеш улыр. Иштә хәзрәтләр! Оренбург, Кырым, Тифлис идарә руханияләренә гаид бөтен низамнар, төркичә тәрҗемәләре илә бәрабәр, яныгызда хәзердер. Моталәга кылыңыз, тиеш тәгъдилат хакында фикерләреңезне языңыз. Бәгъзе маддәләре бәлки истифсар [тулы аңлатуны сорау] хаҗәт улыр, буңа күрә, казыйларның бере һәрвакыт бу рәддә булыначактыр. Мөзакәрәләрдә иштирак шәрәфе миңа насыйп улмас. Үзеңез, иншалла, яхшы гына мөзакәрә итәрсез. Хәерле сәгатьтә!» [Җарулла Муса, б. 16–17]. Күрәбез, мөселман җәмгыятенең ислах эшләре иң элек дини мәсьәләләрдән башланырга тиеш, ислах ителергә тиешле мәсьәләләрне халык күрсәтсә, хөкүмәт аны кабул итәчәк дигән фикерне ассызыклап, мөфти мәҗлесне ачык дип белдерә.

Мөфти планлаштырганча, башта Корылтайда Кавказ арты сөнни мәзһәбтәге руханилар идарәсе һәм Ырынбургия мәхкамәи шәргыя уставлары кычкырып укыла. Әлбәттә, бу уставлар нигезендә генә әзерлексез килеш нинди дер яңа фикер әйтеп булмый. Моннан тыш, муллаларның дини

уку йортында гына белем алган булуларын, Россия кануннарын белмәүләрен, чамаласалар да, төгәл итеп әйтеп бирү кыенлыгын да күздән ычкындырмаска кирәк.

Корылтайның беренче көнге икенче утырышында ил тарихында тәүге тапкыр мөселманнар арасында, «Русия мөселманнарының дини хаҗәтләре бер, яшәп килгән дүрт дини идарә[3] өстенә тагын бер идарә лаземме, аерым-аерым берничә дини идарәнең булуына ихтыяҗ бармы, Русия мөселманнарының дини башлыгы шәйхелислам булырга тиешме», дигән сораулар тирәсендә бәхәс башлана [Җарулла Муса, б. 39–42]. Төрле фикерләр яңгырый, кайберәүләр баш дини идарә булса, Мәхкамәи шәргыя Ырынбургиянең дәрәҗәсе төшәргә мөмкин дигән фикер дә белдерәләр. Икенче көнге иртәнге утырышта сөйләшү дәвам итә. Ахыр чиктә, Корылтайда катнашучылар үзәк дини идарә оештыру фикерен дә, шәйхелислам институтын булдыруны да хупламыйлар.

Мөфти М. Солтанов устав проектын Корылтай тарафыннан эшләнергә тиеш дип саный, үзеннән гел гаеп эзләп торган муллаларның «алдан әзерләнгән документны кабул итәргә мәҗбүр иттеләр» дигән ямьсез сүзләрен ишетергә теләми. Муллалардан устав проектының нигезе булырлык фикерләр ишетүдән өмете өзелгәч кенә, ул казый Ризаэддин Фәхретдингә корылтайга әзерлек йөзеннән эшләнгән проектын тикшерүгә чыгарырга рөхсәт бирә. Ризаэддин Фәхретдиннең проекты – казыйның берничә ел дәвамында уйлаган фикерләренең нәтиҗәсе, иң соңгы тапкыр күчереп язган варианты була. Шул сәбәпле, аның 111 маддәдән торган тексты [шунда ук, б. 52–75] Корылтай проектының нигезе буларак кабул ителә.

Уфадан рәсми чакырулар җибәрелмәсә дә, Корылтайга дип, ахун-муллалардан тыш, сәүдәгәрләр, зыялылар да җыела. Алар турыдан-туры корылтай эшендә катнашмасалар да, сөйләнгән сүзләрдән хәбәрдар булалар, руханилар белән дә еш аралашалар. Корылтайда катнашучылардан Йосыф Акчура, Абүсогуд Әхтәмев, Ибраһим Акчура, Сәетгәрәй Алкин, Мәхмүт Хөсәенев, Мөхәммәтзакир Рәмиев, Мөхәммәтйосыф Дибердиев имзалаган устав проекты белән танышалар [шунда ук, б. 42–49]. Корылтайның дүртенче утырышыннан Р. Фәхретдин проекты белән танышу һәм аның буенча фикер алышу башлана.

Корылтайга җибәрелгән тагын берничә проект муллаларның карашларын киңәйтеп җибәрә. Алар Уфа мәдрәсәләренең 90 шәкерте кул куйган 28 маддәле петиция [шунда ук, б. 79–82], корылтайда катнашучы руханилар төзегән 18 маддәдән торган тәгъдимнәр [шунда ук, б. 83–84], Габдулла Дибердиев биргән проект [шунда ук, б. 84–85], Тау авылыннан имам Сәһман Исхакый язган гариза [шунда ук, б. 86–91], Казан өязе Кече Солабаш авылы имамы Хәсәнгата Габәшинең проекты [шунда ук, б. 99–105], Абүсогуд Әхтәмевнең Мәхкамәи шәргыя турында 6 маддәдән торган фикере [шунда ук, б. 105–106], Самара шәһәре ахуны Шиһабетдин

Минушевның проекты [шунда ук, б. 106–108] белән танышалар. Корылтайда катнашкан 12 мулла белән мәҗлесләрдә рәисе булган Казанның Печән базары мәчете имамы Габдулла Апанаев кул куя [шунда ук, б. 91–99].

Без Ризаэддин Фәхретдин һәм Йосыф Акчура (тагын берничә татар бае) проектлары белән танышуны мәкаләбез азагында урнаштырылган әдәбият исемлегенә юллап һәм бу басмаларны Интернеттан да табып булу хакында искәртеп, укучыларыбыз игътибарын мөселманнарның фикерләрен шәрехләргә мөмкинлек бирә торган башка проектларга юнәлтергә булдык.

Аларда кайбер фикерләр кабатланса да, мондый кабатлану очраклары фәкать аларның төрле катлам вәкилләре арасында киң таралуын раслаучы факт булып тора.

Муса Бигиевның «Ислахат әсаслары» китабыннан югарыда аталган петиция һәм проектлар текстларын гарәп имласыннан кириллицага Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе хезмәткәре Шәрәфиева Рәйсә Гамир кызы күчерде.

**Искәрмәләр**

[1] Ризаэддин Фәхретдин шәхси китапханәсеннән М. Бигиевкә танышу өчен үзендә булган проектларны бирә. Шулай ук, М. Бигиев кайбер документларны төзүчеләрдән алган, дигән хәбәрләр дә бар. Мәсәлән, аның үтенече буенча Хәсәнгата Габәши үзенең проекты текстын почта белән Муса Бигиевкә юллый [Заһидуллин, 2015, б. 128–129].

[2] 1) дәмулла Габдулла Габделкәрим улы Апанаев, Казан имамы; 2) дәмулла Галимҗан Мөхәммәтҗан углы Баруди, Казан имамы; 4) Шиһабетдин Хөснетдин Минуш, Самара ахуны; 5) дәмулла Хәлил Габдегалләм углы Сөләйман, Түбән Новгород шәһәре имамы; 6) Габдулла Габдегалләм углы Нигъмәтулла, Бубый мәдрәсәсенең баш мөдәррисе; 7) дәмулла Габделхак Гыймадетдин, Семипалатта имам-мөдәррис; 8) дәмулла Мөхәммәтсадыйк Госман, Сәгыйд бистәсендә имам-мөдәррис; 9) Габделваһап Габделбари углы Яушев, Петропавел шәһәрендә имам; 10) Мөхәммәтҗан Зәйнетдин углы Янгалыч, Саратов шәһәрендә ахун; 11) Габделгалим Габделгалләм углы Дәүләтшаһ, Оренбургта имам; 12) Мөхәммәтвәли Габделгани углы Хөсәен, Оренбургта мөдәррис; 13) дәмулла Мотыйгулла әфәнде Төхфәтулла, Җаек шәһәрендә ахун-мөдәррис; 14) Мөхәммәткасыйм Мөхәммәтгата хәзрәт углы Мансур, Солтанай авылында ахун-мөдәррис; 15) Мәсгуд әфәнде Билал, Югары Урал шәһәрендә ахун; 16) Сафиулла Максуд, Казан өязе Күлбаш авылында ахун; 17) Хыялетдин Хөсәен углы Хөсникәй, Пермь шәһәрендә мөдәррис; 18) Мөхәммәт углы Дәүликам, Касыйм шәһәрендә ахун; 20) Мөхәммәтйосыф Сәгыйд, Төмән өязе Манчыл авылында ахун; 21) Җәмалетдин Хәрәмшаһ, Бәләбәй шәһәрендә имам-хатип, ахун; 22) Мөхәммәтсабир Мөхәммәтҗан углы Хәсән, Уфа шәһәрендә имам-мөдәррис; 23) Хәйрулла хәзрәт Госман, Уфада мәшһүр мөдәррис, ахун; 24) Хәйрулла бине Габдерахман Госман, Сәгыйд бистәсендә мәшһүр имам-мөдәррис; 25) дәмулла Шәрәфетдин Хәбибулла хәзрәт углы Пати; 26) Хәйретдин Агаев, Мәскәү шәһәрендә ахун; 27) Хәмзә Хәмид, Томск шәһәрендә ахун; 28) хаҗи Гали Гайсә углы, Хан Урдасында ахун; 29) Сабирҗан Гомәр углы Мозаффар, Югары Урал шәһәрендә имам-мөдәррис; 30) Габдрахман Зәбир, Казан өязе Пәрши авылында имам; 31) Салахетдин Бәшир, Троицк өязе Миасс заводында имам-мөдәррис; 32) Габдулла Ибраһим углы Хәрәмшаһ, Стәрлетамак өязе Бозау Яз авылында

имам; 33) Гайнулла Качим, Нократ авылында ахун; 34) Хөсәен Сакал, Пашат авылы ахуны; 35) Мохтар Салах, Әстерхан губернасында ахун; 36) Гатаулла Баязид, Петроградта ахун; 37) Әхмәтшакир Сөендек, Әгерҗедә ахун; 38) Гайнелислам Әхмәтхаҗи углы Мөхәммәтҗан, Пешмә авылында имам-мөдәррис; 39) Мөхәммәтшакир Мөхәммәтхарис углы Тукаев [Җарулла Муса, 1917, б. 13–14].

[3] Русиядә дүрт дини идарә эшли: Тифлистагы Кавказ арты сөнни һәм шигый мәзһәбләрендәге руханилар идарәләре, Уфадагы Мәхкамия шәргыя Ырынбургия, Симферопольдәге Таврия мөселман дини идарәсе.

## Әдәбият

*Байбулатова Л.Ф.* Проект реформы Оренбургского магометанского духовного собрания в начале XX века // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств. 2015. № 4-1. С. 35–40.

*Дәүләт Н.* Русия төркиләренең милли көрәш тарихы (1905–1917) / төрекчәдән Р. Батулла тәрҗ. Казан: Милли китап, 1998. 399 б.

*Җарулла Муса.* Ислахат әсаслары. Пг.: М.-А.Максутов типографиясе, 1917. 288 б.

*Загидуллин И.К.* Юсуф Акчура о реформировании управления духовными делами мусульман // Симбирский научный вестник. 2016. № 1 (23). С. 123–127.

*Заһидуллин И.К.* Хәсәнгата Габәши хәтирәсе // Фәнни Татарстан. 2015. № 2. Б. 122–139.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит нәшр., 1984. 7 т.: Тарихи хезмәтләр. Б. 212–435.

*Исхаков С.М.* Первая русская революция и мусульмане Российской империи. М.: Общественно-политическая мысль, 2007. 400 с.

*Сенюткина О.Н.* Первый съезд мусульман России (к 100-летию проведения). Нижний Новгород: Махинур, 2005. 76 с.

Татария в дни первой русской революции / под ред. Х.Г. Гимади. Казань: Таткнигоиздат, 1955. 92 с.

*Фархшатов М. Н.* Петиции мусульман Волго-Уральского региона 1905 г.: о модернизации государственного устройства России // Исповеди в зеркале: межконфессиональные отношения в центре Евразии (на примере Волго-Уральского региона – XVIII–XXI вв.). Н. Новгород, 2012. С. 76–89.

*Хабутдинов А.Ю.* Оренбургское магометанское духовное собрание: планы реформ в начале XX в. // Оренбургское магометанское духовное собрание и духовное развитие татарского народа в последней четверти XVIII – начале XX вв.: материалы одноименного семинара, посвящённого 220-летию учреждения религиозного управления мусульман внутренней России и Сибири (Казань, 18 декабря 2009 г.). Казань, 2010. С. 163–175.

*Хабутдинов А.Ю.* «Голяма җәмгыяте» апреля 1905 г. и проекты реформ Риза Фахретдина // Фахретдиновские чтения. Материалы второй всероссийской научно-практической конференции «Инновационные ресурсы мусульманского образования и культуры: Вторые Фахретдиновские чтения». М.-Н. Новгород, 2011. С. 30–35.

*Хабутдинов А.Ю.* Институты российского мусульманского общества в Волго-Уральском регионе. М.: Изд. дом Марджани, 2013. 344 с.

*Хасанов Х.Х.* Казань в годы первого штурма царизма. Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. 191 с.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы,***
*тарих фәннәре докторы, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының Яңа тарих бүлеге мөдире*

# МӨСЕЛМАН РУХАНИЛАРЫНЫҢ 1905 ЕЛГЫ УФА КОРЫЛТАЕНДА КАРАЛГАН КАЙБЕР ПРОЕКТЛАР[1]

## Корылтайның соң мәҗлесләре

Апрель 12, сишәнбе көн иртә өченче мәҗлес башланды. Мөзакәрә [фикер алышу] остаз Риза әфәнденең ляихә мөсәүвидәсе [караламасы, черновигы] әүзәрендә иде. Проект язмак асан дәгел [җиңел түгел] исә дә, язылмыш проект маддәләренә игътираз [каршы сөйләү, кире кагу] итмәк, маддәләрне интикад [тәнкыйть] итмәк ул кадәр агыр дәгелдер. Буңа күрә, кыйль вә кал [имеш-мимеш, юк-бар сүз] игътираз вә җидаль [кычкырышу, талашу] күбәйде. Шул әснада [арада, чакта] «ляихәи әүвәл мөрәттәб [рәткә салынган, төзелгән] укып, тәмам итмәкме мөнасиб улыр? Яхуд һәрбер маддәне тәмам мөзакәрә итеп, тәдкыйк [җентекләп тикшерү] кылып кичмәкме мәгъкуль улыр?» мәсьәләсе зоһур итте [килеп чыкты]. Әксәрияте [күпчелек] карары илә икенче шәкъ [ярык, тишек] ихтыяр кылынып, һәрбер маддә галәхидә [аерым рәвештә, аеруча] мөзакәрә кылыначак, һәм дә кабул кылыначак маддәләр мәҗлес тарафыннан карар вирелмеш, гүя мәҗлес тарафыннан язылмыш хисап кылыначак улды. Наразый [риза булмаучы] адәмнәрнең үз фикерләрендә калмак ихтыярлары да бәян кылынды.

Дүртенче мәҗлес апрель 12 сендә өйләдән соң иде. Әүвәлге кеби маддәләрне мөзакәрә итмәк илә мәшгуль улды. Бишенче мәҗлес апрель 13 ендә, чәһаршәнбе көн иртә. Шул мәҗлестә ляихә мөзакәрәсе тәмам улды.

Апрель 13 ендә, өйләдән соң алтынчы мәҗлес башланды. Мөзакәрә кылынмыш маддәләр хосусында мәҗлес әгъзалары тарафыннан вирелмеш хосусый рәиләр [фикерләр] (мненияләр) укылды. Буңа магада [башка, бүтән] берничә бәяннамәләр кыйраәт кылынды [укылды].

Йосыф әфәнде Акчура каләме илә язылып, мөхтәрәм алты әфәнде тарафыннан имзаланмыш, 46 маддәдән гыйбарәт ляихә гаризасы югарыда (42–49 сәхифәләрдә) нәкыль [күчерү] кылынмыш иде. Иштә ул ляихә мәҗлес исеменә вирелеп, алтынчы мәҗлестә мөзакәрә юлында укылды. Бунның биркәсендә [аркасында] корылтай алында [кулында] гаять мөһим ике ляихә [проект] хасил улды: бере, әүвәлге ляихә – Риза әфәнде хәзрәтләренең ляихәсе; дигәре, икенче ляихә – Йосыф әфәнде каләме илә язылып «Тиҗар [сәүдәгәр] вә әгъян [югары дәрәҗәле түрәләр, башлыклар] ляихәсе» исеме илә аталмыш ляихә иде.

«Бунлара башка янә берничә проект укылды, күрелде исә дә, мөфти әфәнде тарафыннан язылмыш проект мәҗлескә вирелмәдегеннән, башкалары исә ялгыз дин мәсьәләләренә

[1] *Җарулла Муса.* Ислахат әсаслары. Пг.: М.-А.Максутов типографиясе, 1917. Б. 77–90.

гаид улмадыгыннан, анларны бу раддә [дәрәҗәдә] язмак зарурәте [үтә кирәклек] юктыр». Шул сүз «Корылтай» исемле әсәрендә остаз мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләренең сүзедер. Укылмыш проектларның бәгъзеләрен түбәндә, иншалла, бәлки нәкыль идәрем.

Апрель 14 ендә, пәнҗешәмбе көн иртә җиденче мәҗлес башланды. Әүвәлге мәҗлесләрдә натәмам [бетмәгән] калмыш байтак мәсьәләләр тәкрар [кабат] кылынды. Риза әфәнде ляихәсе илә Йосыф әфәнде ляихәсеннән кабул кылынмыш маддәләрне интихаб кылып [аралап алып] язмак өчен әгъзалар арасыннан дүрт адәм тәгъйин кылынды [билгеләнде]. Кабул кылынмыш маддәләрне тәртип кылып язмак вазыйфасы ике көн эчендә тәмам улып, мәҗлес әгъзалары тарафыннан да имзаланып, мөфти хәзрәтләренә тәслим кылынды [тапшырылды].

Апрель 15 ендә, җомга көн иртә сигезенче мәҗлес башланды. Шул мәҗлес мөзакәрә мәҗлесе улмаеп, бәлки корылтай мәҗлесләренең мөфти әфәнде тарафыннан ябылмасыннан гыйбарәт иде. Мөфти хәзрәтләре хәзрәтләргә шул сүзләрне сөйләде:

«Һәр нәкадәр юлларның фәна [юкка чыгу, бетү] вакыты исә дә, килеп, әһәмиятле мәсьәләләрне мөзакәрәләреңездән шатландык. Бөтен Русия мөселманнарына гаид мөһим мәсьәләләрдә аз адәм тарафыннан эшләнер исә, бөек ялгышлыклар булачагы бик мөмкиндер. Буңа күрә күп затларның иҗтимагы лазем улды. Ләкин мөфти улачак затны мувәкъкать [вакытлыча] сайламак мөселманнар өчен файдалы улмас, зан идәрем [дип уйлыйм]. Бунда бәнем өчен бер файда, бер зарар юктыр. Мувәкъкать сайланачак мөфтиләрнең хөкүмәт күзендә игътибары калмаса кирәк. Мәҗлесләреңездә мөзакәрә кылынмыш мәсьәләләрнең һәрберен айларча мөзакәрә итмәк тиеш исә дә, мөсагадә [булышу, ярдәм итү] кылынмыш мөддәт аз иде, мөзакәрәләрне мөмкин кадәр кыска итмәк лазем улды. Сезнең мөзакәрәләреңезгә мәәхәз [чыганак] улмыш бөтен мәгълүматны хәзер итеп куючы Риза казыйдыр. Риза әфәнденең шул тугрыда гаять бөек иҗтиһады [тырышлыгы] улды. Буңа күрә, бән үз тарафымнан аңа рәхмәт әйтәм. Инде мәҗлес шул сәгатьтән башлап ябылды. Аллһу тәгалә хәерле итсен».

Мөфти Мөхәммәдъяр әфәнде хәзрәтләренең шул сүзләре илә корылтай мәҗлесләре тәмам улды.

Корылтайның биш көн дәвам итмеш мәҗлесләре Русия мөселманнарының тарихында гаять әһәмиятле хадисәләрдән [вакыйгалардан] игътибар кылынмак тиештер. Собрание тарихында исә фәүкылгадә [гадәттән тыш] хадисә иде. Корылтай мәҗлесләренә тәкъдим кылынмыш гаризаларның, ляихәләрнең бәгъзеләрен бу раддә нәкыль итеп, буннан соң янә корылтай мәҗлесләренең карарларыннан бәхәс идәрез.

**Уфа шәкертләренең гаризасы**

Күптән көтелеп тә бүген генә сезнең риясәтеңез тәхетендә

[җитәкчелегез астында] тупланмыш «Җәмгыяте исламия»дә хосусы илә мәктәп, мәдрәсәләрнең, шәкертләрнең, руханиларның хәлләрен ислах чаралары мөзакәрә кылыначагына күрә, түбәндәге маддәләрне җәмгыятьнең мөхакәмәсенә [хөкем чыгаруга] без, таләбәләр тәкъдим иттек. Рәҗамыз [үтенечебез] сезнең һәм җәмгыятьнең илтифатына бәлки наил улыр [ирешер].

1) Мәгариф назыйрының [мөдиренең, министрының] һичбер мөдахәләсе [катышы] улмаеп, мәктәп-мәдрәсәләремез ялгыз собрание идарәсенә табигъ [буйсынучы] улса иде.

2) Мәктәп-мәдрәсәләргә мәҗлесләргә нәзарәт [күзәтү, идарә итү] өчен собраниедә аеруча шөгъбәләр булынып, назыйрларның, мөмәйизләрнең [яхшыны-яманны аеручы, акыллы] рәисләре ул шөгъбәләрдә әгъза улсалар иде.

3) Собраниедә әүкаф [вәкыфлар] өчен йәнә махсус бер шөгъбә булынып, бөтен әүкафларга һәм дә бөтен җәмгыяте хәйрияләргә нәзарәт итсә иде.

4) Собрание мәктәп-мәдрәсәләремезне дүрт дәрәҗәгә тәкъсим итеп; ибтидаия [башлангыч], рөшдия [башлангычтан югары (урта) мәктәп], игъдадия [мәдрәсәдә югары белем алуга хәзерләү класслары], галия исемнәре илә тәсмия итәр. Шул дәрәҗәләрнең һәрберендә өч сыйныф улып, мәҗмугы 12 дән; яхуд 4 сыйныф улып, мәҗмугы 16 дан гыйбарәт улыр.

5) Ибтидаи мәктәпләргә кабул кылынмак өчен яше сигездән аз улмамак, һәм дә һәр ай бер микъдар парә вирмәк мәҗбүри улса иде.

6) Рөшди мәктәпләргә кабул кылынмак өчен я ибтидаи мәктәп шәһадәтнамәсе, я дөхуль [керү] имтиханы шарт кылынып, һәм дә һәр ай бер микъдар парә вирмәк мәҗбүри улса иде.

7) Игъдади мәктәпләргә кабул кылынмак өчен йә рөшди шәһадәтнамәсе йә дөхуль имтиханы шарт кылынып, һәр ай бер микъдар парә вирмәк мәҗбүри улса иде.

8) Галия сыйныфларына кабул кылынмак өчен йә игъдади шәһадәтнамәсе яхуд дөхуль имтиханы шарт кылынып, мөгаен бер микъдар вирмәк мәҗбүри улса иде.

Шәкертләрдән мәктәп өчен алыначак микъдар, мәсәлән шөйлә [шул илә, шулай] улыр: ибтидаи мәктәп сыйныфларына сәнәлек биш рубль; рөшди сыйныфларына сәнәлек ун рубль; игъдадиларга 15 рубль; галия сыйныфларына 25 рубль улмак кеби.

9) Рөшдидән шәһадәтнамәсе бар зат ибтидаи мәктәптә мөгаллим ула булыр. Әгәр дә мөгаллимлек вазыйфасында хезмәте яхшы улмаса, мөәзин тәгъйин кылынса иде.

10) Игъдадидан шәһадәтнамәсе бар әфәнделәр рөшдидә мөгаллим, мәхәлләдә имам улыр.

11) Галия сыйныфларыннан шәһадәтнамәләре бар әфәнделәр игъдади мәктәпләрдә мөгаллимлек кылып мәләкә [өйрәнү, остару] тәхсил итсәләр, галия сыйныфларына мөгаллим улыр. Әгәр дә галия сыйныфларында мөгаллимлек кылып мәләкә тәхсил итеп яхшы хезмәт күстерсәләр

назыйр, мөмәйиз, мәгариф шөгъбәсендә әгъза, собраниедә казый улмак шәрәфләренә дә мөстәхикъ [хаклы, лаеклы] улыр.

12) Кабул парәсе һәр мәктәптә һәр сыйныфта шарт кылынса, мәктәп нәфәкасы [кирәк-ярагы] өчен бер микъдар парә, әлбәттә, тупланыр.

13) Никах мөһерләреннән һәр рубль башына өч тиен хәйрат сандыкларына вирелсә иде.

14) Талакта, хатын дәгъва итәр исә, рубль алмак, ир дәгъва итәр исә, өч рубль алмак рәсем [гадәт] улса иде.

15) Метрика дәфтәрләренә балаларның исемнәрен кайд иттермәк [беркетү, теркәү] өчен ля әкалле [иң кимендә] 20 тиен алынмак рәсем улса иде.

16) Фарыз садакалары тупламак өчен «гамил садака»лар нәсыб кылынып [билгеләнеп], һәр сәнә зәкят, гошер, фытыр, корбан кеби садакалар тупланып, җәмгыять хәзинәсенә тәслим кылынса иде.

17) Кирәк хөкүмәттән, кирәк башка бер җирдән мәгаш алучы әфәнделәр мәгашләреннән һәр ай ля әкалле бер процент җәмгыять хәзинәсенә вирсәләр иде.

18) Собрание идарә итмәк, мәктәп, мәдәрәсә, мәсҗед бина итмәк хосусларында дәүләт хәзинәсе тарафыннан азмы-күпме иганә вирелсә иде.

Шул 12–18 рәкымнарда күстәрелмеш мәбләгалардан [акча күләме] имамлык, мөгаллимлек, мәктәп-мәсҗед хадимнәренең мәгашләре бераз гына исә дә бәлки тәэмин кылыныр.

19) Һәр карьяда ибтидаи мәктәп; һәрбер бөек карьяда ибтидаи мәктәп өстенә рөшди мәктәп; мөселманнары күп өяз шәһәрләрендә ибтидаи, рөшди мәктәп өстенә игъдади мәктәп; вилаят шәһәрләрендә, мөселманнары күп улыр исә, бунларга башка янә бер гали мәктәп ачылса иде. Кызлар өчен дә һәр карьяда ибтидаиләр, бөек карьяларда рөшдиләр, шәһәрләрдә игъдадилар ачылса иде.

20) Мәдрәсәләрдә гарәби, фарси, төрек, татар, рус лисаннары тәгълим кылынып, голүме диниядән: хәдис, тәфсир, тарихе мөкаддәс, фәлсәфәи диния, гакаид, фикъһе, әдәбияте гарәбия, бәлягате гарәбия; фөнүннән: хисап, һәндәсә, җәгърафия, тарихе гомуми, тарихе рус, тарихе шәрекъ, хокукы дөвәл [дәүләтләр], рус кануннары тәгълим кылынса иде.

21) Волостьларда, һич улмас исә, өязләрдә, мөгаллимнәрне мөселман улмак шарты илә, хөкүмәт тарафыннан тиҗарәт, сәнагать, зирагать мәктәпләре бина иттерелсә иде.

22) Волостьларда, өязләрдә, вилаят шәһәрләрендә мөселманнар өчен дә кыйраәтханә ачылса иде.

23) Нә җирдә гали мәктәп вар исә, ул җирдә бөек бер көтебханә тәэсис кылынса иде.

24) Мәктәп-мәдрәсәләрнең низамнарына, програмнарына муафыйк дәрес китаплары тәэлиф иттермәк җәһәтләренә рәваҗ [таралу] вирмәк өчен, гүзәл дәрес китабы тәэлиф итәчәк әфәнделәргә хосусый бер имтияз [мактау кәгазе] вирмәк, каләм һәдиясе [бүләге] дә вирелсә иде.

25) Җәмгыять хәзинәсе хисабына, ятим балалар өчен тәрбия йортлары бина кылынып, аталары фәкыйрь балаларны ибтидаи, рөшди, игъдади, гали мәктәпләрдә тәгълим итмәк әҗерәсе [түләве] җәмгыять хәзинәсеннән вирелсә иде.

26) Җәмгыять хәзинәсе мөселманнарга махсус җәридә [газета], мәҗәллә [журнал] нәшер итсә иде.

27) Тәгълим һәм голүм эшләрендә хезмәтләре, мәһарәтләре исбат кылынган голәмәдән, җәмәгать эшләрендә иҗтиһадлары, әманәтләре, һиммәтләре күренгән адәмнәрдән мөрәккәб [бергә җыелган, кушма] бер һәйәт хаҗәт тәкъдирендә, могаен вакытларда дәгъвәт кылынып, мөселманнарның милли, иҗтимагый хаҗәтләре мөзакәрә кылынып торса иде. Мәктәп-мәдрәсәләрдә мәгариф юлларына җәмгыять хәзинәсеннән сарыф кылынмыш мәбләгъләры [акча күләме] ихтисаб иттермәк өчен хосусы илә һәр сәнә бер җәмгыять тәшкил кылынса иде.

28) Шул сәнә дәгъвәт кылынмыш «Галимнәр мәҗлесе» буннан соң һәр сәнә дәгъвәт кылынып, дини-иҗтимагый хаҗәтләремез һәрвакыр мөзакәрә кылынып торса иде.

Шул 28 маддәдән гыйбарәт гариза 90 шәкерт имзасы илә мөфти хәзрәтләренә, «Голәмә мәҗлесе»нә тәкъдим кылынмыш. Хәзрәтләрнең илтифатларына наил улып-улмамак мәсьәләсе бәңа мәгълүм улмады. Буннан соң да шәкертләрнең хәрәкәтләрен, иншалла, нәүбәтлә бәян идәрем.

**Мәҗлестә хазир дәгъвәтле хәзрәтләр тарафыннан имзаланып, хөкүмәттән соравы тиеш табылган эшләр:**

1) Мөселманнарга имин һәр җирдә мөселман руханилары хозурында улып ислам лисанында улса иде.

2) Ислам карьяларында ислам балалары өчен русский класс тәклиф кылынмаса иде.

3) Ислам хаҗиләренең паспортлары христиан паломникларының паспортлары бәһасендә улып, һәр җирдә һәрвакыт биля мөманәга [каршылыксыз] вирелсә иде.

4) Ислам гаскәри хокукта рус гаскәриләә бер дәрәҗәдә улса иде.

5) Ислам гаскәриенә тиешле кадәр имамнар нәсыб кылынып [билгеләнеп], ислам руханилары хокукта рус руханилары кеби улса иде.

6) Шәригате исламиядә хәрәм тәгамнан, шәраптан ислам гаскәри мәнгы кылынып, дини вазыйфаларын әда сәгатьләрендә һәрвакыт мөсагадә вирелсә иде.

7) Ислам галимнәренә, бәлки гомумиятьлә мөселманнарга русча уку тәклиф кылынмаса иде.

8) Имамнарның, ахундларның һәрберенә хәзинә мөһере вирелеп, эш кәгазьләре почтада мәҗанән [түләүсез, бушка] йөртелсә иде.

9) Руханиларның һәрбере гаскәрлек хезмәтләреннән азат кылынса иде.

10) Заграницада тәхсил итмәк руханилык, мөгаллимлек, мөдәррислек хезмәтләренә манигъ кылынмаса иде.

11) Нә рәддә табигъ кылынмыш исә дә, яхуд дәстхат

[кулъязма] улса да, дини китаплары укытмактан манигъ булынмаса иде.

12) Коръән кәримгә, шаригъ хәким галәйһи әс-салат вәссәлам хәзрәтләренә, динемезгә тагын юлында язылмыш бәндәләргә рисаләләргә мокабил, хакыйкатьне бәян итеп җавап язмак мәҗбүриятенә һәрвакыт мөсагадә вирелсә иде.

13) Компанияләр, ширкәтләр тәшкил итмәк, Русиядә һәр җирдә милек ала белмәк хосусларында мөселманнарның хокуклары руслар илә бер дәрәҗәдә улса иде.

14) Диннәрен, лисаннарын, язуларын белүләренә шәһадәтнамәләре юк ислам балалары рус мәктәпләренә кабул кылынмаса иде.

15) Кыргыз, казак, төркмән балаларын мәктәп-мәдрәсәләремездә укытмактан; кыргыз, казак, төркмән арасында мөгаллим, имам, мөдәррис улмактан манигъ итмәк алга кылынса иде.

16) Башка диннәрнең беренә мөртәд улачак мөселманнарны алты һәфтә вәгазь итеп, шөбһәләрен хәл итмәк хакы голәмәләргә вирелсә иде. Бөлүгъдан элек иртидад хакы һичбер сурәт илә вирелмәсә иде.

17) Падишаһлык бәйрәмнәреннән, үзләренең дини бәйрәмнәреннән башка вакытларда эш туктатмак, сәүдә вә дөкяннәрен япмак мөселманнарга тәклиф кылынмаса иде.

18) Әхлакларын төзәтеп, дини әдәпләрен бәян итмәк өчен үз лисаннарында җәридә, мәҗәллә нәшер итмәк хакы мөселманнарга да вирелсә иде.

**Габдулла әфәнде Диберди тарафыннан күндерелмеш гаризада 25 маддәдән бәгъзеләре:**

1) Мәктәп, мәдрәсәләр ялгыз собрание идарәсендә улып, дахилия назарәте дә мәгариф назарәте дә мөдахәлә итмәсә иде. Ибтидаи мәктәпләремезгә, дини мәдрәсәләремезгә хөкүмәтнең мөдахәләсе динемезгә хөкүмәтнең мөдахәләсе кебидер. Дәүләт мәслихәтләре ноктасыннан да мөдахәлә файдасыздыр. Инспекторларның, миссионерларның мөдахәләләре укудан мөселманнарның күңелләрен биздерде, халыкта әхлак фәсадына сәбәп улды.

2) Собрание голүме диния тәгълименә махсус мәктәп-мәдрәсәләргә һәр шәйдән зиядә әһәмият виреп, һәрбер карьяда мәхәллә хезмәте илә мәшгуль имамнан башка, мәхәллә хезмәтләренең һичбере илә мәшгуль түгел бер мөдәррис я бер мөгаллим тәгъйин итсә иде.

3) Әүкаф, зәкят, хәйрат кеби мәнбәгъләрдән бер сәрмая тупланып; мәктәп, мәдрәсә, мәсҗедләрне тәрбия өчен собрание хозурында бер комиссия тәшкил кылынса иде.

4) Руханиларны, мөгаллимнәрне, мөдәррисләрне һәм нәсыб итмәк һәм гозел итмәк ялгыз собрание ихтыярына махсус кылынып, шул хосусларда вилаять правленияләренең мөдахәләләре катгый сурәттә алга кылынса иде.

5) Яңабаштан мәктәп, мәдрәсә, мәсҗед биналарына рөхсәт вирмәк ялгыз собрание ихтыярына хәсыр кылынып, консисторияләрнең христиан идарәи

руханиялрнең һичбер сурәт илә мөдахәләләре булынмаса иде.

6) Бер мәхәллә үзенә мөгаллим я мөдәррис таләп идәрсә, сәнәви мәгашләрен тәэмин итә белер кадәр мәбләгый җәмәгатьтән имзалар илә илтизам иттереп, хөкүмәт мәэмүрләре васитасилә һәр сәнә әһалидән әү мәбләгъ тупланып собрание васитасилә сахибләренә тәүзигъ [тарату, өләшү] кылынса иде. Әгәр дә мәхәлләдән туплана булачак мәбләгъ мәктәпнең мөгаллимнәрнең нәфәкаларына кифаять итмәс исә, собрание тасрифында булыначак маядан тәкмил кылынса иде.

7) Цензура тәмам ләгу кылынып [бетерелеп], үз лисанымызда җәридә, мәҗәллә нәшеренә там хөррият вирелсә иде. Чит мәмләкәтләрдән ислам китапларын җәлеп итмәк цензор назарыннан азат улса иде.

8) Руханилар гаскәрлектән азат улып, имамәт өчен яшь шарт кылынмаса иде.

9) Никах өчен алына торган 25 тиен өстенә янә 75 алынып, мөселманнарның мәгариф сәрмаясенә тәхсыйс кылынса иде.

10) Ислам балаларына махсус приютлар мәгариф назарыннан алынып, собрание идарәсенә тәслим кылынса иде; мөгаллим, мөгаллимәләрне, мөрәббияләрне мөселман улмак шарт кылынса иде.

11) Төркестанда, Русия мәмләкәтләренең һәр җирендә җир вә милек алмак хокукы мөселманнарга руслар илә бер дәрәҗәдә вирелсә иде.

12) Керәшен исемендәге мөселманнарның хәлләре хакында мәгълүмат тупланып, хокукы динияләренә мөсагадә алмак хосусларында мөнасиб юллардан хәрәкәт кылынса иде. Ягъни рәсмән ислам танылып мәхәлләләренә мәктәп, мәсҗедләренә рөхсәт вирелсә иде.

13) Кыргыз, казакъ, төркмән араларына варып балаларын укытмак мөгаллимнәремезгә манигъ кылынмаса иде.

14) Русиядә, шаять, халык представительләренең парламенты була калса, һәр җирдә үзләренең гадәдләренә күрә мөселманнардан да вәкилләр сайланса иде.

### Тын карьялардан бөек тавыш

Мөхтәрәм казый Ризаэддин әфәнде хәзрәтләре!

Уфада апрель 10 нда бөек галимнәр иҗтимаг итеп милләт эшләре хакында мөзакәрә, мөшәвәрә итәчәкләре мәсмугатымыздан улды [хәбәре ишетелде]. Ул илә бөек мәҗлесләргә хазир улмак шәрәфләренә безем кеби гаҗиз имамнарның истихкаклары, салахиятьләре юк исә дә, милләт намына исламият файдасына фикеремезне язып, сезгә күндермәк безгә һаман ваҗиб улса кирәк.

Русиядә бөтен милләтләрнең хөррияте динияләре хакында 1904 сәнә декабрь 12 ндә император хәзрәтләренең фәрман шаһанәләрен күреп укып шатландык, әтраф галимнәре илә мөзакәрәләргә, мөшәвәрәләргә чумдык. Ул бөек фәрман шаһанәдән истифадәмезне арзу итеп, 1905 сәнә январь 24 ндә Гундыр ярмаркасында җитмештән зиядә галимнәр тупланып, мөшаварә соңында император хәзрәтләре-

нә дүрт мәтлабтан гыйбарәт гаризамызны күндермәк карарын кабул иттек. Гаризамызны хәзерләдек. Голәмә, әгъниядән 200 гә кариб имза илә гаризамызны тиеш мәхәленә [урынына] күндердек. 1905 сәнә февраль 18 ндә император хәзрәтләренең янә фәрман шаһанәләрен күреп, ялгыз руханилар улмак шарты илә бәнем ханәмдә янә тупландык. Русия мөселманнарының ихтыяҗларын сөйләдек. Иң мөһимнәрен 6 маддә әүзәренә ихтисар итеп, Петербургта яңа ачылмыш назыйрлар шурасының рәисе Витте хәзрәтләре намына күндердек. Без, руханилар, боралларда һәрнә кадәр мәхәлли хөкүмәт кешеләренең бөек тәһдидләренә [куркыту, янауларына] гөрефтар [тоткын] улып торсак та, мөселманнарның шул көнге форсатларын хәтердән чыгармаеп, мөселманнарның колакларына үзләренең хаҗәтләрен тәлкыйн итүдән, император хәзрәтләренең гадаләтләрен, мәрхәмәтләрен рәҗа вә нияз иттерүдән һичбер вакыт кире тормадык. Соң гаризамызда күстерелмеш матлаблар шулдыр:

1) Мөфти голәмәдән улып, интихаб хакы мөселманнарның үзләренә тәслим кылынмак. Собрание казыйларны да шул илә. Рухани эшләр бөтен тәфригате илә, мәсәлән, руханиларны насыб итмәк, гозел итмәк, дәрәҗәләрен рәфыг итмәк, мәктәп, мәдрәсәләрне, мәсҗедләрне идарә итмәк, биналарына изен вирмәк, һәммәсе собрание алында улыр. Рухани эшләргә башка мәхкамәләрнең һичбер мөдахәләсе улмас. Һәм дә руханиларга илзам кылынмыш русча фәсех кылынмак, руханилар хезмәт гаскәриядән азат улмак.

2) Никах, талак, мирас кеби гаилә мәсьәләләре бөтен фөругаты илә шәригате исламия ысуллары әүзәрендә иҗра кылынып, мал дәгъвалары да ислам галимнәренең фәтваләренә, казаларына күрә катгы ителсә иде.

3) Ислам гаскәриләре шәригате исламиядә хәрәм тәгамнардан, шәраплардан сакланса иде, мөселманнарга диннәрен тәлкыйн итеп дини вазыйфаларын әда иттерү өчен һәр полкта имамнар нәсыб кылынса иде, рамазан шәрифтә рузаларына мөсагадә вireп, ашлары-сулары руза сәгатьләренә күрә улып, хезмәтләре дә руза көннәренә күрә асанлаштырылса иде.

4) Диннәргә һәр җәһәт илә хөррият вирелеп, матбугатта да хөрриять вирелсә иде.

5) Русларга вирелмеш бөтен мәдәни хокук мөселманнарга да вирелсә нииде. Мәсәлән, мәхкамәләрдә хаким улмак, русларның мәктәпләрендә мөгаллим профессор улмак, уфак бөек идарәләрнең һәрберендә чиновник улмак кеби.

6) Руханиларга дахили, хариҗи паспорт вирә белмәк собрание ихтыярында улса иде.

Гадаләтле, мәрхәмәтле император хәзрәтләренең декабрь 12 сендәге фәрман шаһанәләре Русиядә бөтен тәбәгаларга хөррият, мөсавәт, гадаләт, сәгадәтләрен ихсан итте. Шул бөек өч кәлимә ялгыз кәгазь өстендә язылып кына калмаеп, бөтен халыкның көндәлек хәятләренә, хаҗәтләренә дә татбикъ кылынмакларын һәммә

халык арзу итәләр. Безем мөселманнарның иң мөһим хаҗәтләре дә, бөтен хокук та руслар илә мөсави улып, Русиядә яшәмәк, эш күрмәктер. Шул көн хокукларның әксәреннән мәхрүмиятемез өчен дә, ачылмыш милләт мәҗлесеннән хокукымызны милләт өчен таләп итмәгә хакымыз, әлбәттә, вардыр.

Мәгълүм, безем ислам галимнәре нәсари руханиларыннан сад мәрхәлә әдвән вә әсфилдер. Җөмлә милләтләрнең һәрбер хокук гомумиядә бәрабәрлеге гадаләтнең иң беренче шартыдыр, сәмәрәседер.

Таләп кылыначак безем хаҗәтләремез дә, хокукларымыз да бигүк күп, хокукларның дәрәҗәләре дә мөтәфавиттер [төрледер]. Мәсәлән: ибтидаи мәктәп мәсьәләләрендә һәр җәһәт илә там хөррият хакы ибтидаи мөкаддәс бер хакымыз исә, әксәрияте исламнан гыйбарәт вилаятьләрдә вәлиләре, губернаторлары мөселманнардан тәгъйин итмәк милли шәрәфемезнең хакыдыр. Бу илә улса иде, хөкүмәттә дә бу бөек файдалар мәнфәгатьләр хасыйл улыр иде. Халык тәгълим, тәрбия җәһәте илә тиз тәрәккый итәр иде, хөкүмәтнең бөтен фәрманнары да асанлыкла нөфүз итәр иде.

Русча белмәк, ихтыярый сурәттә рус мәктәпләрендә тәрбия күрмәк безем өчен гаять файдалыдыр, бәлки һәр җәһәт илә заруридыр. Ләкин һәрбер кавемнең, һәрбер милләтнең ана лисанында иң әүвәлге тәрбиясе иң әүвәл арзу кылыначак хаҗәтләрдәндер. Буңа күрә, ислам карьяларына бина кылмыш һәм кылыначак сельский школаларда русча нәкадәр укылса, мөселманча да ул кадәр укытмак һәм халык өчен, һәм хөкүмәт өчен һәр җәһәт илә файдалыдыр. Русча һәркөн 3 сәгать дәрес вирелсә, мөселманча да ул кадәр; русча укучыларга бөтен хаҗәтләре земстводан вирелсә, мөселманча укучыларга да вирмәк лазем. Русча учитель һәр ай 25 рубль алса, мөселман мөгаллиме дә, мөгаллимәсе дә ул кадәр алмак, әлбәттә, тиештер. Сельский школаларда русча уку шул көн өч сәнә исә дә, мөселманчасы илә бәрабәр биш сәнә улса, нә улыр. Русча дәресләрдән инспектор имтихан итәр исә, мөселманча дәресләрдән ислам галимнәренең бере яхуд махсус тәгъйин кылыначак бер мәмйиз имтихан итәр. Юкса, хәзерге кеби һәфтәдә бер-ике дәфга барып, һәфтияк һәҗаләрен [иҗекләрен] дә белдермәмәк шарты илә укытмактан нә бер мәгънә, нә бер файда хасыйл улыр. Балаларның гомерләрен заегъ итмәктән башка бер файда чыкмас.

Халыкның лисаны да хөкүмәт лисаны да бер дәрәҗәдә гүзәл ысулда укытылса, халык өчен дә, хөкүмәт өчен дә бөек файдалары хасыйл улыр. Алмания, Англия, Австрия кеби мәдәни мәмләкәтләрдә шул ысул җаридер [кулланыладыр]. Шуңа күрә ул мәмләкәтләрнең халкы басыйрәтледер, тәрбияледер.

Хәзерге һәм киләчәк балаларның күзләрен ачып, бөтен Русия мөселманнарының гүзәл истикъбальләрен тәэмин итмәк өчен, мәктәп-мәдрәсәләремезнең начар җәһәтләрен тәмам

төзәтмәк һәм дә мөнтазам [тәртипкә салынган] ысул истикамәтендә [дөрес юнәлешендә] тәгълим-тәрбия юлларын бүген хәзерләмәк безгә, әлбәттә, һәр шәйдән зиядә лаземдер. Башка һәрбер милләт уянып, җанланып, иҗтиһад итеп торганда, без һаман әүвәлгечә гафләттә калыр исәк; мәгърифәтле, мәдәниятле милләтләрнең иң дүн [түбән] хадимнәре улып калачагымыз кояш кеби заһирдыр.

Мәктәп-мәдрәсәмезне ысуллы тәгълим тәрбиямезне ислах өчен, әлбәттә, безгә сәрмая лазем улачак, парә лазем улачак. Мөкаддәс Коръән кәрим әмере илә бөтен мөселманнарга фарыз кылынмыш гошер, зәкят, фытыр, корбан кеби садакалары милли бер хәзинәдә, бәйтелмалда гамәлләрнең иганәсе илә тупласак, ма хасилның ля әкалле өчтән берен мәктәп-мәдрәсә юлларына сарыф итсәк, бәкыясы мәхәллә руханиларына дәрәҗәләренә, хаҗәтләренә күрә тәүзигъ кылынса гүзәл улмасмы? Хөкүмәт буңа, иншалла, мөсагадә итсә кирәк. Зирә һәм хөкүмәткә, һәм бөтен мөселманнарга файдалыдыр.

Русия мөселманнарының шул көнге хәлләрдән нәҗатлары [котылу] өчен ике шәй лаземдер: бере мәктәп-мәдрәсәләрнең интизамы, дигәре галимнәрнең милли, дини хаҗәтләремезне мөшавәрә мөзакәрә хакында иттифаклрыдыр. Руханилар, галимнар иттифак итсәләр, соңра милләтне дә эш берлегенә дәгъвәт итсәләр, һәр мөшкелнең чарасы булыныр.

Гадаләтле император хәзрәтләренең фәрман шаһанәсе илә милләт мәҗлесе дәгъвәт кылыныр исә, хәмиятьле, мәгълүматлы, моктәдир мөселман вәкилләрен интихаб итеп күндереп, Милләт мәҗлесе трибунасында үз таләпләремезне гарыз иттермәк, бөтен хокукларымызны хөкүмәт һәм вәкилләр хозурында химая иттермәк безгә, әлбәттә, лазем улачактыр. Ислам вәкиле кылыначак адәмнәргә хокукы исламия, исламиятне, мөселманнарның хәлләрен, хаҗәтләрен һәр җәһәтлә гүзәл сурәттә белмәк, әлбәттә, тиеш улса кирәк. Ялгыз русча белү кяфи улмаса кирәк, Милләт мәҗлесендә ислам галимнәреннән хәмиятьле, бәсыйрәтле, мәгълүматле затлар исбат вөҗүд итмәк иң арзу кылыначак әмәлләрдәндер.

Шул көннән соң, Уфада һәр сәнә бер мөнасиб мөгъйин вакыт галимнәр, мәгариф әсхабы, бәсыйрәт әрбабы иҗтимаг итеп, мөселманнарның мөһим хаҗәтләре хакында мөзакәрә мөшавәрә итә торсалар, милләт тиз заманда җанланып яңа хәят юлларына аяк басар иде.

Шул көнге иҗтимагый хәлемезгә интикад күзе илә нәзар итәр исәк, өмид вирә белерлек бер нур һәрбер җәһәттә күренмәс. Мәктәп-мәдрәсәләремезнең һичбере тәэмин кылынмаган. Дөрест, бәгъзе бер һиммәтле хәмиятьле бай әфәнделәр тарафыннан бина кылынмыш гүзәл генә мәдрәсәләремез вар исә дә, мөрәббиләре киттекеннән соң ул мәдрәсәләрнең дә хәлләре тәэминсез калачактыр, буның өстенә 15–20 миллион мөселман өчен 5–10 мәдрәсә тәмам юк мөнәсәбәтендәдер. Сәрмаяләре азлыктан улса кирәк, җәмгыяте хәйрияләремезнең халык өчен бәрә-

кәтләре аздыр. Нә диик, хәлемезнең гакыйбәте хәер улса иде.

Аурупа мәктәпләренә иң истигъдадлы таләбәләремезне тәхсил тәрбия өчен күндереп, һәр сәнә ля әкалле [иң кимендә] 30–40 таләбәмезне, тәхсил тәмам итмеш яшь егетләремезне кайтарып тормак, ислам мәркәзләренең һәрберендә һөнәр мәктәпләре, санагать мәдрәсәләре ачып ислам балаларын һөнәр, санагать юлларына сәвекъ [юнәлтү] итмәк, безем өчен һәм лазем һәм мөмкин исә дә, ләкин шул көнге хәлемезгә хиссиятемезгә күрә, ялгыз бер хыялдыр.

Ихтыяҗларымыз хакында без бәлки дәһа зиядә язар идек, ләкин сүз язуда файда юк, әһәмият юк. Бөтен әһәмият эштә. Инде эш кирәк!

1905 сәнә, апрель 6 сында.

Имзалар:

Уфа вилаяте Бөре уезды, Тау карьясында имам Сәһман Исхакый хәзрәт ханәсендә тупланмыш хәзрәтләр.

Әтраф карьялардан имам Сәһман әфәнде ханәсендә тупланып мөзакәрә итмеш хәзрәтләрнең остаз мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләре исеменә шул мәктүпләрне «Тын карьялардан гаять бөек тавыш» иде. Шул мәктүпнең, бәнем нәзарымда, бер кач җәһәтлә гаять бөек әһәмияте вардыр.

1. Бере мохтасарлыгы илә бәрабәр җамигъ улмак җәһәте. Корылтай мөзакәрәләрендә кабул кылынмыш карарларның бөтен әсасларын җамигъдыр; байтак мөһим зиядәләре дә вардыр.

2. Хәзрәтләрнең мәктүбе улмак җәһәте. Иң хөрриятле зыялыларымызның фикере дә шул мәктүпнең фикереннән тугры, ачык улмас. Карья хәзрәтләре арасында бу илә cималарны күрмәк безгә һәм шатлык һәм өмид вирер.

3. Соң 10 сәнә эчендәге съездлар карарларының бөтен милләт карары, бөтен милләт таләбе икәнлегенә гаять ачык далаләт итмәк җәһәте. Почтадан озак һәм дә матбугат нурларыннан мәхрүм карьяларда, съезларның һәрбереннән мөкаддәм бер заманда язылмыш бер мәктүп карарларының бөтен әсасларын җәмигъ итмеш исә, карарларның һәрбере бөтен милләтнең калебеннән чыкмыш улыр.

Мәктүпнең бөтен әһәмияте дә бу раддә шул җәһәттәндер.

*Текстны гарәп имласыннан кирилл алфавитына күчереп,*
*сүзлекне һәм аңлатмаларны Казан федераль университетының*
*Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә хезмәткәре*
***Шәрәфиева Рәисә Гамир кызы** әзерләде*

УДК 94(47).08

***Ч.Д. Миңнемуллина***

# КАЗАН ӘҖНӘБИ УКЫТУЧЫЛАР СЕМИНАРИЯСЕНДӘ МУЗЫКА УКЫТУ (XIX гасырның икенче яртысы)

В работе описан процесс становления музыкального образования в Казанской инородческой учительской семинарии. В статье рассматривается организация музыкальных занятий в этом учебном заведении, а также прослеживается роль Степана Васильевича Смоленского в развитии хорового пения на языках коренных народов Поволжья, оказавшего огромное влияние на становлении духовности воспитанников семинарии.

**Ключевые слова:** Казань, Казанская инородческая учительская семинария, музыкальные занятия, церковный хор, инородцы, С.В. Смоленский, Н.И. Ильминский.

Урта Идел буе халыкларына милли белем бирүнең формалашуында Александр II нең Бөек реформалар дәвере мөһим чор булып санала. Бу процесста Казан әҗнәби (җирле халык өчен ят телле) укытучылар семинариясе, Казан үзәк керәшен-татарлар мәктәбе аеруча зур роль уйный. Казан укытучылар семинариясен тикшеренүчеләр бу уку йортын бак хаклы рәвештә профессор, семинариянең беренче директоры Николай Иванович Ильминский системасын тормышка ашыруның уникаль үрнәге дип саныйлар [Исхаков, с. 105].

Казан укытучылар семинариясе авыл мәктәпләре һәм халык көллиятләре өчен укытучылар әзерләүче урта уку йорты булып санала. Анда, руслардан тыш, Россия империясенең көнчыгышта яшәүче күпсанлы милләтләр вәкилләре дә белем ала. Бу мәкаләдә сүз семинариядә тәрбияләнүчеләргә музыкаль сәнгать нигезләрен өйрәтүнең әлеге уку йорты бурычларын үтәүгә ничек ярдәм итүе хакында барачак.

Идел буендагы «рус булмаган» халыкларны православиегә тартуда музыкаль сәнгатьнең ролен чиркәү идеологлары һәм реформага кадәрге чор җәмәгатьчелегенең зыялылары яхшы аңлыйлар. Мәскәү университеты профессоры С.А. Рачинский, мәсәлән, болай дип яза: «Пение – единственная отрасль обучения, в которой успехи могут быть оценены непосредственно даже безграмотным родителем учащихся, возбуждает живой интерес в сельских жителях всех сословий» [Русская духовная..., т. 3, с. 357]. Россиядәге башка телле халыкларга музыкаль белем бирүнең әһәмияте дәүләт дәрәҗәсендә дә югары бәяләнә. Н.И. Ильминскийның Россия империясе халык мәгарифе министры Д.И. Деляновка язган отчетында мондый юллар бар: «Святейший синод считает чрезвычайно сильным орудием для привлечения язычествующих и магометанствующих инородцев к христианству употребление, согласно давним традициям пра-

вославной церкви, инородческих языков при церковном богослужении» [Ильминский, с. 12].

Музыкаль белем бирү, Казан укытучылар семинариясенә кадәр үк, Н.И. Ильминский тарафыннан оештырылган Казан үзәк керәшен-татар мәктәбендә актив алып барыла. Әйтик, XIX гасыр урталарында анда белем алучылардан чиркәү хоры оештырыла. Аны Алтай миссионеры, Мәскәүнең булачак митрополиты, Николай Ильминскийның якын дусты иеромонах Макарий башлап җибәрә. Ул Казанга Алтай миссиясе башлыгы, архимандрит Владимир тарафыннан керәшен-татар мәктәпләре оештырып, аларның эшен җайга салу максаты белән җибәрелгән була. Н.И. Ильминский гыйбадәт кылуны һәм чиркәү вәгазьләрен аз санлы халыклар телләрендә алып бара башлауга зур әһәмият бирә. Аның фикеренчә, бу ысул рус телен белмәүчеләрне чиркәү догаларының мәгънәсенә төшендерергә һәм аларны православие диненә тартырга ярдәм итәргә тиеш була [Колчерин, с. 126]. Һәм керәшен-татар мәктәбендә гыйбадәт кылу һәм догалар укуны әкренрәп татар телендә алып бара башлыйлар.

1871 елның августында керәшен татар мәктәбендә укучылар хорына Александр II каршында чыгыш ясау бәхете насыйп була. Император Казанда бөек кенәзләр белән Идел буйлап сәяхәт иткәндә тукталган була [Загоскин, с. 254–255]. Укучылар хоры император каршында татар, чуваш һәм чирмеш телләрендә «Коткар, Аллам»-ны («Спаси, Господи») башкара. Александр II аларның чыгышыннан бик канәгать кала. Изге Синодның 1880–1905 еллардагы обер-прокуроры К.П. Победоносцев та Казанга визиты вакытында бу уку йортында укучыларның музыкаль осталыгын югары бәяли. Н.И. Ильминский турындагы фикерләрен теркәгән хәтирәләрендә ул болай дип яза: «Все, имевшие случай посещать эту школу и слышать в церкви ее богослужение и пение на татарском языке, выносили оттуда истинную, восторженную радость русского сердца о том, чего могут достигнуть русские люди, связуемые любовью» [Победоносцев].

Н.И. Ильминский, Макарий Казаннан киткәннән соң да, татар телендә гыйбадәт кылуны дәвам итүдән туктау урынсыз дип саный. Керәшен-татар мәктәбе укучылары хорының яңа җитәкчесе вазифасын Василий Тимофеев үз кулына ала [Колчерин. с. 127].

Н.И. Ильминский, керәшен-татар мәктәбендә башка телләрдә алып барылган чиркәү җырларының уңышлы йогынтысын тоеп, Казанның әҗнәби укытучылар семинариясендә дә хор сәнгатен куллана башлауга зур игътибар бирә. Бу уку йортының, башлангыч мәктәп укытучыларыннан тыш, башка телдәге халыклар яши торган мәхәлләләр өчен руханилар (священниклар) әзерләвен дә истә тотып, семинаристларны укыту программасында чиркәү җырларына киңрәк урын бирелә башлый. Чиркәү идеологлары фикеренчә, «хор оештыру» һәр руханиның һәм чиркәү старостасының турыдан-туры бурычы булып исәпләнә, шуңа күрә семинарияне

тәмамлаган һәркем хор оештыру һәм аның белән җитәкчелек итү сәләтенә ия булырга тиеш санала [Русская доховная…, т. 3, с. 388].

Семинариядә музыканы беренче булып Степан Васильевич Смоленский укыта башлый. Ул, Казандагы Икенче ир балалар гимназиясен тәмамлаганнан соң, Казан Император университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Студент елларында С. Смоленский музыкаль квартетларда катнашып, бик оста итеп скрипкада уйный. Нәкъ менә университетта укыганда ул хорда җырлау белән кызыксына башлый. Н.И. Ильминский белән С.В. Смоленскийны якын туганлык берләштерә. Н.И. Ильминский Казан әҗнәби укытучылар семинариясенә нигез салучы Степан Васильевичның туган апасына өйләнгән була. 1875 елда университетны тәмамлаганнан соң С.В. Смоленский, Н.И. Ильминский тәкъдиме белән, Казан әҗнәби укытучылар семинариясендә географиядән һәм җырдан укыта башлый. Семинариядә эшләвенең беренче елларда ул чиркәү җырларына өйрәтү алымнарын эшләү белән мәшгуль була. Аңа кадәр бу фәнне укытуның нигезле методикасы булмый әле. С.В. Смоленский укучыларның музыкаль белем дәрәҗәсен җырлау күнекмәләрен музыка теориясенә нигезләп тирәнәйтә бару аша күтәрергә омтыла. Мәсәлән, аның инициативасы белән семинаристларга сольфеджио дәресләре кертелә башлый [Русская духовная…, т. 3, с. 189].

1880 елларда инде аның эшчәнлеге нәтиҗәсе булып, җыр укытуның эшкәртелгән һәм шактый ныклы формалашкан методикасы барлыкка килә. Ул музыка дәресләрен өч төрле итеп уздыруга нигезләнә. Беренчесенә музыка теориясе, сольфеджио дәресләре керә. Әлеге алымнар семинарияне тәмамлаучыларга алга таба авылларда хорлар оештырырга ярдәм итәргә тиеш була [Ильминский, с. 19]. Икенче төре практик характерда була. Бергә җырлаганда хор чиркәү җырларын хәтеренә сеңдерә һәм аларны чиркәүдә җырлый. Мондый дәресләр атнага 3–4 тапкыр уздырыла. Өченче төр итеп, семинариядә белем алучыларның музыка коралларында (аерым алганда, скрипкада) уйнарга өйрәнүен санарга кирәк.

Рус һәм башка телләрне укыту программасы нигезендә чиркәү тарихлары, Иске һәм Яңа Гаһедләр турында сөйләгәндә музыкаль күнегүләрдән файдалана торган булалар. Шунысы кызык, андый музыкаль дәресләр программасы татарлар, чувашлар, чирмешләр һәм арлар өчен аерым төзелә. Күрәсең, монда ул телләрдәге укучыларның әзерлек дәрәҗәсе дә истә тотылгандыр. Н.И. Ильминский нәтиҗә ясаганча, керәшен татарлары дини яктан да, гомуми әзерлек, аеруча рус телен белүләре буенча да башкалардан өстенрәк булалар. Семинария директоры күзәтүләреннән мәгълүм булганча, аларның кайберләре кабул итү сынауларын рус мәктәпләрендәге яхшы укучылар белән бер дәрәҗәдә тапшыралар Н.И. Ильминский сүзләренә караганда, семинариягә килгән чувашлар күп яктан татарлардан түбәнрәк саналсалар да, арала-

рында рус телен шактый яхшы белгәннәре дә очрый. Чирмешләр белән арларны Н.И. Ильминский болай дип бәяли: «почти без исключения, весьма слабыми и в отношении общего развития, и в отношении знания русского языка» [Ильминский, с. 11]. Ә татар укучылар музыкаль күнегүләр буенча яхшы әзерлекле булулары белән аерылып торалар, чувашлар, арлар һәм чирмешләр исә Чиркәү җырлары, Литургияне һәм Пасха догаларын чиктән тыш уяулык, тырышлык белән генә ятлап башкара торган булганнар [Ильминский, с. 32].

С.В. Смоленский эшчәнлеге белән семинариядә Казанның күп кенә уку йортлары өчен үрнәк саналган хор оеша, шулай ук «Курс хорового пения» китабы да аның тырышлыгы нәтиҗәсе. Степан Васильевичта белем алган семинаристларны, бу уку йортын тәмамлаганнан соң, башка уку йортларына җыр укытучысы яки чиркәү хоры регентлары итеп чакыралар. С.В. Смоленскийның укучыларын хәтта Казан әҗнәби чиркәү хорының беренче җитәкчесе Макарий да югары бәяли. Бийскида епископ, шулай ук Алтай һәм Кыргыз миссияләре башлыгы Макарий 1891 елның 26 апрелендә С.В. Смоленскийга түбәндәге юлларны язып җибәрә: «Характер Вашего пения мне весьма нравится. Заключаю об этом по пению некоего Ташкинова, учившегося в Казанской учительской семинарии, состоявшего в Вашем хоре и теперь регентствующего в Улалинском хоре» [Воспоминания. Казань, Москва–Петербург, с. 531].

Казан әҗнәби укытучылар семинариясендә 15 ел эшләгәннән соң С.В. Смоленскийны Санкт-Петербургның Синод дәрәҗәсендәге җырлаучылар көллиятенә директор вазифасына билгеләр. Әмма бу педагог китсә дә, аның белем бирү системасы таркалмый, XX гасыр башына кадәр аны укытучылар Н.И. Суворов белән Н.А. Александров тиешле югарылыгында дәвам итәләр.

**Әдәбият**


*Загоскин Н.П.* Спутник по Казани. Иллюстрированный указатель достопримечательностей и справочная книжка города. Казань: DOMO «Глобус», 2005. 837 с.

*Ильминский Н.И.* Отчет Казанской учительской семинарии за 1889–90 и 1890–91 учебные годы. Казань, 1892. 36 с.

*Исхаков Р.Р.* Страницы истории Казанской учительской (инородческой) семинарии // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств. 2015. № 4–1. С. 105–108.

*Победоносцев К.П.* Из воспоминаний об Н.И. Ильминском // Русский вестник. Февраль 1892.

Русская духовная музыка в документах и материалах: в 8 т. М.: Языки славянской культуры, 2002.

*Колчерин С.А.* Православная миссия через просвещение: школы Н.И. Ильминского во второй половине XIX – начале XX вв. // Христианское чтение. 2013. № 1. С. 114–135.



***Миңнемуллина Чулпан Рамил кызы,***
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*Өр-яңа тарих бүлеге аспиранты*
*e-mail: minchulpan@mail.ru*

УДК 94(=512.145):314.74

***Окан Таһир***

## ФИНЛЯНДИЯ ИСЛАМ ҖӘМГЫЯТЕ[1]

Статья освещает историю и деятельность Общества татар Финляндии, объединяющего представителей Исламского общества Финляндии в Хельсинки и Общества мусульман Тампере, организованного в 1943 г. Показаны пути успешной интеграции татар в финское общество, подробно анализируется опыт совместных социальных и культурных практик.

**Ключевые слова:** Общества татар Финляндии, татарская диаспора в Финляндии, интеграция татар в иноязычной и инорелигиозной среде.

**Финляндиядәге татар азчылыгы бу ил шартларына тулысынча интеграцияләшкән.** Алар, эшчән ватандашлар буларак, Финляндия тормышына тиз җайлашалар, шул ук вакытта үз җәмгыятьләрен дә саклап калалар. Татар җәмәгатьчелеге читтән ярдәм алырга теләми, үз тотрыклылыгы аркасында яхшы биналар били, ике зиратны тәртиптә тота алалар. Бу – аларга яңа килеп кушылган мөселман иммигрант төркемнәр өчен үрнәк булып тора.

### Кереш

Татар җәмгыяте Финляндиянең тарихи һәм милли азчылыкларын берләштергән җәмәгать оешмаларының берсе булып санала. Бүгенге көндә Финляндиядә чыгышлары белән төрки булган 700 гә якын мөселман татар кешесе яши, аларның күпчелеге (600 гә якыны) Финляндиядә электән яшәп килгән ислам җәмгыятенең (Suomen Islam-seurakunta) әгъзасы булып тора, ә 100 кеше, 1943 елда Тампере шәһәрендә оешкан ислам җәмгыятенә тупланган. Бу җәмгыятьләрнең әгъзалары, нигездә, Патша Россиясе заманында Идел буендагы Түбән Новгород губернасының фин-угор, мордва һәм руслар белән күрше булган татар авылларыннан чыккан татарлар. Алар, кечкенә күләмдәге җирләргә ия буларак, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнгәннәр, ләкин торабара, чәчүлек җирләре кимеп файда китерми башлагач, авыл хуҗалыгы белән бергә сәүдәгәрлек өлкәсендәге эшчәнлекләрен дә башлап җибәрәләр. Әкренләп аларның сәүдәгәрлек сәфәрләре тимер юл буйлап Санк-Петербургка, хәтта Териоки (бүгенге Зеленогорск) аркылы Бөек Фин-

[1] 2017 ел Финляндия бәйсезлегенең 100 еллыгы уңаеннан Финляндия милли азчылыклар хокукларын саклау төркеме 2016 елның азагында «National Minorities in Finland a Richness of Cultures and Languages» исемле җыентык бастырып чыгарды. Китапта Финляндиядә яшәүче төрле милли азчылыкларның көнкүреше һәм тормышы турында мәгълүматлар бирелгән. Биредә шулар арасыннан татар азчылыгын тәшкил итүче Финляндия ислам җәмгыяте турындагы мәкаләнең татар теленә ирекле тәрҗемәсе тәкъдим ителә.

ляндия кенәзлегенә һәм Выборгка кадәр барып җитә.

Иң башта татарлар читкә йөреп һәм базарларда сату-алу белән шөгыльләнгәннәр һәм, озак та үтми, үзләренең сату урыннарын да булдырганнар. Сәүдәгәр татарлар шәһәр һәм район үзәкләрендә тукыма сату, тегү һәм күрек ясау үзәкләре ачканнар. Тотрыклы керем татар гаиләләренең яхшы яшәвен гарантияләгән. Сәүдәдә алар элеккеге чикләрен киңәйтә баралар, илләрара аралашуга һәм яңа мәдәни бәйләнешләргә омтылалар. Шулай итеп, гасырлар чигендә илдә индивидуаль һәм гаиләви рәвештә кечкенә, әмма бердәм мәдәни җәмгыять оеша башлый. Финляндиягә күчеп килгән татарларга тормышларын үз илләрендәгечә дәвам итү мөмкин булмый, алар моны яхшы аңлыйлар һәм фин җәмгыятенә бик тиз һәм органик рәвештә җайлашалар. Ана телләренең корылышы һәм тавыш системасы фин теленә охшаш булу сәбәпле татарлар яңа телне бик җиңел өйрәнәләр.

### Уртаклык

Татарлар, бәйсез Финляндия ватандашларына әверелеп, фин җәмгыяте үсешенә хезмәт итә башлыйлар һәм фин мәдәниятенә интеграцияләшәләр, ләкин шул ук вакытта хәтта бишенче буында да үз мәдәни үзенчәлекләрен саклап кала алдылар. Моңа ирешүнең сәбәбе нәрсәдә соң? Беренче һәм икенче буын вәкилләре хезмәт сөючәнлек, ихтыяр көче һәм үзара бердәмлек нәтиҗәсендә үз җәмәгать оешмаларын төзү өчен ныклы матди һәм рухи нигез булдырдылар. Бу җәмәгать оешмасы тарафыннан хупланган бурычларны тормышка ашыру, нигездә, гаиләгә йөкләнә. Гореф-гадәтләрне саклау яшьләргә үз тамырларын, кемлекләрен белеп үсәргә һәм үзүзләрен бәяли белергә ярдәм итә. Гаилә һәм туганнар белән булган тыгыз бәйләнеш бердәмлек һәм ышанычлылык тойгысын ныгыта. Шулай да татар мәдәни мирасын, милли йолаларны саклап калу, балаларны милли рухта тәрбияләү күп көч куюны таләп итә.

Соңгы йөз елда татарлар үз мәдәниятләре белән бергә финнәр казанышларын да үзләштерделер. Ахыргы чиктә алар Финляндияне үз ватаннары дип кабул иттеләр. Финляндиянең бәйсезлеге урнашкан көннән башлап, татар ислам җәмгыяте әгъзалары фин халкы белән бергә илнең күтәрелеш һәм авыр елларын уртак кичерде. 1939 һәм 1940 еллар кышында барган сугышларда татарлар җәмгыятеннән 156 ир-ат һәм 21 хатын-кыз Финляндия бәйсезлеген һәм мәнфәгатьләрен яклап катнашты, шуларның 10 сы һәлак булды.

Фин шәхесе балаларның урамдагы уеннарында һәм фин уен төркемнәрендә формалаша башлый. Гомуми белем бирү мәктәпләрендә һәм гимназияләрдә балалар уку, мәктәп дуслары һәм аларның гаиләләре белән аралашу аркылы фин мәдәнияте, җирле халыкның гореф-гадәте белән дә якыннан таныша. Эшчәнлек нигезләре университетларда, институтларда, һөнәри һәм техник училищеларда салынып, кешенең тормыш-яшәү шартларын

киңәйтәләр. Әлбәттә, илкүләм мәдәниятнең йогынтысы зуррак була, ә менә катнаш никахларда ике мәдәниятнең көн саен һәм күп мәртәбәләр очрашуы ике телле гаиләләрне барлыкка китерә. Ягъни татар ислам җәмгыяте әгъзалары үзләренең кем булуларын онытмыйлар – лингвистик һәм мәдәни мирасларына, диненә һәм дә төп халыкны тәшкил иткән финнәрнең шушы ук кыйммәтләренә нигезләп, балансны югалтмыйлар.

### Бай һәм тере тел

Фин татарларының ана теле татар теленең бер диалекты булып тора, дөресрәге ул аның көнбатыш, мишәр диалекты. Татар теле төрки телләрнең кыпчак тармагына карый, гаиләдә һәм җәмгыятьтә шушы тел куллanылу сәбәпле, балалар аны беренче тел буларак үзләштерәләр. Ата һәм ана гына түгел, әбибабайлар һәм туганнар җаваплылыгына нигезләнгән бала тәрбиясе һәр нәрсәнең башлангыч ноктасын тәшкил итә. Телгә өйрәтү татар ислам җәмгыяте тарафыннан оештырылган ял көннәре, балалар уен төркемнәре, шулай ук көз, яз һәм җәй айларында оештырылган ана теле курслары аша тормышка ашырыла. Яшьләр җәмгыять тарафыннан оештырылган мондый чараларда актив катнашалар. Мисал итеп мәдәни чаралардан хор һәм театр тамашаларында катнашуны китерергә була. Гомумән алганда мондый аралашулар, гаилә һәм туганнар арасындагы тыгыз бәйләнешләр ана телен куллануга иң яхшы пропаганда ысулы булып тора. Гадәттә ана теле укытучыларын татар ислам җәмгыяте үзеннән билгели, ә элегрәк, аларны өстәмә ресурс буларак, Төркиядән чакыралар иде. Җәмгыятьнең төрек һәм фин телләренең латин графикасы белән язылышына нигезләнгән үз язу ысулы бар. Ана телен өйрәнү, гомумән, милли үзенчәлекләрне саклап калуның нигезен тәшкил итә.

Фин теленең азчылык теленә ясаган зур йогынтысына карамастан, татар җәмгыяте ачык һәм хәяти әһәмиятле лингвистик үзәк бурычын лаеклы үти. Россия Федерациясе составындагы Татарстан Республикасы һәм аның башкаласы булган Казан шәһәренең мәдәни түгәрәкләре белән булган мәдәни элемтәләр дә телне саклауга зур ярдәм итә. Йөз ел дәвамында телебез бер үк вакытта төрек һәм заманча Казан татар теле белән баетылды. Халыкара бәйләнешләрне ныгыта барып, татар җәмгыяте дөньядагы бөтен татар җәмгыятьләре белән элемтәләр корды. Мисал өчен, Швеция, Эстония, Төркия, Австралия һәм Америка Кушма Штатларындагы татар җәмгыятьләре белән булган элемтәләр ана телен куллану мөмкинлекләрен тагын да киңәйтәләр.

Финляндия татар җәмгыяте бай һәм күп төрле мәдәни мираска ия. Халык җырлары һәм музыкасы татар ислам җәмгыяте әгъзаларын мәдәни һәм башка уртак чараларга берләштереп торалар. Шулай ук татар әдәбияты классикларының әсәрләренә нигезләнгән театраль тамашалар да бик популяр. Фин татарлары

үз әдәби әсәрләрен дә булдырдылар. Җырлар, шигырьләр, дини хезмәтләр һәрвакыт газетада һәм «Мәхәллә хәбәрләре» журналында бастырыла килә.

### Җәмгыятьнең бердәмлек рухы

Аз санлы җәмгыятьләр өчен дин иң мөһим мәсьәләләрдән санала. Ул – кешеләрне рухи инанулары буенча туплый торган ресурс та. Татарлар ислам динен X гасырда исламны кабул иткән һәм Идел буенда яшәгән борынгы болгар бабаларыннан мирас итеп алганнар. Фин мөселман җәмгыяте (1963 елдан Финляндия ислам җәмгыяте) 1923 елда гамәлгә кергән беренче Дини азатлык кануны нигезендә 1925 елда дини җәмгыятьләр реестрына кертелә. Европада Финляндия – Ислам җәмгыятен рәсми рәвештә таныган беренче ил булып тора. 1915 елда ук оешкан Хельсинки мөселман хәйрия җәмгыяте (Helsingin musulmaanien hyvantekevaisyysyhdistys) дә илдә татар халкын берләштерүгә һәм аның көндәлек мәсьәләләрен чишүгә ярдәм итә.

Ислам җәмгыяте ел дәвамында (аеруча язгы лагерьларда) мәктәп укучыларының дини тәрбия алуы турында кайгырта. Җәмгыять имамнары дини тәрбияне татар телендә бирәләр. 1960 елның урталарыннан бирле җәмгыять имамнарны Төркиядән чакыра иде. Советлар Берлеге таркалганнан соң намаз укыту, вәгазь сөйләү, никах һәм башка дини чаралар өчен имамнарны Россия Федерациясенең татар җәмгыятьләреннән чакыра башладылар. Имам сайлау таләпләре татар телен белүне, яңа шартларга һәм фин җәмгыятенә җайлаша алуны үз эченә ала. Җәмгыять әгъзалары ирекле рәвештә җәмгыятьнең төрле вазифаларын да үтиләр.

Ислам җәмгыяте дини оешма гына түгел, ул – үз карамагындагы мәдәни һәм спорт клубларына һәм дә мәдәни мираска матди һәм мәгънәви ярдәм итүче унитар, лингвистик һәм мәдәни җәмгыять тә. «Финляндия төркиләре берлеге – ФТБ» мәдәни җәмгыяте – 1935 елда, ә аның «Йолдыз» исемле спорт клубы 1945 елда корылган. 1948–1969 еллар арасында Хельсинкида татарларның төрки телдә башлангыч белем бирү мәктәбе эшләде. Анда, фин башлангыч мәктәбенең уку программасыннан тыш, татар теле, дин һәм төрки халыкларның тарихы дәресләре укытыла иде. Кыска бер дәвер эчендә анда төрек теле дә укытылды. Мәктәпкә Хельсинки шәһәре һәм татар җәмәгатьчелеге тарафыннан матди ярдәм күрсәтелде. Моннан тыш, Хельсинки, Тампере һәм Турку шәһәрләрендә җәмгыятьнең актив әгъзалары тарафыннан корылган башка мәдәни оешмалар да эшләп киләләр.

Җәмгыятьнең Хельсинки үзәгендә 1960 елда төзелеп беткән һәм җәмгыятьнең үз көчемсез милеге булган бинасында мәчет, җыелышлар залы, аш пешерү бүлмәсе, җәмәгать офисы, клуб, укытучылар бүлмәсе, кечкенә китапханә, ике укыту бүлмәсе һәм башка оешмаларның җыелыш бүлмәсе урнашкан. Җәмгыять милләттәшләребезнең

мәңгелек урыны – Хельсинки белән Турку шәһәрендәге зиратларны тәртиптә тотуга да зур игътибар бирә.

### Мәдәни үзенчәлекләр

Мөһим дини бәйрәмнәр һәм кичке чаралар ислам җәмгыяте әгъзаларын – аралашуга, уртак бәйрәмнәргә, күңел ачуга туплыйлар һәм, җәйге лагерь кысаларында оештырылган Сабантуй кебек, милли фестивальләргә җыялар.

Гадәти мәҗлесләр һәм милли ризыклар татар көнкүрешендә мөһим урын алып тора. Араларында камыр ризыкларыннан пәрәмәч һәм ашлардан шурпа да бар. Мәдәни җәмәгатьчелек милли ризыклар рецептларыннан фин һәм татар телендә аш-су китабы бастырып чыгарды.

Өлкәннәр турында кайгырту да татарларның социаль мәдәниятенең үзенчәлеге булып тора. Җәмгыять тарафыннан оештырылган атналык җыеннар – лаеклы ялда булучылар һәм картлар өчен бер-берсен күреп, аралашып ял итү чыганагы.

Икенче яктан, бергәләп хобби белән шөгыльләнер өчен тудырылган мөмкинлекләр, спорт чаралары яшьләрне тупларга ярдәм итә. Кышкы ял вакытында спорт клубы мәктәп балалары һәм аларның гаиләләре өчен кышкы лагерьлар оештыра. Кайбер милләттешләребез теннис һәм гольф белән шөгыльләнәләр. Спорт клубының «Йолдыз» футбол командасы, Хельсинки дивизионыннан тыш, Финляндиядәге яһүди (Маккаби) һәм гарәп (Сайкус) футболчылары белән дустанә матчларда катнаша. Эстония татар җәмәгыятенең футбол командасы Финляндияга килеп китте, ә «Йолдыз», дустанә ярышларда катнашу өчен, Алжир, Төркия һәм Татарстанда булып кайтты.

### Интеграция

Соңгы елларда яңа социаль күренешләр һәм интернациональләшү йогынтысы астында ислам җәмгыятьнең төзелеше шактый үзгәрешләр кичерде. Милләттәшләребезнең җирле халык белән тыгыз аралашуы ике телле һәм ике мәдәниятле гаиләләрнең барлыкка килүенә китерде. Мондый гаиләләрдә азчылыкның телен һәм мәдәниятен саклап калу өчен җәмгыять тарафыннан күп көч таләп ителә. Өлкән буын вәкилләре, еш кына, финнәр җәмгыятендә уңышлы булу өчен башкаларга караганда күбрәк һәм яхшырак эшләргә кирәклеген ассызыклыйлар. Алар, үз туган илләрендәге мәгариф системасын югары бәяләп, татар балаларына Финляндиядә дә яхшы белем бирү мөмкинлеге өчен бизнес өлкәсендәге эшмәкәрләрнең инвестиция ясавына ирештеләр. Җәмгыять әгъзалары Финляндиянең милли, мәдәни һәм икътисади үсешенә дә үз өлешләрен кертәләр.

Татар ислам җәмгыятенең яңа килүче иммигрантларга сүзе шушы: азчылыклар үз телләрен, диннәрен һәм мәдәни мирасын сакларга тырышырга тиешләр. Шул ук вакытта Финляндия җәмгыятенә җайлашу һәм аның кануннарына буйсыну да зарур. Фин телен өйрәнү – белем алу

һәм эшкә урнашуның мөһим аспекты булуы да табигый. Нәтиҗәле интеграция эзлекле һәм дәвамлы тырышлыкларны таләп итә. Үз милли рухи һәм матди мирасларына өстәмә буларак, кешеләр бай мәдәни мохиттән көч алырга тиешләр. Азчылыкларның җирле халык телен белүләре һәм киң кырлы, дөньяви белемнәре үзләре яшәгән илдә мәдәни һәм сәүдә мөнәсәбәтләрендә кулланыла торган ресурс булып санала.

### Хокукый мөмкинлекләр

Финляндия ислам җәмгыяте үз эшчәнлеген фин татарларының вәкилле органы буларак алып бара. Аның шурасы рәистән, биш әгъзадан, аларның өч урынбасарыннан һәм җәмгыять имамыннан корыла. Җәмгыять милли һәм халыкара дәрәҗәдә Бөтендөнья татар конгрессы кебек үк хокукларга ия. Җәмгыять шурасы вәкилләре Финляндия ил башлыклары катнашындагы дәүләткүләм рәсми визитларда һәм сәүдә миссияләрендә катнаша алалар.

Фин татарлары дини һәм мәдәниятара диалогларда актив катнаша, ислам җәмгыяте җитәкчелеге Финляндия хөкүмәте билгели торган Этник мөнәсәбәтләр консультатив советында (ETNO), Финляндиянең кулланышта булган кече телләр бюросында (FIBLUL), Финляндиянең диннәрара милли хезмәттәшлек форумында (CORE) һәм башка мөһим очрашуларда катнашу мөмкинлегенә ия.

**Әдәбият**

*Muazzez Baibulat:* Tampereen Islamilainen Seurakunta: juuret ja historia. Jyvaskyla, 2004.

*Kadriye Bedretdin* (ed.): Tugan tel. Kirjoituksia Suomen tataareista. Finnish Publications of the Finnish Oriental Society, No. 39. Jyvaskyla, 2011.

*Okan Daher:* Orthographical traditions among the Tatar minority in Finland. In Juha Janhunen & Volker Rybatzki (eds.): Writing in the Altaic World. Studia Orientalia 87, pp. 44–48. Helsinki, 1999.

*Harry Halen:* Suomen tataarit. In Markku Loytonen and Laura Kolbe (eds.): Suomi. Maa, kansa, kulttuurit. Finnish Literature Society Publication No. 753. Jyvaskyla, 1999.

*Tuomo Hirvonen* (ed.): Suomen Islam-seurakunnan veteraaniteos. Finnish Islamic Congregation. Jyvaskyla, 2006.

*Kari Karvonen* (ed.): Suomen Islam-seurakunta 1925–1975. Finnish Islamic Congregation. Helsinki, 1975.

*Antero Leitzinger:* Suomen tataarit; vuosina 1868–1944 muodostuneen muslimiyhteison menestystarina. Tampere, 2006.

Tatarica: studia in honorem Ymar Daher, anno MCMLXX sexagenario. Edendum curavit Abdulla Tukai Cultural Society, ed. Lauri Kotiniemi. Vammala, 1987.

***Окан Таһир Гомәр улы,***
*Хельсинки университетының татар теле*
*һәм мәдәнияте дәресләре лекторы,*
*Финляндия ислам татар җәмгыятенең*
*шәрәфле президенты*

УДК 574.4:349.6

*И.И. Рәхимов,*
*К.К. Ибраһимова*

# ИНТЕНСИВ ХУҖАЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕ ШАРТЛАРЫНДА ТАТАРСТАН ЭКОСИСТЕМАСЫНЫҢ ТАБИГЫЙ БИОТӨРЛЕЛЕГЕН САКЛАУ

Татарстан расположен на границе двух больших природно-географических зон, и фауна характеризуется разнообразием ландшафтов и населяющих их видов животных и растений. Под влиянием разносторонней деятельности человека происходят возрастание численности одних видов, снижение – других, меняется характер размещение видов в пределах территории Татарстана. Для Татарстана важно определить приоритеты в планировании мероприятий по обеспечению практики сохранения биологического разнообразия и устойчивого использования его компонентов. Региональная программа по сохранению биоразнообразия природных экосистем Татарстана в условиях интенсивного хозяйствования должен включать ряд направлений: от создания Особо охраняемых природных территорий и Красной книги до активной природоохранной пропаганды.

**Ключевые слова:** сохранение биоразнообразия, антропогенные факторы, охрана природы Татарстана, Национальная Стратегия сохранения биоразнообразия России.

Кеше эшчәнлегенең киңәя баруы хәзерге вакытта күп яктан биосфераның яшәешен һәм үсеш перспективаларын билгели. Мондый шартларда җирдәге табигый экосистеманы, шулай ук үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының аерым өлкәләрен саклау мәсьәләләрен хәл итү катлаулана бара. Табигый ландшафтны антропоген трансформацияләүнең интенсивлашуы, демографик шартлау, әйләнә-тирә мохитне тоташ пычрату тере организмнар яшәеше өчен табигый территорияләрне торган саен киметә бара, бу – кеше белән табигать арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең кискенләшә баруына китерә. Биотөрлелекне саклау мәсьәләләренең мөһимлеген һәм кичектергесезлеген 1992 елда БМО тарафыннан әйләнә-тирә мохит һәм аның үсеше буенча Рио-де-Жанейрода конференция уздырылуы факты ассызыклый, анда әлеге проблемаларны хәл итү буенча беренче адымнар ясала. Кабул ителгән «Конвенция о биологическом разнообразии» дигән документ дөньякүләм яклау таба. 1995 елда Россия Федерациясе үз өстенә зур бурычлар йөкләгән конвенцияне раслый, шул исәптән биотөрлелекне саклауның милли стратегиясен эшләүне максат итеп куя. Россиядә биотөрлелекне саклауның милли стратегиясе тере табигатьне саклау буенча уздырылган Милли форумда кабул ителә (Мәскәү, 2001) һәм Россия Федерациясенең Россия хөкүмәте тарафыннан расланган Экологик доктринасына кертелә [Реймерс, 1990].

Стратегиянең нигезе табигый биотөрлелекне тәшкил итүче төрләр, биоценозлар һәм экосистемалардан, шулай ук хайваннарның йортка ияләштерелгән һәм үсемлекләрнең культуралаштырылган төрләреннән, тере организмнарның генно-инженерик яктан модификацияләнеп үзгәртелгән төрләреннән, кеше тарафыннан барлыкка китерелгән экосистемалардан (агросистема, шәһәрләр, сусаклагычлар, урман полосалары, парклар, бакчалар һ.б. урнашкан территорияләрдән) гыйбарәт [Итоговый документ Саммита...]. Россия биотөрлелеген саклау стратегиясе буенча кабул ителгән документлар нигезендә биотөрлелекне саклауның конкрет территорияләрдәге табигый-географик, икътисади, тарихи, милли үзенчәлекләре исәпкә алынган региональ программа эшләнергә тиеш.

Җир хартиясен тормышка ашыруны дәвам итүче Татарстан Республикасы өчен бу аеруча актуаль. 2001 елда Татарстан дөньяның күп илләре белгечләре тарафыннан эшләнгән һәм БМО яклавына нигезләнгән әлеге документны гамәлгә ашыру буенча эш башлап җибәрде. Бу башлангычның максаты – гомумкешелек кыйммәтләренә карата әйләнәтирә мохитне саклау таләпләре истә тотылган яңа караш формалаштыруга юнәлдергән. 2001 елның 27 апрелендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы әлеге халыкара документны республика җирлегендә беренче булып тормышка ашыруны башлап җибәрү турында махсус карар чыгарды. Җир хартиясе, икенче төрле әйткәндә Җиргә хокуклар декларациясе, – планетабызны коткарып калу, биосфераны саклау, биологик төрләрнең берсе булган кешеләрнең яшәешен дәвам итү шартларына зыян салмау нияте белән эшләнгән документ, һәм ул Җирдәге барлык халыкны шушы максатка туплаучы ролен үтәргә тиеш [Горшков, 2008].

Татарстанда хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектларын саклауның норматив-хокукый базасын күп кенә мөһим документлар тәшкил итә, аларда төп урынны Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне (шул исәптән биотөрлекне дә) саклау өлкәсендә регион сәясәтен күздә тоткан Экология кодексы (№ 5-ТРЗ, 15 гыйнвар 2009 ел) били [Закон Республики Татарстан от 2 июля 1997 г.; Закон Республики Татарстан от 18 сентября 1997 г.; Закон Республики Татарстан от 16 октября 1997 г.].

Биотөрлелекне саклау проблемаларын практик хәл итү, билгеләнгән Стратегиядән чыгып, ике концептуаль карашка нигезләнергә тиеш:

– популяция-төрлелек. Чөнки табигатьтә һәр төр кабатланмас генофондка ия, генетик яктан ябык система булып карала; бу караш үсемләр һәм хайваннар төрләренең үзләренә генә хас аерым популяциясен саклауга юнәлдереләә;

– экосистемалык. Чөнки барлык биологик системалар яшәү тирәлеге һәм бер-берсе белән аерылгысыз бәйләнгән, тере организмнар экологик бергәлек һәм экосистема составында гына табигый яктан ирекле халәттә яши алалар; бу караш төрле

дәрәҗәдәге экосистемаларны саклауга юнәлдерелә.

Әлеге карашлар нигезендә төрлелеге сакланырга тиеш булган Стратегия түбәндәге объектларга аерыла: организм, популяция, төр, организмнар бергәлеге, экосистема, экосистемаларның территориаль-бәйлелек комплексы, биосфера [Сохранение биологического...]. Регион, аерым алганда Татарстан өчен биологик төрлелекнең сакланышына һәм аның компонентларының тотрыклы файдаланылуына кагылышлы яңа белемнәр һәм традицион практика белән тәэмин ителерлек чаралар планлаштыруның өстенлеген билгеләү мөһим. Хуҗалык итү белән интенсив шөгыльләнүче Татарстанда табигый экосистемаларның биотөрлелеген саклау буенча төзелгән Региональ программада түбәндә күрсәтелгән юнәлешләр урын алырга тиеш.

1. Региональ фауна һәм флораны, аерым төрләрнең популяциясен яктыртып баручы даими мониторинг булдырырга. Урта Иделдәге фәнни потенциал, шулай ук табигый мохит торышын контрольдә тотучы дәүләт учреждениеләре һәм идарәләре системасы мониторинг белән биоиндекацион бурычларны үтәүдә мөһим фактор булып саналалар. Әйтеп үтелгән проблемаларны гамәлгә ашыру – табигатьтән рациональ файдалануга, табигый тереклекнең саны-исәбе белән фәнни идарә итүгә юл ача.

Беренче чиратта, бу – хуҗалыкчыл (бигрәк тә авыл һәм аучылык хуҗалыкларында) әһәмияткә ия, күпләп асрала торган төрләргә карый. Биомониторингның бурычы үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларында кеше эшчәнлеге йогынтысы астында барган үзгәрешләр хакында алдан хәбәр итүдән, аңа бәя бирүдән һәм контрольдә тотудан гыйбарәт. Татарстанда уздырылган тикшеренүләр биотөрлелекнең хәзерге торышы буенча шактый тулы мәгълүматлар алырга, фауна һәм флораның потенциал байлыкларын билгеләргә ярдәм итте [Бакин и др.; Гаранин и др., 2000; Гордиенко; Горшков; Кузнецов; Попов, Лукин] (1 нче табл.).

*1 нче таблица*

Татарстан Республикасындагы үсемлекләр һәм хайваннарның системалы төп төркемнәре биотөрлелеге

| Системалы төркемнәр | Төрләр саны | Мәгълүмат чыганагы |
|---|---|---|
| Югары төзелешле күп тамырлы үсемлекләр | 1610 | Бакин О.В., Рогова Т.В., Ситников А.П., 2000 |
| Кылчыклы балыклар классы | 55 | Кузнецов В.А., 2005 |
| Җир-су хайваннары классы | 11 | Гаранин В.И. и др., 2000 |
| Сөйрәлүчеләр классы | 8 | Гаранин В.И., и др. 2000 |
| Кошлар классы | 289 | Рахимов И.И., 2008 |
| Имезүчеләр классы | 73 | Попов, Лукин, 1988 |

2. Кызыл китап алып бару регионадагы биотөрлелекнең саклanышын күз алдына китерү өчен нигез булып тора [Красная книга.., 2002]. Татарстан Республикасы Кызыл китабы Татарстан Республикасы законнарына туры китереп эшләнгән рәсми документ, ул әледән-әле басылып тора. Татарстан Кызыл китабының беренчесе 1995 елда, икенчесе 10 елдан соң дөнья күрә [Красная книга..., 2006]. ТР Кызыл китабына 122 төрдәге умырткасыз хайваннар, 40 төрле гөмбә, 376 төрдәге (республикадагы барлык төрләрнең 23,35% ы) үсемлекләр, 136 төрдәге (республикадагы барлык төрләрнең 31,7% ы) умырткалылар: 10 төрдәге (ягъни барлык төрләрнең 20,4% ы) балыклар; 3 төрле (барлык төрнең 27,27% ы) амфибия; 5 төрдәге (62,5%) сөйрәлүчеләр; 84 төрдәге (29,7%) кошлар; 34 төрле (47,22%) имезүчеләр теркәлгән. Кызыл китап алып барыла торган берничә генә регион арасында Татарстан – хайваннар һәм үсемлекләрнең сирәк очрый торган яки юкка чыгып баручы төрләре торышын мониторинг буенча даими яктыртып баручы бердәнбер регион. Кызыл китапның беренче басмасына кертелгән мәгълүматлар, төрләрнең саны һәм сирәклек статусы үзгәрү белән бәйле рәвештә, алдагы басмаларда яңартыла баралар. Мәсәлән, икенче басмага кыр тавыгы (*Perdix perdix*), байбак (*Marmota bobak*), язгы утчәчәк (*Adonis vernalis*) һ.б. өстәлгән. Кызыл китапның инде өченчесе нәшер итүгә әзерләнгән.

3. Махсус сакланылучы табигать территорияләре (МСТТ) булдыру һәм, хуҗалык алып бару, табигатьне саклау һәм рекрацион (кешеләргә ял итү өчен көйләнгән) максатларны күздә тотып, аларның челтәрен киңәйтү. МСТТ экологик системаны тоташ (гомумән) саклый һәм территориянең экологик яктан куркынычсызлык дәрәҗәсен күтәрә [Дёжкин и др.; Закон Республики Татарстан от 16 октября 1997 г...]. Татарстан Республикасы территориясенең 2,09% ын тәшкил иткән мәйданы табигый комплексларны, ландшафтны һәм биологик төрлелекне саклау һәм торгызу өчен оптималь шартлар белән тәэмин ителгән. Татарстанда МСТТ системасы югары үсеш алуга карамастан, әйтеп үтелгән мәйданнардагы экосистема һәм табигый төрләр республикадагы флора һәм фаунаның күптөрлелеген тулысынча яктыртып бетерә алмый әле. МСТТ системасындагы биотөрлелекне инвентаризацияләү, табигый экосистеманың торышын, биоресурсларның кыйммәтен бәяләү, шулай ук биомониторингның башка мөһим бурычларын гамәлгә кертү буенча өстәмә тикшеренүләр таләп ителә.

Табигый комплексларга көчле антропоген йогынты шартларында, актив файдаланыла торган территорияләр киңлегендә МСТТ үз функцияләрен тормышка ашыра һәм көчле антропоген басым астындагы әлеге участокта хайваннарның һәм үсемлекләрнең сакланышын тәэмин итә.

Территориаль экологик тигезлекнең тотрыклылыгы өчен, экстенсив файдаланыла һәм саклана торган территорияләрнең мәйданы интенсив эксплуатацияләнә торганнарына карата урман зонасында – 30–35%, урман-дала зонасында – 20–30% чагыштырмасында булырга тиеш [Реймерс]. Мондый шартларда биотопның чагыштырма бөтенлеге саклана, ә табигый кишәрлекләрнең мозаик бүленеше актив яшәү рәвеше алып баручы хайваннар өчен уңайлы шартлар тудыра. Әйтеп үтелгәнчә, әлегә Татарстан территориясенең 2% ы гына махсус саклау системасына карый. Республика транспорт челтәре көчле үсеш алган, халык тыгыз утырган һәм торак пунктлар еш урнашкан сәнәгый регион санала. Территориянең зур өлеше (барлык мәйданның 69,2% ы) – авыл хуҗалыгы файдалануындагы җирләр. Урман фонды – территориянең 16,9% ын тәшкил итә. Мондый шартларда Татарстан Республикасы өчен МСТТ роле аеруча зур әһәмияткә ия. «ТРдагы махсус сакланылучы табигать территорияләренең дәүләт реестры» (2007) нигезендә Татарстанда 154 МСТТ объекты (шул исәптән, 1 тыюлык, 1 милли парк), 24 дәүләт табигый заказнигы, 127 табигать һәйкәле исәпләнә [Татарстан Республикасында махсус саклаулы...; Государственные доклады...]. Аларның һәркайсында республика фаунасының күптөрлелеген саклау тәэмин ителгән һәм җирдә яшәүче умырткалы хайваннарның, төрле үсемлекләр төркемнәренең сирәк очрый торган төрләрен саклау өчен яхшы шартлар тудырылган.

Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгы (ИКДТБТ) ТР Кызыл китабына кертелгән кошларның (аларның 65% ы тыюлык территориясендә яши) күбесенә сакланып калу өчен шартлар бар. Әйтик, ак койрыкбөркет (*Haliaeetus albicilla*), озын койрыклы соры ябалак (*Strix nebulosa*), чал күке (*Picus canus*), кычыткан чыпчыгы (*Troglodytes troglodytes*) һ.б. Идел-Кама биосфера тыюлыгы ике кишәрлектән (участоктан) гыйбарәт, алар бер-берсеннән аерылып торалар һәм саклана торган территориянең мөстәкыйль берәмлеген тәшкил итәләр. Раифада – урман, Саралан кишәрлеге су буена урнашкан. Мондый урыннар тыюлыкның яшәү тирәлеген төрлеләндерәләр һәм фауна белән флораның төрлелегенә йогынты ясыйлар. Тыюлык территориясендә 600 дән артык төрдәге суүсемнәр, 44 төрле бавырсыман мүк, 162 төрле яфрак-сабаклы мүк, 4 төрдәге плаун, 6 төрле наратбаш, 16 төрле абага, 5 төрдә ачыкорлыклылар һәм 800 дән артык төрдә чәчәкле үсемлекләр булуы мәгълүм. Территориядә сирәк очрый һәм юкка чыгып бара торган төрләр дә шактый. Мәсәлән, мүксыманнарның – 19, тамырчалы үсемлекләрнең 93 төре Татарстанның Кызыл китабына кертелгән. Кызыл серкәбаш (*Cephalanthera rubra*), бармаксыман тамырчалы траунштейнер (*Dactylorhiza traunsteineri* ), калпаксыман неоттианта (*Neottianthe cucullata*), каурый кылган (*Stipa pennata*) Россия Федерациясе

Кызыл китабына теркәлгән. Тыюлык мәйданнарында барысы 700 ләп төрдәге гөмбәләр үсә.

1991 елда, Кама буендагы уникаль наратлыкларны һәм тугай-болыннарны саклап калу максаты белән «Түбән Кама» милли паркы булдырылды. Паркның мәйданы Идел-Кама табигый биосфера тыюлыгы территориясеннән өч тапкырга зуррак һәм анда тайганың көньягы белән урман-дала чигендә таралган тереклек ияләре һәм үсемлекләрнең күп сандагы сирәк төрләре саклана. Әйтик, борындык (*Tamias sibiricus*), дала төлкесе (*Lagurus lagurus*), һөдһөд (*Upupa epops*), колаклы ябалак (*Asio otus*) һ.б. Үсемлекләр дөньясын 600 ләп төрдәге тамырчалы үсемлекләр тәшкил итә, аларның 89 ы сирәк очрый һәм юкка чыгып бара торган төрләр (мәсәлән, шлемлы төертамыр (*Orchis militaris*), эре чәчәкле кәккүк читеге (марҗа башмагы дип тә әйтәләр) (*Cypripedium macranthon*).

Татарстандагы күпсанлы табигать һәйкәлләре һәм заказникларның кайбер кишәрлекләре сирәк очраучы хайваннар һәм үсемлекләрнең яки фауна комплексларының аерым төрләрен саклау максаты белән бүлеп алынган. Алар – табигатьнең «зоологик» һәйкәлләре. Аларда байбакларның 4, соры челәннәрнең 2 колониясе, Россиянең Европа өлешендә иң зур саналган күл акчарлаклары колониясе яши.

Табигый заказниклар да махсус сакланулы табигать территорияләре (МСТТ) системасына карый. Аулау рөхсәт ителгән җәнлекләрнең кайбер төрләрен саклау максаты белән оештырылган булсалар да, заказниклар террториялэрендә сирәк очрый торган үсемлекләр саклана. Кызганычка каршы, аучылык заказниклары фаунасы белән флорасы әлегә бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән.

4. Россиядә сунарчылык һәм аучылык хуҗалыгы – кыргый тереклек дөньясыннан һәм сунарчылык биләмәләреннән файдалануның традицион һәм шактый киң таралган ысулы. Табигатьтән файдалануның бу төре безнең илдә яшәүче күпчелек халык көнкүрешенең аерылгысыз өлешен тәкшил итә. Безнең илдә кыргый җәнлекләрнең һәм кошларның 226 төре сунарчылык ресурсы булып санала. Аларның кайберләренең запасы буенча Россия Федерациясе дөньяда беренче урынны били [www.sevin.ru/bioresrus/classification]. Мәгълүм булганча, регламентлаштырылган һәм контрольдә тотылган сунарчылык (аучылык) – ул үзе табигатьне саклауның бер формасы. Табигый комплексны тоташ саклауда, аулана торган кошлар һәм җәнлекләрнең үрчемен тәэмин итүдә һәм аучылык кәсебенең дәвамлы яшәвендә сунарчылык биләмәләре мөһим роль уйный.

Татарстан Республикасында аулана торган хайваннар ресурсы шактый бай. Төп сунарчылык объектлары хәзер 77 төрне тәшкил итә. Татарстанда 2013 елның 1 гыйнварына аучылык белән шөгыльләнүче (охотопользователи) 55 объект теркәлгән,

алар 88 урындагы аучылык хуҗалыгыннан файдалана алалар. Татарстанда аучылык биләмәләре 2013 елның 1 гыйнварына 6065,6 мең гектарны тәшкил итә [http://ojm.tatarstan.ru].

5. Антропоген ландшафтлар (аеруча урбанизацияләнгән) территорияләрен экологик контрольдә тоту һәм аларда тикшеренүләрне киңәйтү. Шәһәр территорияләренең, төрләргә бай табигый ландшафтлар мохитен йота барып, кызу темплар белән киңәюе һәм бөтен регион табигатенә көчле йогынты ясавы шартларында биотөрлелекне саклап калу проблемасы тагын да актуальләшә. Хәзер шәһәр мохите, кешенең генә түгел, антропоген фактор йогынтысы астында анда килеп эләккән күп төрле кошларның һәм җәнлекләрнең дә яшәү тирәлеге булып хезмәт итә. Әйтик, кошлар классы вәкилләре генә дә миллионлы шәһәр Казанда 186 төрне тәшкил итә. Шәһәр шартларында табигый мохиттә тиңдәше булмаган, үзенчәлекле орнитоценнар формалаша. Яшәү тирәлегенең төрлелеге бергәлекләр эчендә дә аерымланулар китереп чыгара. Яшәү җирлегенең төрле биотоплардан торган мозаик характерда булуы нәтиҗәсендә шәһәрдәге кошларның аеруча күптөрлелеге күзәтелә. Бер-берсенә күрше булган биотоплар чиктәш зоналар барлыкка китерәләр һәм аларның ике ягында да яшәү урынының үзара уртак элементлары саклана. Андагы кошларның төрлелек составы да, урнашу тыгызлыгы да табигый экосистемадагылардан күпкә югары була. Фәкать шәһәрләр экосистемасында гына 200 ләп төрдәге кошларны күзәтергә мөмкин, аларның урнашу тыгызлыгы да 1500–2000 ос/км$^2$ тәшкил итә, ә табигый экосистемаларның берсендә дә мондый күренешләрне очрата алмыйсың.

Шәһәрдә сакланып калган үсемлекләр һәм хайваннар андагы шартларга җайлашалар. Тикшеренүләр кошларда һәм җәнлекләрдә экологик яраклашучанлыкның югары һәм потенциаль мөмкинлекләрнең зур булуын раслады. Мәсәлән, эре ерткыч кошлар үзләренең ояларын электр линиясе мачталарына коралар, акчарлаклар антропоген азыклар белән туклануга күчәләр. Әмма тынычсызлык факторы, аларның кайбер төрләрен турыдан-туры эзәрлекләү һәм үтерү шәһәрдәге хайваннарның юкка чыгуына сәбәп була.

Антропоген йогынты уртача саналган зоналарда шәһәр территорияләре системасы булдыру, табигый биотопларны саклау кайбер төрләрнең яшәеше өчен мөмкинлекләрне арттыра. Әмма ул кайбер төрләрнең артык күп үрчүенә китерә, мәсәлән, күк күгәрченнәр һәм каргасыман кошларның саны бүген регулирлауны таләп итә. Урбанизация шартларында табигатьтән дөрес файдалану һәм аны саклау өчен махсус чаралар куллану шәһәрне үзенә бер экосистема буларак үстерергә һәм шәһәр мохитендә экологик тигезләнешне тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Уздырылган тикшеренүләрдән ачыкланганча, хайваннар һәм үсемлекләрнең сан ягыннан үрчүенә һәм таралуына йогынты

ясаучы факторларны чикләү кешенең комплекслы эшчәнлеге (турыдан-туры эзәрлекләү яки яшәү тирәлеген пычрату нәтиҗәсендәге сәбәпләр) белән бәйле. Антропоген факторларның күп нәрсәне эченә алучан характерын истә тотып, трансформацияләнгән территорияләрдәге хайваннарны һәм үсемлекләрне саклап калу өчен шартлар тудыру мөһим. 1980 еллар ахырында Яр Чаллы шәһәрен киңәйтүнең перспектив планын эшләгәндә Шәһәр төзелеше институты (Мәскәү) Татарстан экологларының шәһәр тирәсендә урман массивларын саклап калуны, яңа парклар булдыруны, гомумән шәһәр фаунасын һәм флорасын баетуны күздә тоткан тәкъдимнәрен истә тотып эш итте. Алар түбәндәгеләргә юнәлдерелгән иде:

– шәһәр эчендәге биологик төрләрнең яшәү мохите белән бәйле табигый объектларны саклау, шулай ук ерынты-чокыр һәм тау тирәләрендәге урманлы сөзәклекләргә, юл буйларындагы агач утыртылган полосаларга, сәнәгать предприятиеләренең буфер зоналарындагы агачларга зарар китермәү;

– шәһәрдә яңа микрорайоннар проектлаштырганда җирле табигый биотопларга нигезләп зур-зур парклар булдыру;

– шәһәр эчендәге табигый сулыкларны, елгаларның акваториясен башлангыч хәлендә саклап калу яки шәһәр сулыкларын культуралаштырганда аның ярындагы табигый үсемлекләргә зарар китермәү;

– шәһәрне яшелләндерү системасына мөнәсәбәтне үзгәртү. Чөнки аерым бер территориянең табигый тереклек үзенчәлекләрен исәпкә алмыйча, анда токымсыз үсемлекләр утырту нәтиҗәсендә шәһәр территориясен Америка өрәңгесе (*Acer negundo*) һәм тупыл-тирәк басып китте.

Шәһәрне яшелләндерү практикасында, бу территориягә кошларны ияләштерү максаты белән, биек булып үсә торган агачлар янында, яруслап, куаклыклар үстерү дә киң кулланыла. Паркларны реконструкцияләгәндә картайган агачларны да калдыру, ә яңа үсентеләрне тәртипсез рәвештә утырту мөһим. Мондый алымнарны шәһәрләрне һәм бистәләрне яшелләндергәндә кулланырга була.

6. Биотөрлелекне саклау – хайваннарның сирәк очрый торган төрләрен ясалма үрчетергә һәм шул үрчемне табигый яшәү тирәлегенә күчерергә, кыргый җәнлекләр үрчетергә, хайваннар яки үсемлекләр интродукциясенә мөмкинлек тудыра.

1949 елда Татарстанда Кама елгасының түбәнге агымына Воронеж тыюлыгыннан китерелгән кондызларны җибәрәләр. Шул вакыттан башлап, Татарстанда XIX гасыр башында кырып бетерлегән бу җәнлекләр үрчеме торгызыла. Табигый дошманнары булмау һәм аулауны тыю аларга элекке яшәү тирәлегенә охшамаган мохитне үзләштерергә ярдәм итә. Кондызларны төрле экосистемаларга ияләштереп үрчетү аларның әйләнә-тирәгә йогынтысын махсус тикшереп өйрәнүне таләп итте (Горшков, 2004). Татарстанда янутсыман эт (*Nyctereutes*

*procyonoides*), Америка чәшкесе (*Neovison vison*), ондатра (*Ondatra zibethicus*), тиентелеутка (*Sciurus vulgaris exalbidus*) интродукцияләнде (үз табигый урыннарыннан күчереп урнаштырылды), аларның Татарстан экосистемасындагы әһәмияте һәм роле әле тулысынча өйрәнелмәгән. 2013 елда Татарстанга мараллар китерелде.

Зоологик бакчаларда да шушы юнәлештә эш алып барыла. Зур экологик белем һәм киңәйтелгән аңлату эшләре белән беррәттән, аларда фаунаның сирәк очрый торган вәкилләрен – җәнлекләр һәм кошларны саклап калу буенча да нәтиҗәле чаралар күрелә. Зоологик коллекцияләр җыентыгындагы мәгълүматлардан билгеле булганча, Урта Идел буенда дүрт стационар зоопарк эшли (шуларның икесе – Пенза һәм Казан зоопарклары – Россиянең Европа өлешендәге бик күптәнгеләр).

Казан зооботаника бакчасында күп еллардан бирле ерткыч кошларны читлек шартларында үрчетү эшләре, ак аю (*Ursus maritimus*) һәм барсның үрчүе буенча тикшеренүләр алып барыла.

7. Массакүләм пропаганда эшчәнлеге кеше һәм табигатьнең үзара мөнәсәбәтләрен оптимальләштерүгә юнәлдерелә. Әлеге эшчәнлекнең колачы бик киң, ул тикшеренү-өйрәнүләр нәтиҗәсендә тупланган мәгълүматларны халыкның барлык катлауларына да җиткерү мөмкинлеге бирә, кешеләрдә фауна белән флорага карата уңай мөнәсәбәт формалаштыра, шуңа күрә балалар һәм укучы яшьләр белән эшләү аеруча мөһим.

Популяр басмалар, балалар өчен туган як фаунасы һәм флорасы турындагы китаплар табигатьне яратырга, аңа карата сак караш тәрбияләргә ярдәм итә. Әйтик, Татарстан Республикасындагы үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына багышланган 50 ләп китап дөнья күрде. Алар арасында җитди фәнни хезмәтләр дә бар. Мәсәлән: «Сосудистые растения Татарстана» (Бакин О.В., Рогова Т.В., Ситников А.П., 2000) «Животный мир Татарии» (Попов В.А., Лукин А.В., 1978), «Рыбы Волжско-Камского края» (Кузнецов В.А., 2005), «Совы фауны Республики Татарстан» (Горшков П.К., 2008), «Животный мир Восточного Закамья» (Гаранин В.И. и др., 2000), шулай ук мәктәп укучылары өчен «Растительный и животный мир Татарстана» (Рахимов И.И., Ибрагимова К.К., 2006) һ.б. [Аськеев и др.; Гаранин, 1983; Гордиенко; Шулаев и др.].

Биотөрлелекне саклау өлкәсендә иҗтимагый оешмаларның да роле зур әһәмияткә ия. Татарстанда, мәсәлән, Россия кошларны саклау берлегенең Казан бүлеге, Ботаниклар җәмгыяте, Герпетологлар җәмгыяте, Гидробиологлар җәмгыяте актив эшли.

1997 елда Татарстан Республикасы «Хайваннар дөньясын саклау һәм рациональ файдалану турында», «Үсемлекләр дөньясы турында» законнар кабул итте. Бу документлар хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын саклауга юнәлдерелгән. Аларны әзерләүдә

һәм алар хакында фикер алышуларда галимнәр, Татарстандагы шушы өлкә белән кызыксынучы төрле оешмаларның фәнни хезмәткәрләре катнашты. Әлеге законнар хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын саклау, алардан фәнни нигезләнгән һәм рациональ файдалану өлкәсендә Республиканың дәүләт сәясәте принципларын ныгыта; хокукый, икътисади һәм социаль юнәлешләрне билгели, һәм болар барысы да хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын, аларның яшәү тирәлеген саклауга юнәлдерелә.

Димәк, биотөрлелекне саклауның региональ стратегиясе үз эченә күптөрле алымнарны һәм табигатьне саклау эшчәнлеген оештыру ысулларын туплый. Югарыда әйтелгән юнәлешләр Татарстан Республикасында биологик төрлелекне саклау стратегиясенең нигезен тәшкил итә алалар, бүген ул зарури таләп.

### Әдәбият


*Аськеев И.В., Аськеев О.В., Беляев А.Н.* Млекопитающие Республики Татарстан (конспект современного состояния). Казань, 2002. 35 с.

*Бакин О.В., Рогова Т.В., Ситников А.П.* Сосудистые растения Татарстана. Казань: Издательство КГУ, 2000, 496 с.

*Гаранин В.И.* Земноводные и пресмыкающиеся Волжско-Камского края. М.: Наука, 1983. 210 с.

*Гаранин В.И., Егоров И.Я., Рябова Г.А.* Животный мир Восточного Закамья (позвоночные). Альметьевск, 2000. 237 с.

*Гордиенко С.Г.* Бабочки Татарии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. 144 с.

Татарстан Республикасында махсус саклаулы табигать территорияләренең Дәүләт реестры. Идел-пресс нәшр., 2007. 408 б.

Государственные доклады о состоянии окружающей среды в Республике Татарстан 1999–2011 гг.

*Горшков П.К.* Совы фауны Республики Татарстан. Казань: Изд-во ТГПУ, 2008. 108 с.

*Дёжкин В.В., Лихацкий Ю.П., Снакин В.В. и др.* Заповедное дело: теория и практика. М.: Фонд «Инфосфера» – НИА-Природа, 2006. 419 с.

Об охране и рациональном использовании животного мира: Закон Республики Татарстан от 2 июля 1997 года № 1241 // Ведомости Государственного Совета Татарстана. 1997. № 7.

О растительном мире: Закон Республики Татарстан от 18 сентября 1997 года № 1303 // Ведомости Государственного Совета Татарстана. 1997. № 10.

Об особо охраняемых природных территориях: Закон Республики Татарстан от 16 октября 1997 года № 1360 // Ведомости Государственного Совета Татарстана. 1997. № 11.

Будущее, которое мы хотим: Итоговый документ Саммита «Рио + 20» 2012.

Красная книга Республики Татарстан (животные, растения, грибы). Издание второе / глав.ред. А.И. Щеповских. Казань: Идель-Пресс, 2006. 832 с.

Красная книга Российской Федерации. М.: Министерство природных ресурсов РФ, 2001. 860 с.

*Кузнецов В.А.* Рыбы Волжско-Камского края. Казань: Kazan, 2005. 208 с.

Национальная стратегия сохранения биоразнообразия России. М., 2002. 129 с.

*Попов В.А., Лукин А.В.* Животный мир Татарии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1988. 248 с.

*Реймерс Н.Ф.* Природопользование. М.: Мысль, 1990. 637 с.

Сохранение биологического разнообразия России. Правовая и нормативно-методическая документация. Госкомитет РФ по охране окружающей среды. Проект ГЭФ «Сохранения биологического разнообразия» / сост. В.И. Перерва, Г.К. Ковалев, В.А. Орлов. М.: Окаэкос, 1999. 470 с.

*Шулаев Н.В., Петров Н.Г., Шулаев М.В.* Булавовидные чешуекрылые Татарстана (аннотированный список видов). Казань: Новое знание, 2005. 40 с.

www.sevin.ru/bioresrus/classification

http://ojm.tatarstan.ru

***Рәхимов Илгизәр Ильяс улы,***
*биология фәннәре докторы, профессор,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының биоэкология,*
*гигиена һәм иҗтимагый сәламәтлек кафедрасы мөдире*

***Ибраһимова Кадрия Камил кызы,***
*биология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының биоэкология,*
*гигиена һәм иҗтимагый сәламәтлек кафедрасы доценты*

УДК 615.015.8

***Л.Ф. Миңнуллина,***
***Э.Р. Шәйдуллина***

# УРОПАТОГЕННАРНЫҢ АНТИБАКТЕРИАЛЬ МАТДӘЛӘРГӘ КАРШЫ ТОРУЧАНЛЫГЫ

Данная работа посвящена изучению структуры и чувствительности к антибиотикам основных возбудителей внебольничных инфекций мочевыводящих путей (ИМП) по г. Казани. По результатам работы определены наиболее частые возбудители внебольничных ИМП: *E. coli* (1176/47,2%), *E. faecalis* (575/23,1%) и *K. pneumoniae* (336/13,5%). Выявлен высокий уровень резистентности *E. coli* и *E. faecalis* к ципрофлоксацину – 21,7% и 24,5% соответственно, *K. pneumoniae* к цефалоспоринам III поколения: доля резистентных штаммов к цефтазидиму и цефатаксиму составила 22% и 22,9% соответственно. Наибольшей активностью в отношении *E. coli* и *K. pneumoniae* обладал амикацин и нитроксолин, а в отношении *E. faecalis* – амоксициллин и ампициллин. Таким образом, показано, что основной возбудитель внебольничных ИМП *E. coli* обладает высоким уровнем резистентности к ципрофлоксацину – препарату основной группы антибиотиков, применяемых при лечении ИМП.

**Ключевые слова:** антибиотикорезистентность, внебольничные инфекции, инфекции мочевых путей.

Бүлеп чыгару системасы инфекцияләренә (БЧСИ) бүлеп чыгару системасының төрле өлкәләрендә шартлы патоген бактерияләр тәэсирендә барлыкка килгән ялкынсынулы авыруларны кертәләр. БЧСИ амбулатор[1] һәм госпиталь инфекцияләре арасында иң киң таралганнардан санала һәм бүгенге көн медицинасы өчен актуаль проблема булып тора. Мисал өчен, АКШта 1997–2007 елларда сәламәтлек саклау оешмаларына БЧСИ белән мөрәҗәгать итүчеләр саны 7 миллионнан 10,5 миллионга арткан [Foxman, 2003; Schappert, Rechtsteiner, 2011].

Кагыйдә буларак, кайда барлыкка килүенә карап, БЧСИләрне бүлеп чыгару системасының өске (бөер лоханкалары һәм сидек юллары) һәм аскы өлкәләре (сидек куыгы һәм сидек чыгару каналы) инфекцияләренә бүлеп карыйлар (1 нче рәс.). Шулай ук әлеге инфекцияләр төрле факторлар тәэсирендә катлауланган булырга да мөмкин [Ермоленко с соавт., 2012], ә катлауланмаган БЧСИләр гадәттә бәвел чыгару юлларында структур һәм функциональ үзгәрешләр булмаган кешеләрдә очрый.

БЧСИләрне күпчелек очракта шартлы патоген энтеробактерияләр китереп чыгара.

[1] Амбулатор инфекция – хастаханәдә ятмаган кешедә барлыкка килгән инфекция.




1 нче рәсем. Бүлеп чыгару системасының төзелеше [Urinary system anatomy and function, 2016]

Әлеге бактерияләр, гадәттә, эчәклекнең нормаль микрофлорасы составына керә, әмма, эчәклектән уретрага күчеп, сидек куыгы һәм бүлеп чыгару системасының өске өлкәләренә үтеп керергә һәм анда ялкынсыну тудырырга сәләтле. Анатомик төзелеш үзенчәлекләре сәбәпле (киң кыска уретра), әлеге инфекцияләр хатын-кызларда, ир-атларга караганда, ешрак очрый [Urinary tract infection in adults, 2012; Urinary tract infection: how bacteria nestle in, 2016]. Нигездә, йөкле булмаган хатын-кызларда БЧСИ җиңел уза һәм уңышлы дәвалана. Әмма йөкле хатын-кызларда авыру барышы катлаулана ала, ә бу исә пиелонефрит, вакытыннан алда бала табуга һәм хәтта яралгының үлеменә дә китерергә мөмкин [Foxman, 2003].

БЧСИ кузгатучы бактерияләр арасында грам-тискәре микроорганизмнар да, грам-уңайлары да очрый. Чит илләрдә һәм Россиядә үткәрелгән тикшеренүләргә караганда, күпчелек очракта БЧСИләрнең сәбәпчесе булып *Enterobacteriaceae* семьялыгына караган грам-тискәре бактерияләр, бигрәк тә *Escherichia coli*, *Klebsiella spp.* һәм *Proteus mirabilis* бактерияләре тора [Kahlmeter, 2003; Schito *et al.,* 2009; Палагин с соавт., 2012; Исследование чувствительности возбудителей внебольничных неосложненных инфекций мочевыводящих путей – UTIAP, 2013]. Грам-уңай микроорганизмнар бу төр авыруларны сирәк, өлкән яшьтәге кешеләрдә, йөкле хатын-кызларда һәм катнаш инфекция очракларында гына китереп чыгарырга сәләтле [Kline, Lewis, 2016].

БЧСИләрнең төп сәбәпчесе булган *E. coli* бактерияләре шулай ук җенес әгъзалары һәм эчәклек инфекцияләре китереп чыгарырга да мөмкин. Киң таралган шартлы патогеннар арасында антимикроб матдәләргә карата чыдамлылык (резистентлык) барлыкка килү һәм таралу белгечләр арасында җитди борчылу тудыра. Мондый авырулар еш очраганлыктан, бактерияләр арасында резистентлык таралу тизлеге дә зур, әмма төрле җирлектә бу күрсәткеч төрлечә була. Мәсәлән, *E. coli* штаммнарының амикацинга (3 нче буын аминогликозидлар төркеменә караган антибиотик) карата сизгерлеге төрле илләрдә аерылып тора. Әйтик, 2002–2004 елларда АКШ һәм Европа хастаханәләрендә бүлеп алынган *E. coli* штаммнарының амикацинга чыдамлылыгы 0–1,6% һәм 0,3–1,1% тәшкил итсә, безнең илдә бу күрсәткеч 38,3% җитә [Hoban *et al.,* 2006;

Reinert *et al.,* 2007; Рябкова, 2009]. Моннан тыш, 2000 һәм 2011 елларда Россия һәм халыкара оешмалар тарафыннан үткәрелгән күзәтү нәтиҗәләре дә *E. coli* штаммнарының антибактериаль матдәләргә каршы торучанлыгы артуын күрсәтә [Kahlmeter, 2003; Schito *et al.,* 2009; Палагин с соавт., 2012; Исследование чувствительности возбудителей внебольничных неосложненных инфекций мочевыводящих путей – UTIAP, 2013].




2 нче рәсем. 2012–2013 елларда Казан шәһәрендә амбулатор БЧСИләрне кузгаткан бактерияләр (тикшерелгән штаммнар саны – 2490)

Безнең тарафтан 2012 елның гыйнварыннан 2013 елның декабрь аена кадәр Казан шәһәрендә бүлеп алынган БЧСИ кузгатучы бактерияләргә статистик анализ үткәрелде: аларның төр составы һәм антибиотикларга карата чыдамлылыгы тикшерелде.

Тикшеренү эшендә Казан шәһәре «Биомед» дәвалау-диагностика үзәге тарафыннан 2012–2013 елларда үткәрелгән бактериологик анализ нәтиҗәләре кулланылды. Әлеге оешма билгеләнгән вакыт аралыгында барлыгы 6818 кешенең бәвелен анализлады, шуларның 33,8% ында (2300 очракта) бактериаль инфекция барлыгы ачыкланды. 2300 бәвел үрнәгендә табылган бактерияләрнең төр составы Казан шәһәре территориясендә БЧСИ сәбәпчесе булган төп микроорганизмнарны ачыкларга ярдәм итте. Беренче өчлеккә *E. coli* (1176/47,2%), *Enterococcus faecalis* (575/23,1%) һәм *Klebsiella pneumoniae* (336/13,5%) бактерияләре эләкте (2 нче рәс.).

Бүлеп алынган бактерияләрнең антибиотикларга сизгерлеге Мюллер – Хинтон туклыклы тирәлегендә дисклар диффузиясе ысулы ярдәмендә билгеләнде. Грам-тискәре уропатогеннарга карата түбәндәге 13 антибиотикның тәэсире тикшерелде: ампициллин, амоксициллин, цефтазидим, цефатаксим, цефазолин, нитрофурантоин, налидикс кислотасы, гентамицин, амикацин, нитроксолин, доксициклин, ципрофлоксацин һәм азитромицин. Грам-уңай микроорганизмнарга карата ампициллин, амоксициллин, нитрофурантоин, доксициклин, ципрофлоксацин һәм азитромицин кебек антибиотикларның тәэсире билгеләнде. Алынган нәтиҗәләргә аңлатма бирү өчен МУК 4.2.1890-04 «Определение чувствительности микроорганизмов к антибактериальным препаратам» тәкъдимнәре кулланылды. Чыдам штаммнарның өлеше 20% тан арткан очракта,

әлеге төр штаммнарының бар популяциясе дә сайланган антибиотикка чыдам дип табылды. Хәзер һәрбер микроорганизмны аерым карап китик.

***E. coli***. Кулланылган антимикроб матдәләрдән *E. coli* штаммнарына карата иң югары тәэсирне амикацин (90,6%) һәм нитроксолин (90,1%) күрсәтте. Моннан тыш, әлеге штаммнар нитрофурантоин (82,1%) һәм III буын цефалоспориннар – цефтазидим (84,1%) һәм цефатаксимга (83,4%) карата сизгер иде. Штаммнарга иң аз тәэсир иткән антибиотиклар рәтенә амоксициллин, доксициклин һәм азитромицин (49,7%, 50,6% һәм 47,9%) керде, шулай ук бу бактерияләр фторхиналоннар төркеменә караган ципрофлоксацинга да чыдам булып чыкты (21,7%, 3 нче рәс.).

Алынган нәтиҗәләр, тулаем алганда, Россия Федерациясе буенча күрсәткечләрдән аерылып тора: әйтик, ДАРМИС мәгълүматларына караганда, Россиянең башка төбәкләрендә амикацин һәм нитрофурантоинга карата сизгер *E. coli* штаммнары ешрак очрый (98,2%). Шул ук вакытта ципрофлоксацинга чыдамлылык дәрәҗәсе нык аерылмый, һәм 20,1% ны тәшкил итә. Әлеге күренешне фторхиналоннарны сулыш юллары инфекцияләрен дәвалауда еш куллану белән аңлатып була [Козлов, Голуб, 2014].

***K. pneumoniae.*** Әлеге төрнең штаммнары иң югары сизгерлекне амикацин (95,8%) һәм нитроксолин (90,5%) антибиотикларына карата күрсәтте, ә иң аз тәэсир иткән матдәләр рәтенә азитромицин (19,3%), нитрофурантоин (45,5%), амоксициллин (47%) һәм доксициклин (52,1%) керде. Моннан тыш, *K. pneumoniae* изолятлары арасында III буын цефалоспориннарга




3 нче рәсем. *E. coli* штаммнарының төрле антибиотикларга сизгерлеге (штаммнар саны – 1176).

чыдам штаммнар да табылды: цефтазидим һәм цефатаксимга резистент штаммнарның өлеше 22% һәм 22,9% тәшкил итте (4 нче рәс.). Тикшерелгән амбулатор БЧСИ кузгатучы штаммнар, госпиталь штаммнары белән чагыштырганда, бар төр антибиотикларга карата да күпкә түбәнрәк резистентлык күрсәтте. Россия буенча, тулаем алганда, кайбер антибиотикларга чыдам штаммнарның өлеше бик югары булып чыкты, бу гентамицин (75,2%), амикацин (31,4%) һәм ципрофлоксацинга (38,1%) кагыла [Решедько с соавт., 2008]. Шунысы кызык: Казан шәһәрендә алдагы антибиотикларга чыдам *K. pneumoniae* штаммнарының өлеше бары 18,2%, 4,2% һәм 12,8%-ка гына җитте.

***E. faecalis***. Өйрәнелгән *E. faecalis* штаммнарына карата иң югары активлыкны пеницилиннар рәтенә караган антибиотиклар күрсәтте: амоксициллинга карата штаммнарның 95,5%, ы, ә ампициллинга карата – 92,9% ы сизгер булып чыкты. Шул ук вакытта, штаммнарның 36% ы азитромицинга, ә 44,7% ы доксициклинга карата чыдамлылык күрсәтте (5 нче рәс.). Әлеге факт бу антибиотикларны *E. faecalis* кузгаткан инфекцияләр вакытында куллану файдасыз һәм мәгънәсез икәнлеге турында сөйли ала.

Шулай итеп, *E. coli* һәм *K. pneumoniae*га каршы иң көчле тәэсирне аминогликозидлар төркеменнән амикацин һәм хинолоннар төркеменнән нитроксолин антибиотиклары күрсәтте. Алынган нәтиҗәләрне фәнни әдәбият мәгълүматлары белән чагыштыргач, бездәге амикацинга чыдам *E. coli* штаммнарының өлеше чит илләргә караганда югары, әмма Россиянең башка төбәкләре белән чагыштырганда күпкә түбән икәнлеге ачыкланды.




4 нче рәсем. *K. pneumoniae* штаммнарының төрле антибиотикларга сизгерлеге (штаммнар саны – 336)




5 нче рәсем. *E. faecalis* штаммнарының төрле антибиотикларга сизгерлеге (штаммнар саны – 575)

*E. faecalis*ка килгәндә, әлеге бактерияләргә каршы иң тәэсирле антибиотик – бета-лактамнар сыйныфыннан амоксициллин һәм ампициллин, ә иң «көчсезе» – азитромицин һәм доксициклин булып чыкты. Нәтиҗәләр уропатогеннар арасында фторхинолоннарга карата чыдамлылык киң таралганлыгын да күрсәтте: 2012–2013 елларда Казан шәһәре территориясендә бүленгән изолятларның 20% ы әлеге антибиотикларга резистент булып чыкты. ДАРМИС мәгълүматлары буенча да 2010–2011 елларда Россия төбәкләрендә өйрәнелгән штаммнарның 10,9% ы фторхинолоннарга чыдам булганы ачыкланды. Әлеге факт хәзерге вакытта актив кулланылышта булган фторхинолоннарның якын киләчәктә кулланылыштан төшеп калачагы турында сөйли.

Шулай итеп, Казан шәһәре территориясендә өйрәнелгән амбулатор БЧСИ кузгатучы бактерияләренең төр составы да, резистентлык дәрәҗәсе дә Россия буенча алынган мәгълүматлардан аерыла. *E. faecalis* һәм *K. pneumoniae* төрләренең еш очравы (шулай ук резистентлык дәрәҗәсендәге аермалыклар) амбулатор инфекцияләрнең хроник формага күчкән һәм билгеле бер шартларда кискенләшкән госпиталь инфекцияләре икәне турында сөйли.

Билгеле бер авыруны кузгатучы агентлар төрле илләрдә генә түгел, бер ил эчендә дә аерылып торырга мөмкин, ә бу исә әлеге бактерияләр арасында резистентлык дәрәҗәсенең артуын һәм таралуын даими рәвештә күзәтеп барырга кирәклеге турында сөйли. Мондый тикшеренүләр, бер яктан, кулланышта булган һәм резерв төркемдәге антибиотикларга чыдамлылык арту темпын билгеләргә ярдәм итсә, икенче яктан, әлеге проблемага киң җәмәгатьчелекнең (микробиологлар, табиплар, авырулар) игътибарын җәлеп итәргә һәм дәвалауның яңа ысулларын табарга мөмкинлек бирәчәк.

**Әдәбият**

*Ермоленко В.М., Филатова Н.Н., Малкоч А.В.* Инфекция мочевых путей и ее лечение в возрастном аспекте // Лечащий врач. 2012. № 8. С. 8.

Исследование чувствительности возбудителей внебольничных неосложненных инфекций мочевыводящих путей – UTIAP // Межрегиональная ассоциация по клинической микробиологии и антимикробной химиотерапии. 2013. Режим доступа: http://www.antibiotic.ru/iacmac/ru/rosnet/utiap.shtml.

*Козлов Р.С., Голуб А.В.* Выбор антимикробных препаратов при неосложненных инфекциях мочевых путей: как принять соломоново решение // Клин. микробиол. антимикроб. химиотер. 2014. Т. 16(1). С. 18–25.

*Палагин И.С., Сухорукова М.В., Дехнич А.В. и др.* Современное состояние антибиотикорезистентности возбудителей внебольничных инфекций мочевыводящих путей в России: результаты исследования «ДАРМИС» (2010–2011) // Клин. микробиол. антимикроб. химиотер. 2012. Т.14. С. 280–302.

*Решедько Г.К., Рябкова Е.Л., Кречикова О.И. и др.* Резистентность к антибиотикам грамотрицательных возбудителей нозокомиальных инфекций ОРИТ многопрофильных стационаров России // Клин. микробиол. антимикроб. химиотер. 2008. Т. 10 (2). С. 96–112.

*Рябкова Е.Л., Иванчик Н.В., Сухорукова М.В. и др.* Резистентность нозокомиальных штаммов *Escherihia coli* в стационарах России // Клин. микробиол. антимикроб. химиотер. 2009. Т. 11. С. 161–169.

*Foxman B.* Epidemiology of urinary tract infections: incidence, morbidity, and economic costs // Dis Mon. 2003. V. 49 (2). P. 53–70.

*Hoban D., Bouchillon S., Stevens T., Johnson J., Hsiung A., Badal R., Dowzicky M.* Tigecylcine in vitro activity in current European pathogens – T.E.S.T. Programm 2006 // Programs and abstracts of the 16th European Congress of Clinical Microbiology and infection diseases, Nice, France, 2006. P. 490.

*Kahlmeter G.* An international survey of the antimicrobial susceptibility of pathogens from uncomplicated urinary tract infections: the ECO.SENS Project // J. Antimicrob. Chemother. 2003. T. 53. P. 69–76.

*Kline K.A., Lewis A.L.* Gram-positive uropathogens, polymicrobial urinary tract infection, and the emerging microbiota of the urinary tract // Microbiol Spectr. 2016. V. 4(2). P. 1–54.

*Reinert R.R., Low D.E., Rossi F., etc.* Antimicrobial susceptibility among organisms from the Asia / Pacific Rim, Europe and Latin and North America collected as part of TEST and the in vitro activity of tygecyclin // J. Antimicrob. Chemother. 2007. V. 60. P. 1018–1029.

*Schappert S.M., Rechtsteiner E.A.* Ambulatory medical care utilization estimates for 2007 // Vital Health Stat. 2011. V. 13. P. 1–38.

*Schito G.C., Naber K.G., Botto H., etc.* The ARESC study: an international survey on the antimicrobial resistance of pathogens involved in uncomplicated urinary tract infections // Int. J. Antimicrob. Agants. 2009. T. 35(5). P. 407–413.

Urinary system anatomy and function / Cincinnati Children's Hospital Medical Center. 2016. Access mode: https://www.cincinnatichildrens.org/health/u/urinary-system.

Urinary tract infection: How bacteria nestle in / Infection control today. 2016. Access mode: http://www.infectioncontroltoday.com/news/2016/03/urinary-tract-infection-how-bacteria-nestle-in.aspx.

Urinary tract infection in adults / National Institute of Diabetes and Digestive and Kidney Diseases. 2012. Access mode: http://www.niddk.nih.gov/health-information/health-topics/urologic-disease/urinary-tract-infections-in-adults/Pages/facts.aspx.

*Тикшеренү эше Казан (Идел буе) федераль университетенның дөньякүләм әйдәп баручы фәнни-белем бирү үзәкләре арасында көндәшлек сәләтен арттыруга юнәлтелгән Дәүләт программасы кысаларында тормышка ашырылды.*

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Миңнуллина Ләйлә Фәрваз кызы**,*
*Казан федераль университеты аспиранты,*
*Фундаменталь медицина һәм биология институтының*
*кече гыйльми хезмәткәре*

***Шәйдуллина Эльвира Расил кызы**,*
*Казан федераль университеты магистранты,*
*Фундаменталь медицина һәм биология институтының*
*кече гыйльми хезмәткәре*

УДК 579.852

***Л.Ф. Миңнуллина,***
***Г.Ф. Һадиева***

# БИОПРЕПАРАТЛАР БУЛАРАК КУЛЛАНЫРГА ЯРАКЛЫ ЯҢА *BACILLUS SUBTILIS* ШТАММНАРЫ

В данной работе была исследована фунгицидная активность бактерий рода *Bacillus*, выделенных из ризосферы картофеля. Изоляты бактерий идентифицированы как новые штаммы *Bacillus subtilis* по гомологии гена 16S рРНК и обозначены как *B. subtilis* GM2 и *B. subtilis* GM5. Штаммы охарактеризовали по их способности ингибировать рост фитопатогенных грибов родов *Alternaria*, *Fusarium*, *Colletotrichum* и *Doratchomyces*. Показано, что штамм *B. subtilis* GM5 ингибирует рост микромицетов эффективнее, чем штамм GM2. *B. subtilis* GM5 является потенциальным агентом биоконтроля и может быть использован в качестве биопрепарата против фитопатогенов сельскохозяйственных культур.

**Ключевые слова:** ризосфера, *Bacillus subtilis*, фитопатогены, антагонизм.

Соңгы дистә елда үсемлек һәм микроорганизмнар берләшмәләрен өйрәнүгә багышланган тикшеренүләр саны арта бара. Мондый берләшмәләр үсемлекләрнең үсешен һәм сәламәтлеген саклауда мөһим роль уйный, ә бу исә тотрыксыз табигый шартларда авыл хуҗалыгы культураларыннан стабиль уңыш алырга мөмкинлек бирә. Шулай да, әлеге мәсьәлә интенсив рәвештә өйрәнелүгә карамастан, үсемлекләр һәм микрофлора мөнәсәбәтләренең күпчелек яклары бүгенге көнгәчә ачыкланып бетмәгән [Farrar *et al.*, 2014].

Үсемлекнең тамыры белән бәйләнештә торган туфрак катламы ризосфера дип атала, ә бу катламда яшәүче бактерияләр ризосфера микроорганизмнары яисә ризобактерияләр дигән исем йөртә [Dobbelaere *et al.*, 2003]. Әлеге микроорганизмнарның үсемлек тамырлары белән бәйләнешкә керүе үсемлекләрнең продуктлылыгын билгеләүдә төп фактор булып тора [Choudhary, Johri, 2009; Khan *et.al.,* 2015]. Үсемлекләр өчен файдалы үзлекләргә ия бактерияләрне бүгенге көндә PGPR (*инглиз.* plant growth-promoting *Rhizobacteria* – үсемлекләргә үсәргә булышучы ризобактерияләр) дип атау гамәлгә кергән. Авыл хуҗалыгы өчен мөһим сыйфатларга ия булганлыктан, PGPR бактерияләре киң катлам тикшеренүчеләрнең игътибарын җәлеп итә. Моның төп сәбәбе булып әйләнә-тирәне саклау максатыннан химик ашламалар куллануны киметү тенденциясе һәм шул шартларда игенчелекне үстерү проблемасы тора.

PGPR бактерияләренең үсемлекләр дөньясы өчен файдалы төп үзлеге – үсемлекләрнең үсеш тизлеген һәм продуктлылыгын арттыру [Ngoma *et.al.,* 2012].

PGPR төркеменә төрле ыру вәкилләре керә ала, әмма күпчелекне *Bacillus* һәм *Pseudomonas* ыруларына караган бактерияләр тәшкил итә [Podile, Kishore, 2006]. Ризобактерияләр һавадагы азотны бәйләргә, сидерофорлар, антибиотиклар һәм глюканаза, амилаза, целлюлаза, пектиназа, протеаза, липаза, хитиназа кебек гидролитик ферментлар бүлеп чыгарырга сәләтле. Әлеге матдәләрнең бирәүләре фитопатоген гөмбәләрнең күзәнәк тышчасын тарката алса, башкалары фосфор, калий, цинк кушылмаларының эрүчәнлеген арттырып, аларны үсемлекләр үзләштерә алырлык халәткә китерә һәм шуның белән аларның минераль матдәләр белән тәэмин ителешен яхшырта. Моннан тыш, фитогормоннар һәм ферментлар синтезлап, ризобактерияләр тамыр системасының үсешен яхшырта һәм ризобиум-микориза симбиозлары барлыкка килүгә арадашлык итә ала [Vacheron *et al*., 2013].

Фитопатоген микроорганизмнар, азык-төлек җитештерүгә генә түгел, экосистемаларның тотрыклылыгына да куркыныч янаучы төп факторларның берсе булып тора [Wu *et al*., 2015]. Әлеге авырулар ел саен дөньяда җитештерелгән уңышның 25% ын юкка чыгара [Lugtenberg *et al*., 2015], бигрәк тә җиләк-җимеш, яшелчә, эфир майлары культураларын җитештерүче хуҗалыкларга зур зыян килә [Анисимов с соавт., 2009]. Татарстан Республикасы өчен мөһим азык-төлек культураларыннан саналган бәрәңге дә (*Solanum tuberosum*) күп төрле корткычлардан һәм авырулардан зарар күрә. Бәрәңге авыруларын китереп чыгаручы агентлар рәтенә вируслар, вироидлар, бактерияләр һәм микроскопик гөмбәләрне кертәләр [Асатурова с соавт., 2009]. Иң куркыныч гөмбә авыруларыннан түбәндәгеләр санала: бәрәңге фузариозы (кузгатучысы – *Fusarium solani*), ризоктониоз (кузг. – *Rhizoctonia solani*), көмешсыман парша (кузг. – *Helminthosporium solani*), бәрәңге фомозы (кузг. – *Phoma exigua*), бәрәңге фитофторозы (кузг. – *Phytophthora infestans*) һәм альтернариоз (кузг. – *Alternaria solani, Alternaria alternata*) [Анисимов с соавт., 2009]. Бәрәңге бактериозларына (ягъни бактерияләр китереп чыгара торган авыруларга) исә караяк (кузг. *Erwinia carotovora*), боҗрасыман черек (кузг. – *Clavibacter michiganensis*) һәм коңгырт черек (кузг. – *Ralstonia solanacearum*) керә [Морозкина с соавт., 2009]. Шуңа күрә бәрәңгенең теләсә кайсы яңа сорты бу патогеннарга карата күпмедер дәрәҗәдә чыдамлылыкка ия булырга тиеш [Лебедева, 2014].

Әлеге авырулар белән көрәштә хуҗалыклар ярты гасырдан артык агрохимикатларны уңышлы файдаланган булса да [Schafer *et al*., 2015], тора-бара бу кушылмаларның тискәре тәэсире ачыклану, яңа, экологик яктан зарарсыз ысуллар эзләргә мәҗбүр итте. Шунлыктан XXI гасырда үсемлек авырулары белән көрәштә фитопатогеннарның табигый дошманнарын куллану тенденциясе көннән-көн арта һәм өлешчә пестицидларны

алыштыра бара [Qiao *et al.*, 2014]. Бу максаттан антагонист бактерияләрдән ясалган биопрепаратлар булдыру һәм кулланышка кертү – авыл хуҗалыгы биотехнологиясендә көн кадагында торган мәсьәләләрнең берсе. Әлеге күзлектән *Bacillus* ыруы бактерияләреннән ясалган биопрепаратлар иң өметлеләрдән санала [Borriss *et al.*, 2015; Kamilova *et al.*, 2015; Mora *et al.*, 2015], шуңа күрә безнең максатыбыз да Татарстан туфрагыннан бүлеп алынган *Bacillus* ыруы бактерияләреннән җирле фитопатогеннарга каршы актив штаммнар сайлап алу булды.

Бәрәңге ризосферасыннан *Bacillus* ыруына караган аэроб, грам-уңай, эндоспоралар хасил итәргә сәләтле һәм черек гөмбәләренә карата югары активлык күрсәткән ике штамм бүлеп алынды. Аларга GM2 и GM5 дигән шартлы исем бирелде. Әлеге бактерияләрнең нинди төргә каравын билгеләү өчен, аларның 16S рРНК гены секвенлаштырылды. Геннарның нуклеотидлар эзлеклелеген анализлау, GM2 изолятының *B. subtilis* JCM 1465 штаммына (99%), ә GM5 изолятының *B. subtilis* 168 штаммына (98%) якын торуын күрсәтте. Шул рәвешле, секвенлаштыру нәтиҗәләренә таянып, бу бактериаль изолятлар *B. subtilis* төренең яңа штаммнарына тиңләштерелде.

Сканлаучы электрон микроскоп ярдәмендә *B. subtilis* GM2 һәм GM5 бактерияләренең морфологиясе өйрәнелде. 1 нче рәсемнән күренгәнчә, әлеге штаммнарның күзәнәкләре башлары түгәрәкләнгән таякчыклардан гыйбарәт. Һәр ике штаммның да морфологиясе тиңдәш һәм бары күзәнәк зурлыгы белән генә аерыла: *B. subtilis* GM5 штаммының күзәнәкләре эрерәк, озынлыкка – 1,80–2,50 мкм, киңлеккә 0,63–0,72 мкм тәшкил итә. *B. subtilis* GM2 штаммы өчен 1,61–2,50 мкм (озынлыгы) һәм 0,52–0,61 мкм (киңлеге) күрсәткечләре хас.

*B. subtilis* GM2 һәм GM5 штаммнарының фунгистатик (ягъни микроскопик гөмбәләр үсешен тоткарлау) үзлеген билгеләүдә агар блоклары ысулы кулланылды. Антагонистик активлык дәрәҗәсе бактерияләр белән бергә үскән микромицетларның,




1 нче рәсем. *B. subtilis* GM2 һәм GM5 бактерияләренең морфологиясе (Merlin Zeiss сканлаучы электрон микроскобы)

контроль вариант (микромицет үзе генә) белән чагыштырганда, үсеше тоткарлану буенча билгеләнде. *B. subtilis* GM2 һәм *B. subtilis* GM5 штаммнары барлык кулланылган фитопатоген микромицетларга карата да антагонистик активлык күрсәтте. Бу гөмбәләргә түбәндәгеләр керде: *Fusarium avenaceum, Fusarium oxysporum*, *Fusarium redolens, Fusarium solani, Alternaria alternate* ТП 712, *Alternaria solani* 12РКЛ15, *Alternaria tenuissima*, шулай ук *Doratchomyces sp.* 14 raKKLD һәм *Colletotrichum coccodes* 14raKK6 (2 нче рәс.).

1 нче таблицада *B. subtilis* штаммнарының тәҗрибәнең 7нче тәүлегенә микромицетлар үсешен никадәр тоткарлавы күрсәтелгән. Ике штамм да иң күбе *Doratchomyces sp.* 14 raKKLD (GM2 – 72% һәм GM5 – 79%) һәм *C. coccodes* 14raKK6 (GM2 – 53% һәм GM5 – 63%) микромицетларына тәэсир иткән. Шулай да антагонистик эффектын ныграк күрсәткән штамм *B. subtilis* GM5 икәнлеге аңлашыла. Әйтик, GM5 штаммы *A. alternate* ТП 712, *F. avenaceum, F. redolens* гөмбәләренең үсешен 72%, 66% һәм 65% ка тоткарласа, GM2 штаммы шул ук микромицетларның үсешен 48%, 54% һәм 55% ка киметә.

Шулай итеп, бәрәңге ризосферасыннан фитопатоген гөмбәләрнең үсешен тоткарларга сәләтле яңа *B. subtilis* штаммнары бүлеп алынды. Әлеге изолятларның үзлекләрен өйрәнү, *B. subtilis* GM5 штаммының фитопатогеннарга каршы биопрепарат буларак кулланылырга яраклы икәнлеген күрсәтте.



2 нче рәсем. *B. subtilis* GM2 һәм GM5 бактерияләренең фитопатоген микромицетларга тәэсире: 1 – *A. alternate* ТП 712, 2 – *A. solani* 12РКЛ15, 3 – *A. tenuissima*, 4 – *C. coccodes* 14raKK6, 5 – *Doratomyces sp.* Сулдан беренче – контроль (бактерияләрдән башка үскән) гөмбәләр

*1 нче таблица.*

*B. subtilis* GM2 һәм GM5 штаммнарының микромицетлар үсешен тоткарлавы

| № | Микромицетлар | 7 тәүлектә үсешне тоткарлау, % | |
|---|---|---|---|
| | | *B. subtilis* GM 2 | *B. subtilis* GM 5 |
| 1. | *A. alternate* ТП 712 | 48,5±2,5 | 72,7±3,1 |
| 2. | *A. solani* 12РКЛ15 | 45,5±2,2 | 51,5±2,4 |
| 3. | *A. tenuissima* | 45,7±2,2 | 60,0±2,7 |
| 4. | *C. coccodes* 14raKK6 | 53,3±2,8 | 63,3±2,9 |
| 5. | *Doratomyces sp.* 14 raKKLD | 72,4±3,1 | 79,3±3,4 |
| 7. | *F. avenaceum* | 54,8±2,6 | 66,7±3,0 |
| 8. | *F. oxysporum* | 43,2±1,9 | 54,1±2,3 |
| 9. | *F. redolens* | 55,3±2,3 | 65,8±2,9 |
| 10. | *F. solani* | 44,2±2,0 | 58,1±2,7 |

**Әдәбият**

*Анисимов Б.В., Белов Г.Л., Варицев Ю.А. и др.* Защита картофеля от болезней, вредителей и сорняков. М.: Издательский дом Ивана Корытова, 2009. 272 с.

*Асатурова А.М.* Перспективные штаммы бактерий – продуценты микробиопрепаратов для снижения вредоносности фузариоза на подсолнечнике: автореф. дис. … канд. биол. наук // Всерос. НИИ защиты растений. СПб., 2009. 22 с.

*Лебедева В.А., Гаджиев Н.М.* Экспериментальная полиплоидия и инцухт в селекции картофеля на высокую продуктивность и качество клубней // Защита картофеля. 2014. Т. 1. С. 15–16.

*Borriss R.* «*Bacillus*, a plant beneficial bacterium» in Principles of plant-microbe interactions. Microbes for sustainable agriculture. Berlin: Springer, 2015. V. 24. P. 379–391.

*Choudhary D.K., Johri B.N.* Interactions of *Bacillus spp.* and plants – With special reference to induced systemic resistance (ISR) // Microbiol. Research. 2009. V. 164. P. 493–513.

*Dobbelaere S., Vanderleyden J., Okon Y.* Plant growth-promoting effects of diazotrophs in the rhizosphere // CRC Crit. Rev. Plant Sci. 2003. V. 22. P. 107–149.

*Farrar K., Bryant D., Cope-Selby N.* Understanding and engineering beneficial plant-microbe interactions: plant growth promotion in energy crops // Plant Biotechnol. J. 2014. V. 12, No. 9. P. 1193–1206.

*Kamilova F., Okon Y., Weert S., etc.* "Commercialization of microbes: manufacturing, inoculation, best practice for objective field testing, and registration", in Principles of plant-microbe interactions. Microbes for sustainable agriculture. Berlin: Springer. 2015. V. 40. P. 319–327.

*Khan M., Sessitsch A., Harris M., etc.* Cr-resistant rhizo- and endophytic bacteria associated with *Prosopis juliflora* and their potential as phytoremediation enhancing agents in metal-degraded soils // Front. Plant. Sci. 2015. V. 5, No. 755. P. 1–9.

*Lugtenberg B.J.* «Introduction to plant-microbe-interactions», in Principles of plant-microbe interactions. Microbes for sustainable agriculture. Berlin: Springer. 2015. V. 40. P. 1–2.

*Mora I., Cabrefiga J., Montesinos E.* Cyclic lipopeptide biosynthetic genes and products, and inhibitory activity of plant-associated *Bacillus* against phytopathogenic bacteria // PLoS One. 2015. V. 10., No. 5. P. 1–21.

*Ngoma L., Babalola O., Ahmad F.* Ecophysiology of plant growth promoting bacteria // Scientific Research and Essays. 2015. V. 7, No. 47. P. 4003–4013.

*Podile A.R., Kishore G.K.* Plant growth-promoting rhizobacteria. Springer, Netherlands. 2006. V. 8. P. 195–230.

*Qiao J., Wu H., Huo R., etc.* Stimulation and biocontrol by *Bacillus amyloliquefaciens* subsp. *plantarum* FZB42 engineered for improved action // Chem. Biol. Technol. Agric. 2014. V. 9. P. 1–14.

*Schäfer T., Adams T.* «The importance of microbiology in sustainable agriculture», in Principles of plant-microbe interactions. Microbes for sustainable agriculture. Berlin: Springer. 2015. V.9. P. 5–7.

*Vacheron J., Desbrosses G., Bouffaud M., etc.* Plant growth-promoting rhizobacteria and root system functioning // Front. Plant Sci. 2013. V. 57. P. 1–19.

*Wu L., Wu H.J., Qiao J., etc.* Novel routes for improving biocontrol activity of *Bacillus* based bioinoculants // Front. Microbiol. 2015. V. 6. P. 1–13.

*Тикшеренү эше Казан (Идел буе) федераль университетенның дөньякүләм әйдәп баручы фәнни-белем бирү үзәкләре арасында көндәшлек сәләтен арттыруга юнәлтелгән Дәүләт программасы кысаларында тормышка ашырылды.*

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Миңнуллина Ләйлә Фәрваз кызы,***
*Казан федераль университеты аспиранты, Фундаменталь медицина һәм биология институтының кече гыйльми хезмәткәре*

***Һадиева Гүзәл Фәнис кызы,***
*Казан федераль университеты магистранты, Фундаменталь медицина һәм биология институтының лаборант-тикшеренүчесе*

УДК 929

*Р.В. Шәйдуллин*

# ТАРИХЧЫ ГАЛИМ, ОСТАЗ
# ҺӘМ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МИЛЛӘТПӘРВАР УЛЫ

*(Вәлиев Рәмзи Кәлим улына 80 яшь тулу уңаеннан)*

Статья посвящена доктору исторических наук, профессору Казанского федерального университета Р.К. Валееву. В контексте юбилейной даты в ней системно рассматривается научная и педагогическая деятельность ученого, а также отмечаются его заслуги в области науки и образования. Особое внимание уделяется комплексному анализу наставнической деятельности Р.К. Валеева, направленной на подготовку из талантливой вузовской молодежи научных кадров высшей квалификации.

**Ключевые слова:** Рамзи Калимович Валеев, Татарстан, татарский народ, Казанский федеральный университет, исторический факультет, научная и педагогическая деятельность, наставничество, ученики, государственные награды и звания.

Тарихны кешеләр ясый. Үткәннәребез аларның уңыш-казанышларыннан һәм тайпылыш-хаталарыннан торганга күрә, ул катлаулы һәм гыйбрәтле. Аннан сабак алу фарыз, чөнки тарих галиҗәнаплары – кырыс хөкемдар, үзе белән исәпләшмәүне кичерми. Гасырлар дәвамында кешелек гаять күп сынауларга дучар ителә, әледән-әле дөньяның төрле почмакларында сугышлар кабына, яңа калалар һәм салалар барлыкка килә, күп кенә авыллар җир йөзеннән юкка чыгалар, туган-үскән йортларның да еш кына урыннары гына кала. Ә хәтер буыннардан-буыннарга күчә. Әгәр дә аны сакламасак, аерым бер нәселне генә түгел, тора-бара бөтен бер милләтне инкыйраз көтәчәк. Хәтер бетсә – үткәннәр җуела, ә инде үткәне юкның киләчәге дә булмый. Шуңа күрә үткәннәребезне, татар халкының һәм Татарстанның иҗтимагый-сәяси һәм этномәдәни тарихын өйрәнеп, аны халкыбызга кайтаручы һәм шул рәвешле тарихи хәтерне яңартучы галимнәребезнең, аерым алганда Казан федераль университеты тарихчыларының, нинди фидакарь һәм изге эш башкаруы ачык аңлашыла. Язмабыз аларның берсе – татар милли-демократик хәрәкәте тарихыннан саллы хезмәтләре белән танылган галим, тарих фәннәре докторы профессор Рәмзи Вәлиев хакында.

Тарих фәне аңа тәкъдире тарафыннан тәгаенләнгән. Хәер, балалык еллары сугыш чоры белән өтелгән малайга фән дөньясы баштарак нindидер сихри, романтик һәм шул ук вакытта буй җитмәслек өлкә булып тоела. Ни дисәң дә, ул чакта аның гаиләсендә дә, туган-тумачасы һәм таныш-белешләре арасында да бер генә гыйлем әһеле дә булмый бит. (Хәзерге вакытта

Р.К. Вәлиевнең кызы Эмилия – медицина фәннәре докторы, бертуганының улы Дамир Хәмит улы – юридик фәннәр докторы.) Шуңа да карамастан, әти-әнисе уллары сайлаган юнәлешкә дә, аның теләк-омтылышларына да тирән ихтирам белән карый, аңа һәрьяклап булышырга тырыша. Баксаң, үсеп җиткән егетнең һөнәр сайлавына мөнәсәбәттә авыл хуҗалыгына өстенлек биреп, шул өлкәгә караган белгечлек (агроном, бухгалтер, инженер һ.б.) алырга тәкъдим иткән дә булырлар иде.

Төрле чорларда (студентлык елларында, соңрак фән дөньясына кереп киткәч тә) аның белән аралашкан кешеләр күңелендә Рәмзи Вәлиев шәхесе күпкырлы, тынгысыз һәм шул ук вакытта гаять ярдәмчел образ буларак урын ала, чөнки аның фәнни һәм педагогик эшчәнлегенең һәр буыны кызыксыну һәм соклану уята. Р.К. Вәлиевнең тарих фәне үсешенә, белгечләр әзерләүгә һәм тәрбияләүгә керткән зур өлешен күз алдына китерү өчен аның тормыш юлының аерым бер чорлары белән танышып чыгу да җитә. Һичшиксез, бу феномен җентекләп өйрәнелүгә лаек, чөнки аның фәнни-педагогик эшчәнлеге гаять тирән мәгънәгә ия һәм бай иҗади потенциалны чагылдыра. Галимнең фәнни һәм фәнни-методик хезмәтләре Россиядә һәм Татарстанда тарих фәне нигезләренең киләчәктә дә ныгуын тәэмин итте, аларның теоретик җирлегендә илебез югары уку йортлары тарихчы-тикшеренүчеләренең берничә буыны үсеп җитлекте. Рәмзи Кәлимовичның исеме тарих елъязмасына керде, хаклы рәвештә Россия Федерациясендә, Татарстан Республикасында һәм Казан федераль университетында тарих фәне казанышларының лаеклы рәвештә үзенчәлекле чагылышына әверелде.

Ул 1937 елның 7 маенда Яшел Үзән районының Карашәм авылында Кәлимулла агай гаиләсендә дөньяга килә. Малайга Рәмзи исемен кушалар.

Татар халкында элек-электән инсан затына биреләчәк ат, исем билгеле бер дәрәҗәдә аның тәкъдирен тәгаенли дигән ышану таралган. Булачак галим исеменең сыйфатламалары арасында «үрнәк» дигән мәгънәсе дә бар. Аңа яшәеше дәвамында шул мәгънәгә тугры һәм лаеклы булырга туры килә – ул гомерлек имтихан тота.

Сынаулар белән Рәмзи Вәлиев гомер юлының һәр чатында очраша. Сугыш чоры баласы буларак, бик иртә кул арасына керә – тормыш арбасына җигелә. Сугыштан соңгы ачлы-туклы елларда авыр крестьян тормышының, исәпсез салымнар газапларының барлык авырлыкларын үз җилкәсендә татый. Шуңа да карамастан, кечкенәдән килгән белемгә омтылуданмы, әллә табигый кызыксыну хикмәтеме – мәктәпне яхшы билгеләргә тәмамлый. Совет Армиясендә хәрби хезмәтен тутырып кайтканнан соң, атаклы Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына юл тота. Ул заманда идеологик асылы көчәя барган әлеге факультетка керү җиңел булмый, әмма үҗәтлеге, белемгә омтылышы һәм Ходай биргән

сәләтләре үзенекен итә – кичәге солдат студент була, уку йортын 1963 елда уңышлы тәмамлый. Һәм шундук аны университеттагы иҗтимагый вазгыять һәм фәнни-педагогик тормыш үзенә бөтереп ала – университетның ВЛКСМ комитеты секретаре вазифасына тәкъдим ителә, бер үк вакытта ул философия кафедрасы ассистенты итеп тәгаенләнә. 1970 елда аны СССР тарихы кафедрасының өлкән укытучысы итеп раслыйлар, тагын биш елдан ул доцент вазифаларын башкара башлый. 1992 елдан бүгенгәчә Р.К. Вәлиев – хәзерге заман Ватан тарихы кафедрасы профессоры. Хәзерге көндә дә Рәмзи Кәлимович – университетның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Шәрекъне өйрәнү институты Ватан тарихы кафедрасының әйдәп баручы профессорларыннан берсе.

Баксаң, шаккатырлык – яңарак кына 80 яшьлек юбилеен билгеләп узган галимебезнең хезмәт биографиясенең биш дистә ярым еллар чамасы өлеше фәнни эзләнүләргә, укыту-педагогик эшчәнлеккә багышланган! Шул дәвердә ул дистәләрчә ачышлар ясаган һәм китаплар бастырган, профессорның лекцияләрен меңнәрчә студент – булачак галимнәрнең, укытучыларның һәм башка өлкәләрдә хезмәт куячак белгечләрнең берничә буыны тыңлаган. Ирексездән юбилярның гыйльми җәһәттә озын гомерле булуы феноменының асылы һәм сәбәпләре нидән гыйбарәт соң, дигән сорау туа. Бер караганда, җавап гади дә кебек. Р.К. Вәлиев яшьлек елларында ук даими рәвештә һәм максатчан юнәлештә үзенең белемнәрен баету һәм камилләштерү өстендә эшли, аның бу сыйфаты гомер юлы буйлап яңа кимәлләрдә көчәеп үсә бара. Ул, нинди генә вазифа башкарса да, һәрвакыт үзен кызыксындырган мәсьәләнең тулысынча төбенә төшәргә, аны һәрьяклап һәм җентекләп өйрәнергә, ачыкларга омтыла. Укыту процессыннан аерылмыйча гына, ул күпсанлы хезмәтләр язды, монографияләр дөньяга чыгарды. Киң күләмдә танылган абруйлы галим буларак, 1990 елда Россиядәге 1917 елгы гомуммилли кризисны этрафлы ачкан һәм анализлаган докторлык диссертациясе яклады, соңрак ул, баетылып, аерым монография рәвешендә дөнья күрде («Назревание общенационального кризиса и его проявление в Поволжье и на Урале в 1917 году», Казан, 1979). Бүгенге көндә без аны ике дистәгә якын монография һәм 300 дән артык фәнни, фәнни-популяр мәкалә авторы буларак беләбез. Әлеге сыйфаты – даими рәвештә үзенең профессиональ дәрәҗәсен күтәрүгә омтылышы – аның сыгылмалы, иң катлаулы фәнни һәм дөньяви мәсьәләләрне киң колачлы хәл итүгә сәләтле фикерләү көченең нигезен хасил итте.

Рәмзи Кәлимовичның төрле вазифалар башкарганда этрафлы һәм гаять нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге факультет җитәкчелегенең дә игътибарын җәлеп итте. 1981 елда ул тарих факультеты деканы урынбасары итеп билгеләнде, 1995 һәм 1998 елларда ике тапкыр әлеге

факультетның деканы булып сайланды. Казан университетының иң абруйлы факультетларының берсен очраклы рәвештә, кемнеңдер күңеленә хуш килеп кенә җитәкләү мөмкин түгел.

Р.К. Вәлиевнең декан буларак эшчәнлеге катлаулы һәм каршылыклар чиктән ашкан елларга туры килә. Укыту процессында 1991 елда СССР таркалганнан соң башланган демократик үзгәртеп корулар, акрынлап булса да, тизләнешле үсеш алалар. Татарстанда актив рәвештә республикадагы төп халыкларның милли яңарыш процессы бара, яңа партияләр һәм иҗтимагый хәрәкәтләр барлыкка килә. Соңгылары Россия һәм Татарстанның хакимияттәге югары даирәләренеке генә түгел, укытучылардан башлап вазифаи затларга кадәр югары уку йортлары мәгариф системасы вәкилләренең мәнфәгатьләрен дә алга сөрәләр. Тарих факультетының төрле фәнни, этносәяси һәм идеологик карашлы кешеләрне берләштергән коллективы объектив рәвештә илдә һәм республикада барган иҗтимагый, социаль, милли характердагы вакыйгаларның һәм күренешләрнең тулы бер җыелмасын чагылдыра һәм үзенчәлекле «идеяләр кайнаган казан»ны хәтерләтә. Әлеге шартларда факультет деканаты алдына катгый рәвештә университетның нәтиҗәле эшләүче укыту һәм фәнни бүлекчәсе буларак сакланып калу һәм бәхәс клубы түбәнлегенә тәгәрәмәү бурычы килеп баса. Ул чакта һәр җитәкче дә гыйльми җәмәгатьчелекнең аңында барган үзгәрешләрне һәм шуларның нәтиҗәсе булган гамәлләрне тиешенчә кабул итәргә, югары уку йортлары структураларына үзләрен каршы куйган затлар белән ачыктан-ачык фикер алышуга сәләтле түгел иде. Кемнәргәдер фәнни эшчәнлектәге һәм укыту процессындагы иске калыплар юл куймады, кемдер исә университетта тамырдан үзгәргән вазгыять белән санлашмады. Әмма иң зур бәла аларның күбесенең либераль-демократик система шартларында яшәргә теләгән кешеләрнең тормыш-психологик менталитеты үзгәрүен кабул итәргә әзер булмавыннан гыйбарәт иде. Әйе, үтә четрекле хәлләр хөкем сөрде ул заманда. Әлеге шартларда тарих факультетының җитәкчесеннән аңа ышанып тапшырылган структурада тискәре күренешләргә юл куймау, фәнни җәмәгатьчелекне тиешле юнәлешкә кертеп җибәрү өчен бик күп нәрсә таләп ителде һәм шул максатларда Рәмзи Кәлимович үзенең барлык тәҗрибәсен, зирәклеген һәм акылын эшкә җикте. Нәтиҗәдә факультеттагы укыту һәм фәнни-тикшеренү процессы аның демократик контролендә калды, күп кенә профессорлар һәм доцентлар аның йөзендә яңа шартларда тыныч һәм уңышлы эшләргә сәләтле җитәкче, ә студентлар исә зирәк һәм ышанычлы остаз күрделәр. Моңа ирешү, абруй казану асыл лидерлык сыйфатлары нигезендә мөмкин булды. Р.К. Вәлиевнең уртак фикергә килүгә омтылышы, чиктән тыш катгый, ара-тирә мәгънәсез таләпләр куючы оппонентларын да тыңлый белүе, фикер

каршылыклары булуга карамастан деканатның үзара килешенгән карарлар чыгаруы, факультетның профессорлар-укытучылар составы, ректорат белән тыгыз бәйләнештә эшчәнлек алып баруы аның җитәкчесенә карата тирән ихтирам уятты һәм аңа ышанычны ныгытты. Һичшиксез, Рәмзи Кәлимович Казан федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Шәрекъне өйрәнү институтында бүген тарихчы галимнәр даирәсендә хөкем сөргән демократиянең чишмә башында торды.

Ул декан вазифаларын башкарган чорда тарих факультеты гаять зур уңай үзгәрешләр кичерде, аның яңа сәясәте нәтиҗәсендә факультетның мөмкинлекләре, илнең төрле уку йортлары һәм кайбер чит илләрдәге университетлар белән багланышлары киңәйде.

Моннан тыш, Р.К. Вәлиев тарафыннан фәнни кадрларны саклау һәм яңадан әзерләү, укытучылар даирәсен яшәртү юнәлешендә максатчан эш алып барылды. Факультетны тәмамлаучылар арасыннан ел саен кандидатлык диссертацияләре якланды, эзлекле рәвештә тарих фәннәре докторлары саны арта барды – факультетта көчле фәнни потенциалга ия яңа гыйльми-педагогик алмаш барлыкка килде. Чагыштырмача кыска деканлык эшчәнлеге чорында ул җитәкләгән факультет Казан дәүләт университетының иң нәтиҗәле һәм уңышлы эшләүче бүлекчәләренең берсенә әверелде, анда бер төркем студентлар өчен тарих татар телендә укытыла башлады.

Тарихчы галим буларак, Рәмзи Кәлимович әтрафлы фәнни-тикшеренү эшчәнлеге алып бара. Яшь чагында археологик казу эшләрендә катнашты, аны Лаеш районының Рождествено авылы янындагы археологик комплексны өйрәнү нәтиҗәләренә багышланган «Рождествено авылы янындагы археологик истәлекләр» («Археологические памятники у села Рождествено». Казан, 1962) хезмәте авторларының берсе буларак та беләбез.

Галимнең төп эзләнүләре Урта Идел буе төбәгенең XX гасырның 1 нче чирегендәге иҗтимагый-сәяси тарихы, татар зыялылары, шул исәптән Борһанетдин, Гыйльметдин, Галимҗан һәм Шәһретдин Шәрәфләр язмышы, Татарстанда Сталин чоры репрессияләре мәсьәләләренә багышлана. Шуларның нәтиҗәсе буларак «Фаҗига» китабы дөнья күрә (Казан, 1996), ул ана телебездә басылган фундаменталь монография буларак фәнни даирәләрдә зур яңгыраш ала, җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә. Бу юнәлештә Р.К. Вәлиев әлеге хезмәт белән генә чикләнеп калмый, үзенең ачышлары белән бертуган Шәрәфләрнең акلануына хәлиткеч өлеш кертә, аларның кече ватанында – Буа районы Аксу авылында фәнни конференция, авыл укытучылары белән очрашу оештыра һәм уздыра, Казан урамнарының берсендәге (Жуковский урамы) бер йортка мемориаль такта урнаштыруга һәм Галимҗан Шәрәф каберенә таш куярга ярдәм итә. Ул, беренчеләрдән булып, Вәисиләр хәрәкәте тарихын,

Борһанетдин һәм Гайнетдин Вәиовларның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген өйрәнә, Г. Вәисовның рус әдәбияты классигы Л.Н. Толстой белән дусларча мөнәсәбәтен бәян итә. Әлеге мәсьәләләр буенча татар телендә тирәнтен дәлилләнгән «Өзелгән дога» (2007) дип аталган саллы китабы дөнья күрде.

Рәмзи Кәлимовичның гыйльми эшчәнлегенең тагын бер мөһим тармагы – Россиядә 1917–1918 еллардагы татар милли-азатлык хәрәкәтен яңача аңлау, шәрехләү нигезләрен булдыру юнәлешендә фәнни тикшеренүләр алып бару. Аерым алганда, «Болак арты республикасы» хезмәтендә (Казан, 1999) аның тарафыннан комплекслы рәвештә татар милли-демократик хәрәкәтендәге кризис һәм татар милли дәүләтчелек төзелешендә институциональ процессларның сүнүе сәбәпләре анализлана.

Галимнең фәнни тикшеренүләре арасында татар халкының милли мәнфәгатьләре суверенлашуы этапларына багышланган «Соңгы халык дошманы» («Последний враг народа». Казан, 2013) монографиясе аерым урын алып тора. Анда тәүге тапкыр Татарстанның беренче суверенлыгы тарихы бәян ителә. Нәтиҗәдә автор, беренчеләрдән булып, «ике суверенлык» теориясен нигезләп үстерә, әлеге теория аның тарафыннан Татарстанның сәяси һәм икътисади мөстәкыйльлеген, шулай ук татар халкының этномәдәни мәнфәгатьләрен киңәйтү яссылыгында карала.

Р.К. Вәлиевнең «милли тайпылыш» мәсьәләләре яктыртылган хезмәтләрендә (Милли тайпылыш, Мирас, 2004) тарих фәнендә беренче тапкыр татар интеллегенциясенең татар милли дәүләтчелеге, Урал-Идел Штатын һәм Татарстан республикасын төзү өчен көрәш манзарасын тергезү омтылышы ясала. Аерым игътибар Татарстан партия оешмасындагы төркемнәр көрәшенә юнәлтелә. Мөселман халкының милли-демократик хәрәкәтендә актив катнашкан татарларның язмышына кагылышлы материаллар зур урын били. Моннан тыш, һәрьяклап татар халкының милли мәнфәгатьләре кысаларында «уңнар»ның Татарстан республикасының суверенлыгы өчен көрәш процессы тикшерелә. Галимнең 1920 елларда Татарстан сәяси җитәкчелегендә «уңнар» һәм «суллар» арасында барган көрәшенә карата үзенчәлекле мөнәсәбәте һәм фикерләре дә игътибарга лаек.

Р.К. Вәлиев һәм Г.Ә. Фәттахованың Татарстан АССРның Мәгариф халык комиссариаты каршындагы академик үзәк эшчәнлегенә багышланган уртак монографиясендә («Академический центр Татарии. 1920-е годы», Казан, 2002) төбәкне өйрәнү белән шөгыльләнгән төрле структуралар (җәмгыятьләр, түгәрәкләр һ.б.) эшчәнлеген анализлау белән бергә татар халкының милли мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр дә яктыртыла.

Бүгенге көндә күпләр Р.К. Вәлиевнең үзләренең остазы булуы белән хаклы рәвештә горурланалар. Чирек гасыр чамасы дәвердә аның тарафыннан

тарих фәннәре өлкәсендә 2 фәннәр докторы (Р.В. Шәйдуллин, И.А. Чуканов), 10 нан артык фәннәр кандидаты (А.М. Вәлиев, Ә.А. Гатин, А.И. Диндаров, Л.М. Җаббарова, Г.Р. Кәримова, Л.О. Сулима, О.Н. Тихонов, Г.А. Фәттахова, К.Р. Шәкүров һ.б.) әзерләнде. Юбилярның шәкертләре Татарстанның, Мари Элның, Ульяновск өлкәсенең һәм башка төбәкләрнең төрле югары уку йортларында һәм тармак фәнни-тикшеренү институтларында эшлиләр.

Р.К. Вәлиев тарих фәнендә югары үрләр яулады – Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (1994), Россия Федерациясенең атказанган югары мәктәп хезмәткәре (2006), Казан дәүләт университетының атказанган профессоры (2007) исемнәренә, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләгенә (2011) һ.б. дәрәҗә-бүләкләргә лаек булды. Аның сикәлтәле тормыш юлы һәм фәнни эшчәнлеге фидакарьлек, кешелеклелек, башкаларны ихтирам итү, тырышлык, намуслылык, тугрылык кебек гүзәл үрнәкләр белән бизәлгән. Халкыбызның асыл улына, галимнәрнең укытучысына, остазыбызга ныклы саулык, озын гомер, фәнни эшчәнлегендә яңа казанышлар телибез. Афәрин, Рәмзи ага!

***Шәйдуллин Рафаил Вәли улы,***
*тарих фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Татар энциклопелиясе һәм тәбәкне өйрәнү*
*институтының энциклопедистика үзәге мөдире*

УДК 09:930.27

*Ф.З. Яхин*

## ДҮРТ ЯГЫМ КЫЙБЛА:
## Арчаның тарихи халкына бер сәяхәт

Комплексная экспедиция по изучению языковых особенностей, фольклора и культуры татар Арского и Атнинского районов Татарстана состоялась в 2016 году и была организована Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ. В статье излагаются значимые научные результаты экспедиции в плане археографии, эпиграфики, исторических жителей района, уточняются биографические данные некоторых исторических личностей, выходцев этой местности.

**Ключевые слова:** история Арского района Республики Татарстан, печатные и рукописные татарские книги XVIII–XIX веков, Габденнасыр Курсави, вклад Курсави в исламское реформаторство.

Арча һәм аның авыллары халкы кемне дә сокландырырлык. Тораклары төзек тә, чиста та, ә кешеләре – иманлы. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Халкыбызга ничәмә-ничә буын шагыйрьләр, язучылар, галимнәр, ил батырлары биргән як бу.

### I

Сәяхәтебез 2016 елның 27 июнь көнендә башланып китте. Без, бер төркем галим-голәмә, кайгыртучан хуҗаларның күрсәтмәләре нигезендә юлга чыктык. Сәяхәтебез Арча якларын тарихи-мәдәни-әдәби яктан комплекслы өйрәнеп кайту максатына корылган иде.

Миңа борынгы татар китапларын барлау, өйрәнү, фәнни әһәмияте булганнарын туплап алып кайту бурычы йөкләнгән иде.

Беренче тукталу урыны – Арчаның көнчыгыш тарафындагы Поченок Поник авылы.

Поченок Поник авылында мөселман татарлары яши, әмма тәүдә аны керәшен татарлары нигезләгән булып чыкты. Монда безнең экспедицияне авыл администрациясе башлыгы озата йөрде.

Моннан ерак түгел Ключище авылы да булган, аның хәзер урыны гына калган. Анда руслар яшәгән.

Поченок Поникта Исхакова Мәдинә Ибраһим кызында булдык. 1928 елгы. Аның кулында XIX йөзнең беренче яртысына нисбәтле басма китап – Коръән саклана. «Әлхәм сүрәсе» һәм алга таба ике сәхифәсе ертылган, уртадан берничә бите төшкән. Аларны кулдан язып тутырганнар. Мөһере дә бар. Анда «Кәрим бине Өммейәмин» дип сугылган. Китап Мәдинә әбигә әнисе Галимәдән мирас буларак калган. Ул, урман аша тугыз чакрымнар булыр, Балтач районына караган Каенбаш авылында яшәгән. Ә этисе Ибраһим исемле булган. Аңарда да китаплар бар иде, ди. Әмма йортлары беткән инде. Димәк, ул китаплар сакланмаганнар.

«Поник» сүзенең мәгънәсен авылда «утын диләнкәсе», «утынлык» буларак аңлаттылар. Монда кирпеч заводы булган. Шуның мичләрен кыздыру өчен бу авылныкылар агач күмере җитештергәннәр. Шушы эшкә килеп йөри торгач, ахырда, күпләр бу авылда төпләнеп тә калганнар.

Авыл башыннан, көнчыгыш тарафыннан, инеш агып чыга да көнбатышка юнәлә. Аның аргы ягында ике ихата күренә. Аларның яныннан биек яр сузыла. Арырак – урман. Көньякка табарак – зират. Монда кирәмәт бар икән. Анда элек марилар килә торган булганнар. Дини йолаларын үтәр өчен әлбәттә.

Әмма борынгы тарихлардан хәбәрдар кешеләр беләдер: кирәмәт дигәннәре – торاташ, ягъни балбал. Аларны скиф-сармат-кыпчаклар куя торган булганнар. Алар күчмә тормыш белән яшәүчеләрнең сакма-җәйләүләрендә юл күрсәткече ролен үтәгәннәр, диннәрендә гыйбадәт өчен дә файдаланылганнар. Аларны «баба ташы» дип тә атыйлар. Изге саналганнар. Үлем-җитемдә алар янына мәет күмеп калдыру гадәте дә булган. Шулай каберлекләр барлыкка килгән. Тораташлар кабер ташы ролен дә үти башлаганнар.

II

Өйләдән соң безне юлыбыз Ташкич авылына алып китте. Анда да истәлекле урыннар бар. 1985 елда, студент чагымда, минем бу авылда булганым бар иде инде. Бәрәңге алырга җибәргәннәр иде.

Авыл уртасында иске бер бина бар иде. Аның урынында хәзер матур мәчет. Имамнары Зәбир Зарипов исемле агай икән. Аның әтисе Хәлиулла улы Мөхәммәтзариф сукыр булган. «Аны мәчеткә җитәкләп йөреп, үзем дә дингә кереп киттем», – дип сөйләп алды Зәбир хәзрәт.

Электә бу авылда данлыклы Борһан мулла яшәгән. Аның хакында ишеткән-белгәнен 1939 елгы Габделфәрт Мәҗитов болай сөйләде: «Без малай идек. Кыш көне җеназасы артыннан йөгереп бардык. Бер сандык китабы калды. Карт иде. Андый муллалар юк инде хәзер... Бервакыт Салавыч ягыннан туганы килде. Хатын-кыз затыннан. Нигезләренә намазлар укып китте. Борһан мулланың хатыны Салавыч авылыннан булган. Ташкич мәчетен дә шул Салавыч авылы бае салдырган. Хәзрәтнең кайнатасы булган ул».

Хәзер авылда Урта Азия якларыннан кайтучылар да тернәкләнеп килә икән. Тырышлар. Ничек тә аякка басарга, тормышларын ныгытырга телиләр.

Зиратларында борынгы ташларның булуы хакында ишеткәч, анда да барып килдек. Алар XIX гасырга карыйлар икән. Борынгылары да бар булыр. Әмма табылмадылар. «Аларны галим Әнвәр Хәйри язып алды, укып, өйрәнеп йөрде бервакыт. Колхозга эшкә китерелгәннәр иде. Бездә тордылар, – диде, хәтерен яңартып Габделфәрт агай. – Клубта концертлар да куеп йөрделәр әле алар. Булдыра иде...». Озата килгән Габделфәрт агай: «Казаннан, Мәрданов бугай, килгән иде. Ул

ташларны, борынгыларны, анын белән тапкан идек. Кая гына китәләр икән?» – диде.

Шунда исемә төште: Риза Фәхретдиннең, үзенә хат белән: «Ул кабер ташларын уку нәрсә бирә?» – дип мөрәҗәгать итүләренә каршы: «Берни дә бирми. Акча да китерми, сәламәтлеккә дә файдасы юк. Әмма тарихларга бәйле хәтеребезне яңартуга хезмәт итә», – дип җавап бирүе хакында «Шура» журналыннан укыганым бар иде.

Сеҗе авылына кичке якта килеп җиттек. Мәчетләренә кереп намаз укыгач, имамнары Илдар Әһлиуллин белән китапханәләрен карадык. Арада иске басма китаплар да бар булып чыкты. Аларның беришләре – төрле догалыклар, икенчеләре – Коръән һәм тәфсирләре. Әхмәт Ясәвинең «Диване-хикмәт»е, шулай ук «Бакырган китабы»ның өлешләре саклана икән. Авылда, кешеләр кулында гарәп графикасындагы китаплар калмаган. «Андыйларны, укый алмагач, сакламыйбыз инде», – дип җавап бирделәр.

Элек бу авылда удмуртлар яшәгән икән. Зиратлары да булган. Аның чыршыларын кискәннәр. Әйтүләренә караганда, удмуртларда «сеҗе» дип «солы»ны атыйлар икән. «Ташкичләр – арлар иде. Әни аларны «марилар» дия иде», – дип аңлатты Илдар хәзрәт.

Сеҗедән Гөберчәк авылына китеп, Мөхәммәт Мәһдиев музеена кердек. Элек тә монда килгәнем бар иде. Музей ачылуда да катнаштым. Ул вакытта колхозлары исән иде әле, рәисләре Фәрит исемле кеше иде. Шуларны да сөйләшеп алдык. Музейләры булгач, авылларын карап, чиста тоталар икән. Мөхәммәт агада бөек хыял яши иде, ул да тормышка ашты: Гөберчәгенә асфальт юл илтә.

III

28 июнь көнне Кенәр авылы аша Кызылъярга киттек. Яңа һәм Кече Кенәр авыллары инде кушылып беткән. Авыл шулай зурайган. Олы мәктәп, яхшы итеп эшләнгән мәдәният йорты бар. Кызыл, ак кирпечтән эшләнгән матур, төзек биналар. Халыкның тырышлыгы да, уңганлыгы да күренеп тора. Кышын мәктәпләренә дә, китапханәләренә дә очрашуларга чакырачакларын әйткәч, бераз шикләнеп тә куйдым: мин Арча яклары хакында нәрсә сөйли алырмын икән? Китапларымны укыган булсалар инде...

Кызылъяр авылына юл алдык. Кәүсәрия абыстайга барырга куштылар. Анда борынгы китаплар бар икән. Ул хәзер Тәнзилә әбиләрдә яши, ди. Үз өе дә монда гына. Китаплары шунда, диләр. Аннары, Айсылу ханым Галимҗановада «Коръән тәфсире», Габделхәй Тракторчыда әби-бабайдан калган борынгы китаплар күп имеш.

Кызылъярлар безне алтын эзләп йөрүче чегәннәргә тиңләделәрме? Сүзләре һаман да эредән йөрде. Болар, мөгаен, иске байлар авылы булгандыр? Кемгә барып керсәң дә, ихаталары – төзек, нык. Бар да заманча. Машиналы, мал-туарлы болар. Барысы да яхшы югыйсә. Әмма күңелләрендә тынычлык, бәхет тойгысы юк кебек.

Арча ягындагы иң борынгы авылларның берсенә – Түбән Орыга килдек. Монда XVII гасырда, үз заманында акылы, зиһене, галимлеге белән танылып, тарихыбызда эз калдырган шәхесләребездән Бисары улы Янсари хафиз яшәп, 1687 елда вафат булган. Аның бабасы – Килдеш бәк, ә ул – Килеваз («Калавыз» түгел) бәкнең улы икән.

Оры авылы зиратында булып, аның кабер ташын укыганлыгы хакында Риза Фәхретдинов «Асәр» китабында язып уза. Янсари хафизның Ючәнәһам исемле кызы Иванай улы Юныска никахлы икәнлеген дә ачыклый [Фәхретдинов, 1900, б. 29]. Янсариның «хафиз» аталуы мәсьәләсенә тукталып, бу сүзнең мәгънәләрен төрле яклап тикшерә, керәшеннәрдә поп-атакайны да «хафиз» дип атауларына игътибарын юнәлтә, «абыз, абыстай» сүзләренең дә менә шушы «хафиз»га бәйле ясалуын ача.

Иванай улы Юныска килгәндә, ул үз заманында шөһрәтле имам һәм мөдәррис булып җитлегә. Оры авылында зур мәдрәсә тота, балалар укыту белән шөгыльләнә. Аны «Юныс әфәнде», «Юныс ахун» дип атап йөрткәннәр. Бабасы Усай исемле булган.

Юныс хәзрәтнең этисе Иванай Кәче авылында имамлык һәм мөдәррислек иткән. Кодасы Янсари хафиздан соң, бер ел кичеп, 1688 елда вафат була. Казан төбәгендә зур нәсел калдыра.

Иванай мулланың язу эшенә маһирлыгын Р. Фәхретдинов аерым күрсәтә. Ш. Мәрҗани дә бу нәселдә зур галимнәр булганлыгын үз хезмәтләрендә искә ала.

Юныс хәзрәт 1636 елда туган. Р. Фәхретдинов язганча, Казан ханлыгы басып алынганнан соң, Урта Азия якларына китеп, Бохарада белем алып кайткан беренче кеше ул булган [Фәхретдинов, 1901, б. 38]. Зур гыйлем туплап, аң-белемдә маһирлыгы белән танылырга өлгергән. Юлда кәрван белән кайтышында, күчмәләр кулына төшеп, аны казакъларның данлыклы ханы, мәшһүр Чыңгызхан Әбул-Хәйр улы каршына китерәләр. Егетнең төс-кыяфәте, күркәм тәрбиясе, тирән белемнәре һәм саф зиһене хан хәзрәтләренең күңелендә мәрхәмәт хисләрен уята. Ул аны үз янында калдыра. Әмма берникадәр вакыттан соң, егетнең сагыш утында көюен күреп, кәефен аулау нияте белән кызы Мәһәлбикә-солтанга өйләндерә. Кыз, әлбәттә, бик тә чибәр икән. Хан баласы, шуңа да «солтан» титулы белән йөртелә.

Әмма Юнысның күңеле барыбер дә туган якларына ашкына. Ватанпәрварлык хисләренә бирелгән киявен, Мәһәлбикә-солтан белән бергә, казакълар ханы Чыңгызхан асыл ватанына кайтып килергә рөхсәт бирә.

Юныс хәзрәт Оры авылында мәдрәсәдә укыта башлый. Тирән гыйлем иясе булуын истә тотып, аңарга четерекле мәсьәләләрнең берсе – бу мәмләкәттә гошер садакасын җыю тиешлемеюкмы, шуны раслап чишү эше йөкләнелә. Ул аның важиб, ягъни саваплы икәнлеген дәлилләп фәтвә яза. Голәмә тарафыннан кабул ителеп, шул фәтвәсе соңгы гасыргача үз көчендә кала килә, дини басма китаплар арасында

ул хактагы хәбәрләрне очратырга була.

Озакламый Юныс хәзрәтне Оры авылына имам итеп сайлыйлар. Ул мөдәррис, ягъни мәдрәсә профессоры сыйфатында да таныла. Әмма хатыны Мәһәлбикәсолтан вафат була. Аны Оры зиратына җирлиләр.

Юныс ахун икенче хатын алырга ниятли. Аңа Янсари хафизның кызы Ючәнәһамне димлиләр.

Аның белән дә бик тату һәм мәхәббәт тигезлегендә матур яшәгәннәр.

Юныс хәзрәт өч угыл үстергән, исемнәре Нәзер, Сәфәр, Мәкъсүт икән. Болардан шулай ук укымышлы нәселләр таралган.

Фарсы теленә бик оста булып, Юныс хәзрәт күп әсәрләрен шул телдә язган, Иран ягы әдипләренең һәм галимнәренең хезмәтләренә шәрехләр төзегән, үзеннән бай һәм кызыклы гыйльми мирас калдырган. Китапларында үзен «Юныс ахун», «Мулла Юныс», «Юныс бине Иванай Казани» имзалары белән күрсәткән. Танылган әсәрләреннән берсе – «Шәрхе Габдулла». Соңыннан ул Казанда берничә кат басылган, дини йолаларны үтәү, иман, намаз һәм башка фарызларны башкару хакындагы дәлилле, ышанычлы китаплардан санала.

Татар халкы XIX йөз шагыйре Әбелмәних Каргалыйның тормышы һәм иҗаты хакында яхшы хәбәрдар. Аның хакында мәктәп дәреслекләрендә үк бирелгән. Әмма аның бабалары Арча ягыннан икәнлеген искә дә алмыйбыз. Ул данлыклы шагыйрьләр һәм имамнар нәселеннән чыккан.

Әбелмәнихның бабасы Габдессәлам – Урай (Уразмөхәммәт) улы. Урайның этисе – Колмөхәммәт, бабасы – Колчура, нәсел башлары Кылап бәктән. Асыллары белән алар Алат юлындагы Мәңгәр авылы кешеләре.

Габдессәлам башта Ташкичү авылына күченә, анда имаммөдәррис була, зур мәдрәсә тота. Аның дистә еллар буе Кариле имамы Хәсән улы Габдессәлам ахун мәдрәсәсендә камил белем алуы да яхшы мәгълүм. Мәдрәсәдә укыган чагында гарәп теле грамматикасына бәйле хезмәт яза һәм сүзлек төзи. Габдессәламнең чыннан да Әбелмәних Каргалыйның бабасы булуын Р. Фәхретдинов «Асәр» хезмәтендә ачык дәлилләп яза, фикерен раслауда шагыйрьнең үз сүзләреннән дә файдалана, әсәреннән өзек китерә [Фәхретдинов, 1901, б. 42]. Тагын шунысы әһәмиятле, Габдессәламнең бер кызы Стәрлетамак ягындагы Кырмыскалы авылы имамы Вәлид бине Мәкъсүт бине Афак бине Дусмөхәммәттә кияүдә була. 1744 елда Патшабикә Елизавета татар һөнәрчеләренә һәм сәүдәгәрләренә Сакмар елгасы буенда шәһәр төзергә фәрман бирә. Эш башына Казан ягы Саба авылынан курку белмәс Габделхаяли улы Сәгыйть баса, үз тирәсенә гайрәтле, хөр җанлы татарларны туплый. 1750 елда, башкалар белән бергә, Габдессәлам дә шул якларга күченә, Оренбургта имам һәм мөдәррис була. Аның Ташкичү мәдрәсәсендә укыткан чагында ук шәкертләрен китап язарлык, иркен фикерләрлек дәрәҗәдә тәрбияли

алганлыгын Ш. Мәрҗани тарихи хезмәтләрендә дәлилләп, мисаллар белән искә алган.

Габдессәламнең үз мөгаллиме Хәсән улы Габдессәлам исә асылы белән Уфа ягы кешесе була. Ул Кариле авылына килеп, монда исеме тирә-якка танылган остаз-мөдәррис буларак таныла. Күп кенә шәкертләр тәрбияли. Әмма ир балалары булмау сәбәпле, тәрбиясез калгач, Минзәлә елгасы буендагы Шыгай авылына китә. Монда кызы кияүдә була. Шулай итеп, Шыгай авылында кияүләре Сөләйман улы Мөхәммәтшәрифтә яши, атаклы Шыгай мәдрәсәсендә укыта. Аннары Мәлем авылындагы кияүләре Зәйнетдин йортына күченә. Кабере дә шул Мәлем авылында.

Гали Чокрыйның әнисе Гөлбаһар нәкъ менә шушы нәселдән.

Хәсән улы Габессәлам исә данлыклы Котлыгыш әс-Семети улы Мортаза әфәндедә белем алган. Ә ул, үз чиратында, Дагыстан якларында укып кайткан, хаҗи да булган. Р. Фәхретдин хәбәренә күрә, 1723 елда Мортаза хафиз намаз укуга бәйләнешле әһәмиятле гарәпчә китап язган [Фәхретдинов, 1900, б. 31].

Хәсән улы Габдессәлам Курса авылында да белем алган. Ул монда Таип улы Рафыйк мөдәррис мәдрәсәсендә укыган. Шунысы игътибарга лаек, имам Рафыйк үзе дә заманында Мортаза хафизның шәкерте булган.

Габдессәламнең Рафыйк хәзрәткә күчүе мөдәррисенең вафаты сәбәбенә бәйле аңлатыла ала. Ул заманнарда гыйлем ияләре күп булмаган. Рафыйк Курсави бик күп бәхәсләр уяткан мәсьәләләрдән берсе – кыска төннәрдә ястү намазын уку тиешлеге хакында рисалә язган шәхес тә әле.

Бу шәхесләр фикер иясе Габденнасыйр Курсави кебек алдынгы карашлы галимнең җитлегеп мәйданга чыгуында зур роль уйнаганнар билгеле. Габденнасыйр кебек даһиларга бөек халыклар һәйкәлләр куялар, бездә дә андый гамәлләр булырга тиеш иде югыйсә.

Габденнасыйр Курсавиның этисе Ибраһим исемле, бабасы – Ярмөхәммәт. Ул – Курса авылыннан, Иштирәк нәселенең дәвамчысы. Габденнасыйрның улы – Насыйр. Шунлыктан ләкабе, шәригать кысаларында, Әбуннасыйр була («Насыйрның этисе» дигән сүз). Берәүләр аны «Әбуннасыйр Курсави» диләр, икенчеләр «Габденнасыйр Курсави» исеме белән белдерәләр. Бу исә «ике төрле кеше хакында сүз бара булса кирәк» дип уйларга җирлек тудыра. Алар икесе дә бер үк зат, ягъни Насыйрның атасы – Габденнасыйр Курсави.

Габденнасыйр Курсавиның этисе Ибраһим 1790 елда вафат булган. Әнисе – Әмин кызы Миһербан, Максабаш авылы Мансур бай нәселеннән.

Габденнасыйрның апасы Мәрхүбә исемле булган. Мәчкәрә авылыннан Габдессәлам улы Габдуллага кияүгә чыккан, Габденнасыйрны гына түгел, Гобәйдулла, Муса, Мөхәммәтҗан, Хәсәнбану исемле балаларын да үстергән. Р. Фәхретдинов аны «Мәшһүр хатыннар» исемлегенә керткән. Мәрхүбә абыстай 1827 елда вафат булган.

Габденнасыйр Курсави 1776 елда дөньяга килгән. 37 яшендә, 1812 елда, рамазан аенда вафат булган. «Буның вафат улмасы илә Казан вә Болгар исламнары, бәлки гомумән ислам галәме олуг бер галимнәрене заигъ итмешләрдер», – дип яза бу хакта Риза Фәхретдинов [Фәхретдинов, 1903, б. 95].

Бала чагында Габденнасыйр, белем алу максатын күздә тотып, туган авылы Курсадан Малмыж ягындагы Мәчкәрә авылы мәдрәсәсенә китә. Аннары аны гарәп-фарсы телләрен яхшылап үзләштерү теләге Бохарага кадәр китерә. Ул монда батыйни вә заһири гыйлемнәрне, ягъни интуиция һәм тәҗрибә юллары белән хакыйкатьне табу ысулларын, замананың бөек галимнәреннән һәм шәехләреннән өйрәнә, гарәп-фарсы телләрендә камил дәрәҗәдә укырлык, язарлык, иркен аралашырлык дәрәҗәләргә ирешүе белән бергә, мәгънәләргә, ягъни белемнәрнең эчтәлегенә, чын асылына төшенүгә дә ирешә. Бохарада уздырыла торган галим-голәмәнең бәхәс мәҗлесләренә йөри. Монда үзенең яхшы зиһен һәм гыйлемнәр иясе булуын, кыен мәсьәләләрне чишә алырлык көчле акылы белән даны тарала. Хәтта ул килмичә бәхәс мәҗлесләре башланмау очраклары ешая.

Әмма уйланмаган хәлләр килеп чыга. Габденнасыйр Курсави, фикер өлгерлеге һәм хакыйкатьне ачык күрә белүе аркасында җитәкче даирәләрнең «ачуын кузгатуы» сәбәпле, алга таба Бохарада кала алмый, үз ватанына кайта. Аңа бай җизнәсе Габделсәлам улы Габдулла олы мәдрәсә салдырып бирә. Габденнасыйр Курсави аны алдынгы карашлы һәм югары белемнәр учагына әверелдерә.

1807 елда ул Бохарага икенче тапкыр китә, анда бераз торгач, кирәкле китапларын кабат укып, күчереп язып, тикшереп-өйрәнеп чыккач, Хива шәһәренә юл ала, монда да китапханәләрдә була. Аннары Әстерханга килә, шуннан соң, Идел буйлап сәяхәт итә-итә, асыл ватанына кайта.

Ә 1812 елда Габденнасыйр Курсави хаж сәфәренә кузгала. Алар Казанда җыелышып, аннан Истанбулга киләләр. Әмма Габденнасыйр юлда авырый башлый. Истанбулга барып ирешкәндә авыруы тагын да көчәя һәм ул шунда вафат була. Искедәр бистәсе Солтаннар зиратында җирләнә.

Габденнасыйр Курсави күп төрле остазлардан белем ала. Әмма алар арасында ике галим аның фикерләре оешуда, күзләре ачылуда төп урынны алып торалар. Аларның беренчесе – Мәчкәрәдән имам-мөдәррис Мөхәммәтрәхим булган. Ә Мөхәммәтрәхим үзе Ашыт авылы Йосыф мулланың улы икән. Икенчесе – Бохара шәехе Ниязколый Төрекмәни Шаһнияз улы. Бу остазы да гаҗәеп зур акыл иясе, фикер чыганагы һәм итагатьле кеше булган.

Габденнасыйр Курсавиның язган китап һәм рисаләләре арасында тугызы бүгенге көндә дә әһәмиятле саналалар. Аларның кайберләре: «Әл-Иршад», «Китабул-ләваих», «Шәрхүл-гакаидүл нисфиятүл кадим», «Шәрхүл-

гакаидүл нисфиятүл җәдит», «Рисаләтүл-исбатул-саффат», «Китабул-нәсаих», «Шәрхулмохтасарул-Манар», «Хашиятүлгакаидүл-җәдит», «Төрки телендә Һәфтияк шәриф тәфсире». Шушы хезмәтләре белән ул ислам дөньясын яңа фикерләр белән баету гына түгел, бәлки яшәеш барышын һәм илаһият кануннарын суфичылыктан аралап алып аңлата башлаган бөек галим дә санала.

Габденнасыйр Курсави озын буйлы, киң маңгайлы, куәтле кеше булган. Башкаларның сорауларына ачык итеп, аңлатып җавап бирүчән, ә сөйләшүе – туры сүзле, төгәл, матур. Үткенлеге белән сокландырган да, куркуга да салган. Табигатеннән үк укымышлы кеше икәнлеге күренеп торган. Гәүдәгә – арык, холыкта – сабыр, акылы – камил, фикерләре – дөрес, нәсыйхәтләре – яңача, кабатланмас сурәттә үтемле һәм дәлилле, зиһене – ачык һәм тугры, әйткәннәрендә матур гыйбрәтләр һәм чагыштыру-ишарәләр күп булып, сүзләре үзе белән сөйләшүчеләрнең күңеленә рәхәтлек биргән. Мәгъруp һәм вәкарьле булган. Һәммә бу сыйфатлары аңа карата башкаларда хөрмәт, олылау хисе уяткан, әмма көнчелекле кешеләрдә дошманлык хисе дә тудырган. Шунлыктан халык арасында алары да, болары да күп булган. Әмма Әбүннасыйр Курсави икенчеләренә бик игътибар итеп тормаган. Олы адәмнәргә күрсәтелгән ихтирамны аңа кече яшеннән татырга туры килгән.

Мәчкәрә мәдрәсәсендә укыган чагында Габденнасыйрның этисе үлә. Мөгаллиме Мөхәммәдрәхим хәзрәт аның акыллы, зиһенле һәм аңлы шәкерт булуына соклануын яшерми, укуын дәвам иттерүен сорый. Габденнасыйр Курсавиның киләчәктә зур галим буласын башкаларга да яшермичә әйтә килә. Аның үсеп, зур галим мәртәбәсен алуын халык та өмет итә башлый. Бу хакта Ш. Мәрҗани үз хезмәтләрендә сокланып искә ала, хәтта халкыбыз арасында чын галимнәрне аера һәм күрә белүчеләрнең барлыгына куана.

Габденнасыйрга иптәшләре дә, тормышы бермә-бер авырлашса да, укуын ташламаска киңәш итәләр. Һәм ул Бохарага китеп бара, анда да ачлы-туклы гомер кичерә. Әмма гыйлемгә омтылышы һич кенә дә сүрелми. Мәчкәрә мәдрәсәсе шәкерте чагында ук аның фикерле булуы, укыган китапларын тәмам истә калдырулары, дәресләрдә һәм аерым оештырылган гыйльми бәхәсләрдә аларны дәлил итеп сөйләп бирүләре мәртәбәсе үсүгә хезмәт итә, инде яңа сыйфатлары да ачыла. Бохара галимнәрен ул гаҗизлектә калдыра башлый. Иман һәм шәригать мәсьәләләрендә аның ачык һәм үтемле сөйләүләре, замана үзгәрешләрен һәм тормыш таләпләрен һәркайсын янәшә куеп аңлатулары үзләрен белем иясе хисабында йөртүче адәмнәрнең ачуларын китерә һәм алар аның өстеннән Бохара әмиренә хат язалар. Бу вакытта Габденнасыйр Курсави Ниязколый Төрекмәнидә дүрт ел белем алган, аның алдынгы шәкерте хисабында саналган. Тагын шунысы да бар, Казан

ягыннан килгән шәкертләр андый бәхәс мәҗлесләренә йөрмәү ягын караганнар. Ул утырышлардагы шау-шулар, бер-берсен инкарь итүләр, кәфергә чыгарулар бик еш булганлыктан, аның ише урыннардан читтәрәк йөрүне хәерлегә исәпләгәннәр. Әмма Габденнасыйр Курсави бу ише бәхәс мәйданнарына тәҗрибә урыны буларак та караган, аларны хакыйкатьне эзләү өчен уңай урын итеп тә белгән. Әфләтунча фикер йөртүе, акылы, зиһене аны игътикад мәсьәләсендә яңа мәгънәләр табуга китергән.

Бохара әмире махсус мәҗлес җыйдырып, илендәге галимнәрне чакырып, Габденнасыйр Курсавины кәферлектә гаепләгәндә дә бары тик тиран рәвешендә эш иткән, хәтта шәригать таләпләрен дә исәпкә алмаган. Аның ясаган хөкемен һәм дини, һәм тарихи нигездә тикшереп, XX гасыр башында Р. Фәхретдинов бу эшнең ни әмирлек, ни казыйлык ягыннан гадел һәм дөрес башкарылмаганлыгын ачыклап аңлатып язарга мәҗбүр була [Фәхретдинов, 1903, б. 119–121].

Ш. Мәрҗани дә үз чорында, Бохарада укыган вакытларында, «Габденнасыйр эше» белән махсус кызыксына һәм ул вакыйгада катнашкан имам-мөдәррисләрнең соңыннан үкенүләрен, Курсави замандашлары арасында аны аңларлык галимнәрнең булмавын искәртүләрен, бу хакта яшерми әйтүләрен хезмәтләрендә хәбәр итә.

Бохарадан Әстерханга килгәч, Габденнасыйр хәтта шыга мәзһәбе галимнәре мәҗлесенә чакырыла. Ул аларны шаккатыра. Һәммә яктан бу мәзһәпнең үзенчәлекләрен ачык аңлатып бирә. Аның белән ярышырлык, фикерләрен инкарь итәрлек галимнәрнең араларында табылмавы аларны борчуга сала.

Габденнасыйр Курсави диндә сәләфләр (сәләфият) юлын өстен куя, әмма аңа да тәмам мөкиббән түгел, тәнкыйди карашы булган шәхес. Моңа Ш. Мәрҗани дә игътибар иткән, ул аны хәтта «биш йөз елга бер туа торган галим» дип атаган. Курсавиның китапларын укыган кешеләр, аның фикерләрен һичбер бәхәссез кабул итеп, тормыш тәртипләрен үзгәрткәннәр, хаталарын төзәткәннәр. Шундыйлардан мисал итеп «Асәр»дә Р. Фәхретдинов Табул ягыннан Хуҗамбирде исемле галимнең вакыйгасын искә ала [Фәхретдинов, 1903, б. 123]. Ул, Г. Курсавиның «Әл-Иршад»ын укыгач, мәсләген үзгәртә, игътикадын яңарта.

Г. Курсави Хивага килгәч, шәһәр башлыгы аңа атап аерым мәҗлес оештырган. Гыйлеменә һәм данына соклануын яшермичә, ике йөз алтын акча биреп, аның иңенә халат салган һәм үзләрендә имам-мөдәррис булып калуын үтенгән. Бу кадәрле олы хөрмәтләр күңелләрне яуларлык дәрәҗәдә күрсәтелсә дә, Габденнасыйр ата йортына кайтырга тиешлеген дөрес мәгънәдә белдерә алган.

Аның Хивага килүен мөгаллиме Ниязколый Төрекмәнигә хөрмәте буларак та аңларга кирәк. Кайда гына бармасын, Г. Курсавиның үз шәхесенә карата көчле соклану хисләрен уятыр

дәрәҗәдә бөеклеген танымый мөмкин түгел.

Китапларындагы аңлатмалар, фикер сөреше гаҗәеп дәрәҗәдә җитди рәвештә булып, икеләнерлек урын калдырмыйлар, фәнни мәгънәләр кысасында язылганнар. Шул сәбәпле кешеләргә тәэсирләре дә көчле. Дини-рухани эчтәлектә, Аллаһыга тугрылык, Мөхәммәд пәйгамбәргә олы хөрмәт, ислам динен саф, бернинди катнашсыз һәм, иң әһәмиятлесе, һәртөрле суфичыл, шагыйранә фикерләрне, әүлияви күрсәтмәләрне читкә кую, аларның асылсыз икәнлекләрен аңлау-аңлату нигезендә язу, яшәү – болар үзләре генә дә ул заман өчен күрелмәгән хәл була. Габденнасыйр Курсави ислам динен хорафи карашлардан арындыру юлын ача, рухани дөньяның таләпләрен һәм чикләрен дөрес билгели. Бу исә халыкны урта гасырчылыктан котылдыру, яңа заманга алып керү була. Аның алдынгы карашларын татар дөньясының үз вакытында ук кабул итүе халкыбызга карата хөрмәт хисен тагын да ныгыта.

## IV

XVIII гасырда рухани фәлсәфә өлкәсендә Габденнасыйр Курсави мәртәбәсендә башка бер генә галим дә җитешмәде. Әмма аның шәхесе һәм өстенлеге бүтәннәрне күләгәдә калдырырга тиеш түгел.

Халкыбызда булган андый галимнәр, булган! Хәтерләп кенә бетермибез. Шундыйлардан тагын берсе – «Таузыйхи» кушаматын йөрткәне бар.

Аның даны «Тәүзыйх китабы»на мөкиббән булуыннан, аңа аңлатмалар төзүеннән килә. Ул әле башка төрле шәрех китаплары язу белән дә шөгыльләнгән. Исеме – Нигъмәтулла имам, Наласа авылында яшәгән. Әтисе – Рәхмәтулла, бабасы – Иманкол исемле булган. Аларның нәселе Рәхманколдан килә. Бу Нигъмәтулла ахун 1815 елда хаҗ сәфәренә китеп, Искәндәрия шәһәрендә вафат булган, Бусыйри төрбәсе янында җирләнгән...

Түбән Оры авылында йөрибез. Күпләр Казанга күченгән. Ата-ана йортын музей-ихатага әверелдергәннәре дә бар.

Данлыклы авыл булган ул. Монда элекке байлар завод-фабрикалар тотканнар. Агым суны буып, аның көченнән машиналар эшләткәннәр. Кайсыларының субайлары әле дә сакланган. Түбән Оры авылы иңкүлеккә, тирән булып сузылган чокыр урынга урнашкан.

Әмма хәзер кайбер урамнары түбәннән югарыга таба дәвам иткәннәр. Аңлашыла! Моның сәбәбе хакында Оры авылында искә алуны хәерсез бер гамәл кебегрәк кабул итсәләр дә, тирә-күрше авылларында аны вакыйга итеп сөйлиләр. Чөнки даны китапларга кергән. Тарихларда да «Оры туфаны» буларак искәртелә [Фәхретдинов, 1903, б. 144]. Ул инде, телдән-телләргә йөрийөри, гасырдан-гасырга күчеп килә-килә, безнең дәвердә дә сөйләнелә. Миңа аны Кызылъярда кат-кат сөйләделәр.

Бик эссе җәйге вакыт икән. Оры авылына бер ак бабай килеп, йорттан-йортка йөреп,

эчәргә су сораган. Әмма аңа бирмәгәннәр. Бары бер яшь кызның гына мәрхәмәте килеп, аңа су чыгарган.

Бәлки вакыйгалар шуның белән бетәр дә иде, әмма бу кызның әнкәсеме (әллә әткәсеме?) бик усал кеше икән. «Аңа нигә су бирдең?» – дип, кызын тәмам орышкан, тәмам орышкан... Бу хәлгә түзә алмыйча ак бабай, ишетеп торган җиреннән: «Авылыгызны су йотсын», – дип, каргап дога укыган.

Ул китүгә, озак үтми, күктә кара болыт чыга, бик әшәке җил күтәрелә һәм бик көчле яңгыр ява башлый. Һәммә тарафтан сулар күтәрелеп, Түбән Оры авылын басып, халкы, малытуары белән бергә, еракка ук агызып алып киткән. Шул туфан суы алып барып тукталган урында бүгенге көндә дә шомлы агачлык һәм зират икән. Аны «Орылар яткан җир» дип аңлаталар.

Оры туфанында бердәнбер кеше – ак бабайга су биргән кыз исән калган.

Берәүләр әйтәләр: «Туфанның килгәнен ул белми калган», – диләр. Икенчеләр: «Күреп торган, авыл халкын кызганып елаган», – диләр.

Түбән Орыда да бу хәбәрне матурлап сөйләделәр. Инде хәзер мәгънәле бер риваять төсен алса да, мин аның асылы белән кызыксынып карадым. Белүче булмады. Китаплардан эзли торгач, күп нәрсәләргә ачыклык керде. Болар инде чын тарихның үзе иде!

Бу туфан вакыйгасы чыннан да булып узган. Төгәл датасы да билгеле.

Ул вакыйга 1817 елга карый. Монысы тагын да гыйбрәтлерәк!

Түбән Орыда ул вакытта имам-мөдәррисләрдән шөһрәтле Хәбибулла ахун яшәгән. Аның «Хәбибулла ишан» дигән даны еракларга таралган. Нурлы йөзен күрергә, аяк тузанын үбәргә әллә кайсы мишәр якларыннан да киләләр икән.

Хәбибулла ишанның нәселе зур булып, аның бабалары инде язылып узылган Янсари хафиздан килә икән. Килдеш бәк торыннарыннан болар. Кайчандыр мари яклары болар кулында булган.

Җәйләрен тарантасларына атларның бары тик яхшыларын гына җиктереп, кышларын затлы бизәкле чаналарда җилдереп, туннарның да асылларын гына киенеп йөргән Хәбибулла ишан. Әтисе – Хәсән, бабасы – Габделкәрим. Хатыны да ни җитте генә түгел, Хуҗа Сәет нәселеннән килгән, Ханмирза, Котлык кебек бабалары белән дан тоткан, Оры авылының мәшһүр байларыннан Туктамыш улы Рәхмәтулланың кызы Зөбәйдә абыстай икән. Хәбибулла ахун Оры авылында таш мәчетнең имамы булган.

Әмма көннәрнең берендә авыл байлары, Хәбибулла ишанга карата күңелләре суынып, туганы Фәтхулла хәзрәтне ахун итеп куйганнар. Шулай гына бераз тынычланганнар.

Әмма Хәбибулла ишанның мәртәбәсен санлаучылар да табылган. Тиз арада агач мәчет җиткергәннәр һәм бер мәхәллә булып аерылып чыкканнар.

Боларның икесе дә – Хәбибулла да, Фәтхулла да – ни җитте

генә түгел, горур вә тәкәббер икәннәр. Мәчетләреннән азан һәм Коръән уку авазлары үзара ярышып ишетелә башлаган, берсе уразага кергәндә, икенчесе бер көнгә соңарта, гаетләрне дә берсе икенчесеннән арттырып уздыра торган булып киткәннәр. Ул ярышулары йорт-җиһаз, арба-чана, ат-дирбия, кием-салым, юл йөреш, кыяфәт күрсәтеш, беләмлек мәртәбәләренә кадәр үстерелеп, шайтаный бер хәрәкәткә һәм бәлагә әверелә барган. Ә моның сәбәбе, эшнең башы – мөфти хәзрәтләренең кул уйнатуыннан һәм көнчелегеннән килгән. Аңа башкалар да катнашып киткәннәр.

Тагын шунысы да бар, Оры авылының төп халкы мишәр татарларыннан булып, алар бу якларга шактый таза хәлләрендә килеп урнашканнар һәм, гадәтләре буенча сәүдә эшләрен киң җәелдереп, татар галәмен үз мәнфәгатьләренә бик оста хезмәт иттерә башлаганнар. Икенчедән, Оры авылы халкы үз данын һәм мәртәбәсен даими күз уңында тоткан. Яхшы зиһенле, атаклы имамнар нәселеннән булган Хәбибулланы шәкерт вакытыннан дин башлыгы итеп әзерләүгә зур көчләр куйганнар.

Татар мәдрәсләрендә аңбелем алгач, аны Бохарага җибәрәләр, анда да иң шанлы мөдәррисләрдән белем ала Хәбибулла. Хәер, ул үзе дә акыллы шәкертләрдән була. Бохарадан Кабулга китеп, гарәп һәм фарсы телләрен камил үзләштереп, белемнәрен тирәнәйтеп һәм киңәйтеп өлгерә. Хәтта ишанлык серләренә дә төшенә. Һәм менә ул Орыга кайткач, имамлыкта аның белән ярышырлык кеше табылмый.

Тиздән Хәбибулла ишан хакында олы хәбәрләр тарала. Мәдрәсәсе даннарга күмелә. Аңа халык ихлас күңел белән бирелә. Бигрәк тә мишәрләр, мәртәбә, дан, шөһрәт яратучылар буларак, аның атта узып киткәнендә: «Ишан хәзрәтләребез, бәракәт ит!» – дип, тәгәрмәч эзен ятып үбәләр, укыган догасыннан могҗизалар табалар, чана юлларын кочалар икән.

Хәбибулла хәзрәтнең даны зурлыгын сөйләүче фактлардан тагын да берсе шул, бусы – муллаларга бәйлесе...

Шәкерткә, әлбәттә, төрле сораулар бирелә. Шулардан берсе: «Оры шәрифкә бардыңмы? Ханәкәгә кердеңме? Тәнбиһ укыдыңмы?» – диләр. Әгәр дә Оры ишаны Хәбибулланың алдында булган, аның фатихасын алган шәкерт икән – булды гына, килешүнамә җыела, моны имам итеп сайлыйлар, Уфага, мөфтидән шәһадәтнамә алырга җибәрәләр. Әгәр: «Юк!» – дисә, нинди генә укымышлы, олы белемнәр иясе саналмасын, аңардан, ике дә уйламый, баш тарталар.

Әмма бервакыт Хәбибулла хәзрәтнең дан-шөһрәтләре бәхетенә каршылык итә башлый. Вакыйга шулай килеп чыга ки, мөфти Мөхәмммәтҗан хәзрәтләренең хаталы эшләреннән берсе хакындагы эш, тикшерү өчен, мәхкәмәгә тапшырыла. Менә шунда «мөфти Мөхәмммәтҗан хәзрәт урынына Оры имамы Хәбибулланы куялар икән» дигән сүз тарала. Бу хәбәр Мөхәмммәтҗан мөфтигә дә килеп ирешә.

Әлбәттә, бу яңалык аның ачуын кузгата.

Ул Оры авылының мәчетенә ут төртеп яндырырга әмер бирә. Ярый әле бу эшкә һичкем алынмый, халык тәмам курка кала, күңелләрен аптырау баса.

Хәбибулла хәзрәткә килгәндә, ул боларны белми дә кала. Үз тәртибендә яшәвен дәвам итә. Әмма Мөхәммәтҗан мөфти, мәхкәмә эшеннән имин узып өлгерми, Хәбибулла ишаннан үч алу уена төшә. Казан байлары аша Хәбибулланың мөфтилеккә дәгъва кылмаган булуын, бары тик каршылыклы халыктан чыккан сүз аркасында гына бу хәбәрнең таралганлыгын белсә дә, Хәбибулла ахунга каршы «ут ягу» эшен башлап җибәрергә кирәк таба.

Байлар арасында махсус рәвештә коткылар таратылып, имамга каршы барысын да котырта башлыйлар. Алар баштарак бирешмиләр. Әмма нинди иманлы кешеләрнең дә күңеленә, әүвәле аптырау, аннары коткы төшеп, Хәбибулладан көнләшү, аны начарга чыгару уе урнаша бара.

Хәбибулла хәзрәткә каршы алып барылган коткыга бирелеп, байлар үзара тарткалаша башлыйлар. Тәмам үпкәләшеп, ахырда ике мәхәлләгә аерылып, Хәбибулла ишан үзенә агач мәчет төзетергә, шунда имамлык итүгә күчәргә мәҗбүр була, туганы Фәтхулла таш мәчеткә мөфти фәрманы илә ахун итеп куела.

Хәбибулла хәзрәт Оры авылында 1762 елда туган, 1817 елда Орыда вафат булган. Шул елны, ишанның вафатыннан соң озак та үтми, Оры авылын туфан суы агызып алып киткән. Мөфти Мөхәммәтҗан (Габдраманов Мөхәммәтҗан Хөсәен улы, беренче мөфти, нindидер сәбәп белән бабасы исеменә бәйле рәвештә, ягъни фамилиясенә карап, «Габдрахман мөфти» дип йөртелгән) исә, Хәбибулла вафатыннан соң җиде ел узгач, 1824 елның 17 июнендә 68 яшендә мәңгелек йортка күчкән. Мөфтилеген һичкемгә бирми һәм тапшырмый калдырган. Аның Әхмәт исемле улы, башка балалары кебек үк, морза титулында, зур биләмәле җирләр хуҗасы була.

Мөхәммәтҗан мөфтинең бәхет кояшы бик тә югарыдан яктыртып, аны һәрьяктан нурландырып торган. Ул патшалар кебек яшәгән, яхшы арбаларда дүртәр ат җиктереп узып китә торган булган. Аның мәрхәмәтенә ирешү бөек саналган, каһәренә юлыкканнар, һичшиксез, һәлакәт тапкан, бәла авырлыгын татыган. Нинди данлыклы Хәбибулла ишанны да аның сәясәт тегермәне йоткан, ваклап ташлаган.

Фәтхулла хәзрәт тә төшеп калганнардан түгел, ул, ни гаҗәп, матур телле, фикерләрен ачык белдерүче кешеләрдән була. Аның хәтта берничә әсәр һәм китап язуы билгеле. Шулардан берсе – «Рисаләте фи иттисафул-вәҗиб бил-вәхдәтүлгаддийәт», ике сәхифәдән гыйбарәт, гарәп телендә, ачык аңлаешлы һәм төзек итеп язылган. Икенче хезмәте – «Рисаләте мөһиммәт», 1872 елдан бирле Казанда еш басылган 15 битле китап. Анда ураза мәсьәләләре тикшерелгән. Өченче китабы – «Мәҗмуг». Бу китап 25 бүлектән

һәм 798 сәхифәдән гыйбарәт, күләмле хезмәтләрнең берсе. Ул төрле китапларның асыл нөсхәләреннән алынган җыелма хәбәрләрдән, хашия-аңлатмаларны киңәйтеп язудан гыйбарәт булып, анда хәтта Себер һәм Урта Азия ханнары Шәйбаниләр нәселеннән имам Хәсән улы Мөхәммәтнең «Җәмигуль-гараиб» китабыннан алынган материаллар да бар, алар барысы да күрсәтелеп барылганнар һәм урыны-урыны белән бәхәс тә ителгәннәр. Бу хезмәтендә ислам дине кануннары, Коръән һәм тәфсирләр, әхлак, медицина һәм башка мәсьәләләр белән бәйле хәбәрләр тупланган. Әмма алар берсе дә аерым бер ачык максатлы фикер нигезендә бәян ителмичә, җыелма хәбәрләр бирү юлы белән төзелгәннәр.

Фәтхула хәзрәтнең болардан тыш та шактый китаплар язуы билгеле. Алар һәммәсе дә шушы «Мәҗмуг» рәвешендә төзелеп, ислам динендә булган татар халкының гореф-гадәтләре яхшылыгын аңлатып бирүләрдән, кайсы гамәлләрне ничек итеп кылганда дөрес һәм күркәм икәнлеген ачыклап сөйләүләрдән гыйбарәт. Бер генә фикере дә мөселман кешенең иманына, әхлагына, табигатенә зыян итәрлек түгел.

1819 елда Фәтхулла хәзрәтнең Диния назарәтенә язган хатыннан аңлашылганча, Оры авылының таш мәчете халык акчасына салынган, кырык ел буена монда җомга һәм гает намазлары укылган. Хатта Хәбибулла ишанның агач мәчет төзетеп, шунда җәмәгать белән азансыз гына намазлар укуы, инде аның вафат булуын да хәбәр итә.

Һәм ул хатта хәзрәтнең үз янәшәсендә һичкемне таныргы теләмәвен, авылда таш мәчетне генә калдырырга кирәклеген дәгъвалавы да сизелә. Агач мәчеттә намазларның азансыз укылуын шәригатьне бозу буларак аңлата. Бу хакта халыкка хәбәр итүне үтенә. Монысы инде Хәбибулла ишанның рухын юк итү теләгеннән булса кирәк.

Картайган көнендә Фәтхулла хәзрәт үз мәдрәсәсенә мөгаллим итеп Казан шәһәренең алтынчы мәчете каршындагы мәдрәсәдә хәлфә хезмәтендә торган Габделкадыйр имам улы Сибгатулланы чакырта. Ул Оры авылына күченеп килә. Үзен намуслы, гадел, тәртипле һәм галим зат буларак таныта. Фәтхулла хәзрәтнең вафатыннан соң, рәсми рәвештә имам һәм мөдәррис дәрәҗәләрен ала. 1873 елда 75 яшендә Орыда вафат була. Сәламәт вакытында ук үз урынына улы Вәлиулланы имам итә. Тирә-күрше авылларда болар нәселеннән муллалар тарала. Мәдрәсәсе яхшы, укымышлы, тәрбияле муллалар әзерләгән.

Оры авылын агызып киткән туфанның 1817 елда, Хәбибулла ишан вафатыннан соң булуын искә алсак, аның авыл халкын, барлык мал-мөлкәтне агызып алып китүенә дә игътибар итсәк – монда илаһи бер хикмәт булуына шик калмый.

## V

Бүгенге көндә Түбән Оры авылы байларча яшәп ята. Күп кенә йортларда кыек түбәләрен алыштырганнар. Заманча итеп яңа йортлар да эшләткәннәр. Укымышлы кешеләре дә күп.

Намазларын укып, уразаларын тотып яшиләр. Заманча дини китаплардан тыш, иске басмалар да монда шактый очрады. Кулъязмалар да килеп чыкты. Иманда ныклы халык яши икән, дигән сөенеч белән киттек алардан. Изге догалары үзләренә дә бәрәкәт белән әйләнеп кайтсын!

Ә безнең юлыбыз дәвам итте. Алдагы көндә Байкал авылында булырга тиешбез икән. Бу исем кайдан килә икән? Әллә ерак Себердәге Байкал күле белән бәйләнеше дә бармы?

Дөресен тәмам ачыклар өчен шактый эзләнергә, архивларны, борынгы китапларны актарырга, халык арасындагы киң күңелле иҗатчылар сүзен тыңларга кирәк. Әмма фән – башка, ул төгәллекне, чын хакыйкый белемнәрне генә кабул итә.

Арча ягыннан укымышлылар шактый булган. Шулардан берсе – XVIII–XIX гасырларда Казанбаш авылында Җәгъфәр улы Бикчәнтәй хәзрәт яшәгән, аның бабасы Мөслим исемле булган. Бу Бикчәнтәй хәзрәт, Уфа шәһәренә имамлыкка имтихан тотарга килгәч, бер «Әхтәри кәбир» (гарәп сүзләренең төрки телдә аңлатмалы сүзлеге) китабы сатып алган. Аның тышлыгына бу хакта хәбәрен язып калдырган. Вафаты – 1817 елда, Казанбашта булган.

Менә тагын да – Сәйфулла улы Мөхәммәтәмин, Сарман ягы Шыгай авылы муллалары нәселеннән. Бабасы Динмөхәммәт улы Габделхәмит булган. Наласа авылында имам-мөдәррис булып, 1842 елда хаҗ сәфәренә чыгып китә. Каһирә шәһәренә җитеп, монда ил башлыгы Ибраһим патша хозурына кабул ителә. Фарсы теле мөгаллиме Габдеррәшит улы Шәмсетдиннең вафат булуы сәбәпле, Ибраһим патша тарафынан Мөхәммәтәмин аның урынына Әл-Әзһар университетына мөдәррис-профессор итеп билгеләнә. Ул, хаҗын тәмамлый алмыйча, гомеренең соңынача үз эшен зур җаваплылык белән башкара.

Мөхәммәтәмин 1849 елда мәңгелек йортка күчә. Гарәп мәмләкәтләрендә аны олы галим дәрәҗәсендә таный торган булганнар. Гүре Каһирә шәһәрендә. Габденнасыйр Курсави идеяләрен гарәп дөньясына таратучы һәм танытучы, ул ачыклаган сәләфият мәзһәбенә тулысынча бирелүче, мөселманнар арасында җәелдерүче, Идел – Урал ислам әһеленә карата дөнья халыкларында хөрмәт хисләрен тәрбияләүдә аның зур эшләр башкарган кешеләрнең берсе булуына шик юк.

Мөхәммәтәмин хәзрәт Бохарада, шәкерт булган чагында ук, Габденнасыйр Курсави белән таныша, аннан дәресләр ала һәм ул өйрәткән игътикадиман юлын дөрес аңлап кабул итә. Дөрес фикерләве, хәтере яхшы булу белән аерылып тора. Китаплар да яза. Аның әсәрләрен заманында Ш. Мәрҗани дә укыган. Ул аларны мактап телгә ала. Мөхәммәтәмин хәзрәт Аллаһы Тәгалә хакында Коръәндәге һәм хәдисләрдәге хәбәрләрдән артыгын сөйләүне мөселман кеше өчен бозыклыкка һәм ислам дине каршында җинаятькә санаган. Бу хакта Оры, Кенәр, Мәңгәр

имамнары белән йөзгә-йөз килеп бәхәсләшә, Габденнасыйр Курсави фикерләрен өстенгә чыгара, хатлар алышып фикерләшә торган булган. Гадәтләре, сыйфатлары, әйткән сүзләре игелек белән тулып, язган китаплары да шул юнәлештә һәм рәвештә булганнар. Алар, заманында, күп галимнәрне тәрбияләүдә лаеклы урын тотканнар. Аның язган китапларыннан берсе – «Мәгадәнел-макасид», эчтәлеге һәм фикер сөреше белән төгәл аңлаешлы әсәрләрдән, авторы «Кавәметдин әл-Болгари» дип куелган. Бу – аның галим буларак үзенә алган имзасы.

«Мәгадәнел-мәкасид» китабы Габденнасыйр Курсави хезмәтләре тәэсирендә язылган. Риза Фәхретдинов «Кавәметдин әл-Болгари» имзасы кемнеке булуын төгәл, фәнни нигездә ачыклауга ирешкән [Фәхретдинов, 1904, б. 293]. Ул кичке намаз хакында да бер китап язып, анда үзен, автор буларак, «мөалифе – Мөхәммәтәмин бине Сәйфулла әл-Болгари әс-Сабави» дип күрсәткән.

Арча ягының борынгы галимнәреннән тагын да берсе – Ашыт авылында имам-мөдәррис Сәйфелмөлек улы Габденнасыйр, ул Мортаза улы Мозаффар мулла нәселеннән булып, бабасы хәзерге Чүпрәле районы Чокал авылы имамнарыннан икән. Габденнасыйр имам җитмеш биш ел гомер кичереп, 1833 елда вафат була.

Ул Шырдан мәдрәсендә укый, аннары тагын берничә мәдрәсәдә белем алып, данлыклы Оры авылындагы Хәбибулла ишан мәдрәсәсенә килә, анда мөритлек мәртәбәсе ала, берара Ашытта мәдрәсәдә укый. Зур белемнәр иясе булып җитешә. Ашытта аны имам-мөдәррис итәләр. Мәдрәсәсе даны тиз арада тирә-якларга тарала. Аңа Казан, Буа, Сембер якларыннан шәкертләр килә, Баһаветдин Мәрҗани дә (Шиһабетдин Мәрҗанинең атасы) аңарда укый.

Сәйфелмөлек улы Габденнасыйр имам хак сөйләүче, иманы дөрес, гамәлендә шәригать кушканча эш итүче, гадәти тормыш белән яшәүче булган. Заманында Хәбибулла ишанга мөритлек итеп, аңардан иҗазәтнамә яздырып алса да, аны, ишан белән мөфти арасындагы дошманлык сәбәбендә булыр, яшереп саклаган һәм кешеләргә бер генә дә күрсәтмәгән.

Хатыны Мәхбүбә исемле булып, Туктамыш байның кызы икән. Күп балалар үстергәннәр. Мәхбүбә, иреннән соң калып, 1842 елда вафат булган. Кабере Ашыт зиратында.

Габденнасыйр Ашыти бик тә диндар кеше булган. Аның әүлиялек сыйфатлары да күренгән, изгелек һәм саф-гыйффәт һәммә чалымнарыннан сизелеп торган.

Аның җеназасында олы имамнар катнаша. Арадан Сөбханкол Мәрҗани улы Баһаветдин, аның укучысы һәм Шиһабетдин Мәрҗанинең атасы: «Ашыт зиратында вәли кабере бар. Халык, ышанып, аның каберен зиярәт итеп йөресәләр дә, бу көн бу вәли дәфен кылынды»,– дип әйткән, ягъни, тагын бер изге кешенең кабере өстәлде, дигән.

Ул заманнарда «вәли зираты» дип хәзер «изгеләр зираты»,

«әүлия күмелгән җир» дип йөртелгән каберлекне әйткәннәр. Мәсәлән, Биектау районы Камай (Иске Казан) авылы каршында, Чагыл тау башында, төньяк тарафта Изгеләр зираты бар, анда мәчет салганнар, чардуганнар корганнар, чишмәсе дә матур итеп эшләнгән. «Анда Мулла хаҗи күмелгән», – диләр. Иске заман Сәрдә имамнарының бу зират белән бәйле гаугалы гамәлләре хакында документлар аша безгә килеп ирешкән хәбәрләрдән күренгәнчә, анда Әремле хуҗа һәм аның кызы Гайшәнең гүрләре икән. Ерак түгел урнашкан Айшә авылы да шул Гайшә-бикәгә нисбәтле булса кирәк? Әмма Казан артында Гайшә каберләре берничә урында. Аларда чыннан да Гайшә исемле изге кеше күмелгәнме, әллә гомумән дә изге хатын-кызны Гайшә исеме белән атау тәртибе булганмы?... Күз тиюләрдән «Фатыйма кулы саклый», диләр. «Гайшә-бикә кабере» дигәннәре дә, халык уйлавынча, шундый бер ырым-күзаллауларга бәйле, хикмәткә ия түгелме икән?

Әремле хуҗа бу яклар кешесе түгел. Аның «хуҗа» дип аталуы бер-бер әүлия-ишан кебек бөек кеше булганлыгы хакында сөйли. Себер татарларыннан түгел идеме икән?

Арча ягы галимнәреннән тагын да берсе – Олы Мәңгәрнең имамы Кытый улы Сафкол хәзрәт. Төп чыгышы белән ул Кырым татары булган. XVI гасырда аның бабасы сугышта әсир төшеп, монда китерелгән, аны Килмәк исеме белән атаганнар. Оныгы Сафакол, гыйлемдә алай ук маһир саналмаса да, диндарлыгы, тәүфигы белән халыкның мәхәббәтен яулап алган. Коръән һәм догалар укыганда ясаган хата һәм кимчелекләре өчен, дога артыннан өстәп, аерым бер гафу үтенү («укыганда ясаган хата һәм кимчелекләребез өчен гафу әйлә» дип сорау) гадәтен догачылар теленә ул керткән. Кыска төннәрдә ясигъ намазын ташламаска, витр намазларын да укып барырга халыкны өндәгән. Мөфти каршындагы «Җәмгыяте-шәргыя»дә берничә тапкыр әгъза булып торган, Габдессәлам мөфтинең хөрмәтен казанган.

Сафкол хәзрәт озын буйлы, олы сакаллы, мәһабәт кешеләрдән икән. 1835 елда 78 яшендә вафат булган. Балалары да имамлык дәрәҗәләренә ирешкәннәр, ә икенче улы Мөхәммәт аның урынында муллалык иткән.

Бу якларның тагын бер галиме – Габденнасыйр Курсавиның олы абыйсы Габделхак. 1843 елда вафат була, Курсада җирләнгән. Шушы авылның таш мәчетендә имамлык хезмәтендә торган, мәдрәсә тоткан, анда мөдәррислек иткән.

Яшьлегендә үз авылларында һәм төрле зур мәдрәсәләрдә белем алгач, Бохарага китә һәм Ниязколый Төрекмәнинең мөрите хезмәтендә тора.

Хаҗ сәфәренә Габденнасыйр һәм Габделкәрим исемле туганнары белән бара. Әмма берникадәр вакытка Каһирәдә кала һәм анда тәҗвит гыйлеменнән дәресләр ала. Коръән укуда аның кебек оста кешеләр булмаган диярлек. Шәкертләрен бу гыйлемгә өйрәтүгә күп көч куйган. Коръәнне

дөрес уку серләрен Диярбәкер мөфтие Әбу-Сөгуттан өйрәнгән. Башка төрле рухани гыйлемнәрдә үзенең остазы дип энесе Габденнасыйрны санаган. Хәдисләр китабы төзегән, аны китапчылар бик еш бастырып тараткannar, алардан файда тапканнар.

Габделхак хәзрәт шәкертләренә Коръәнне хатасыз, камил рәвештә өйрәтеп, аятьләргә һәм хәдисләргә дөрес һәм тугры шәрехләр бирә, бу мәсьәләләрдә катгыйлыкны, җаваплылыкны таләп итә торган булган.

Вафатыннан соң имамлык эше Газизә исемле кызының ире Хәмит улы Хәсәнгә кала.

## VI

Мондый да зур һәм танылган галимнәре белән дан алган Арча якларында борынгы китаплар, кульязмалар йорт саен очраргa, кешеләре дә үзләрен белемле, укымышлы итеп күрсәтергә тиеш иделәр кебек. Мине ул өмет күп авылларда йөртте. Байкалдан Чурабашка, аннан Шурага, Шушмабашка, Сәрдәбашка барып чыктык. Авыл администрациясе башлыгы Вәзир Вазыйх улы Сәгыйтовка рәхмәт, ул мине «Яхъя угылы Болгари» каберенә алып килде. Аның кабер ташы Үгез-Елга авылыннан төньяктагы тауда иде. Тирә-ягы – киң басу. Бу урынны әүлия зираты дип йөртәләр икән. Ташына вафаты мең дә тугыз йөзенче елның июле буларак күрсәтелгән. Яхъя улы Болгари үз заманында шактый күп китаплар язган. Әмма фәндә алар әлегә Яхъя ишанга нисбәт ителә. Ә ул Шекә авылында яшәгән һәм кабере дә шунда. Аны да күреп китү мөмкинлеге бар.

Вәзир әфәнде безне Шекәгә алып китте. Яхъя бине Сәфәр бине Арыслан әл-Бәрәзәвинең, ягъни Яхъя ишанның, кабере авыл зираты уртасында икән. Урам яктан ап-ак мәрмәр таш кебек күренә. Эчкә узып, янына барсак, гап-гади, измә белән генә катырып эшләнгән икән.

Башка көннәрне Апаз, Каргалы, Пешәңгер, Хәсәншәех, Ташкичү, Мәмсә һәм башка авылларда булдык. Әйе, тәрбияле, укымышлы яклар. Соклангыч халык икән бу арчалылар!

Әмма күңелне тырнап торган нәрсәләр дә кала. Бу – Оры авылы туфаны мәсьәләсе иде, аның чынлыкта булуы яки булмавы һәм нигә бу якларда аңа шушы кадәр игътибар бирүләре.

## VII

Тарихыбызга Арча ягы биргән бөекләрне төгәллек белән барлау, каршылыклы мәсьәләләрне ачыклау, китапларга, энциклопедия-сүзлекләргә кертелгән шәхесләр белән бәйле очракларны тулыландыру, яңа фактлар өстәү өчен гыйльми экспедиция материаллары зур әһәмияткә ия. Бөтенләй көтелмәгәнчә, Шиһабетдин Мәрҗанинең әлегә фәнгә мәгълүм булмаган хезмәтенең кульязмасы табылды. Аны саклаганы һәм безгә тапшырганы өчен Арча районы Байкал авылыннан гомере буе колхозда сыер сауган Ахунова Галиябану Габделфәрт кызына чиксез рәхмәтлебез. Ул китап аңа кайнанасы Газизә Хәким кызыннан (1901–1970) мирас булып калган.

Шиһабетдин Мәрҗанинең әтисе Баһаветдин исемле булган. Ул 72 ел гомер кичереп, 1856 елда вафат булган. Аның кабере Ташкичү зиратында. Гомере буе ул шушы авыл мәчетенең имамы вазифасын башкарган, мәдрәсә тоткан һәм анда мөдәррислек иткән. Баһаветдиннең әтисе – Сөбханкол Мәрҗани, аның әтисе – Габделкәрим исемле булган. Шушы Габделкәрим хәзрәт исә чыгышы белән Мәрҗан авылыннан. Ул авыл хәзер Япанчы исемен йөртә һәм Әтнә районына карый.

Нәсел башлары Габделкәрим хәзрәт Мәрҗан (хәзергечә Япанчы) авылыннан булганга, үзен «Мәрҗани», ягъни «Мәрҗан авылы кешесе» дип йөрткән. Шуның сәбәпле аның нәселенә дә «Мәрҗани» кушаматы йогып калган. Хәер, алар үзләре дә исемнәренә «әл-Мәрҗани» тәхәллүсен өстәү гадәтен алганнар. Бу тәхәллүс аның данлыклы галим улы Шиһабетдингә дә, аның икетуган энесе – язучы Мәхмүт Галәүгә дә күчкән. Берсе – Шиһабетдин Мәрҗани, икенчесе Мәхмүт Мәрҗани. Дөрес, Шиһабетдин Мәрҗани хәтта «әл-Казани» имзасын да алган. Шиһабетдин Мәрҗани исә тумышы белән Арча районы Ташкичү авылыннан булган. Аның атасы Баһаветдиннең беренче хатыны Ашыт авылыннан Сәйфелмөлек улы Габденнасыйрның кызы Хәбибә булган, әмма аның вафаты сәбәпле, ул Хәбибәнең сеңлесе Хөббийәгә өйләнгән.

Баһаветдин Мәрҗани Бәрәскәдә Ибраһим улы Бикчәнтәй мөдәррис мәдрәсәсендә, аннары Ашытта – булачак бабасы Габденнасыйр имам-мөдәрристә, аннары Бохарада Хокандтан Рәхмәтулла улы Гайсә, Нәдер Хөҗәнди улы Салих мөдәррисләрдә белем алган.

Баһаветдин Мәрҗанинең мәдрәсәсендә Казан арты һәм Буа ягы шәкертләре укыганнар һәм үз чорларының данлыклы белем ияләре, имамнары буларак танылганнар.

Хатларыннан аңлашылганча, улы Мәрҗанигә киңәшләре белән дә, тарихи мәгълүматлар җыюда да ярдәм иткән, кайбер фикерләрен бәхәс итеп, гыйльми нигездә раслауда юнәлешләр биргән.

Тагын да бер галим – Оры авылы Галләм Хафиз нәселеннән Габдерразак мулла улы Ягъкуб хәзрәт. Ул, Риза Фәхретдиновның «Асәр»дә язуыннан аңлашылганча, заманында иң белемле кешеләрнең берсе булган. «Хөкем лаихәләре шулкадәр тәртипледер ки, буның кеби хөкем матдәсене тугыры асаслара бина идеп язан кемсә Собраниядә тордыгы бәңа мәгълүм улмады,– дип белдерә ул. – Бәңа күрә бу зат тугъры фәһемле, зиһенле, гакыллы, вәкарьле һәм дә мәсләкле вә кермеш юлының ахырына чыкар ичүн гайрәтле бер адәмдер». Габдерразак хәзрәт Диния нәзарәтенә берничә тапкыр утырышчы итеп сайлана, шәригать кануннары нигезендә хөкемнәрне дөрес алып бара, дин эшләренә бәйле күзәтчелек эшләрен тигез йөртә. Мөфти белән даими хат алышып торучыларның берсе. Ул 70 ел гомер кичереп, 1869 елда Иж заводында вафат була.

Юлыбыз алга таба Әтнә районына алып китте. «Монда Шиһабетдин Мәрҗани музее бар», – диделәр. Күлле-Кимедә – Сибгат Хәким! Бу район үзенә бер татар дөньясы, ул – һәр авылы, һәр ташы белән тарихи!

Бу якларга экспедициябез тәмамланып ике ай да вакыт үтмәде, күңелне юатырлык хәбәр килеп иреште: безнең галимнәр төркемен озатып, көнебезне көйләп йөргән шоферыбыз Рөстәм Солтан улы Гыйльфанов, туган энекәше Ленар Дамир улы Гыйльфанов белән икәүләп, Арча районы Казиле авылы каршындагы әүлия зиратының кабер ташын, аунап яткан җиреннән казып чыгарып, юып-чистартып, төзәтеп, тиешенчә ныгытып ясап утыртып куйганнар. Никадәр олы һәм изге эш. Ул зиратта 945 елда (милади ел исәбенчә 1538 елда) вафат Кемәш угылы Ужур күмелгән икән. Ташының һәм язуының затлылыгы бөек бер зат булганлыгы хакында сөйли. «Ужур» исемен хәзерге әйтелештә «Җорҗ» дияләр иде, ягъни ул «Чура» дигән исем булып чыга. Аннары, халкыбызның борынгы тарихларына, истәлекләренә һәм рухи-мәдәни мирасына хөрмәт, горурлык, рәхмәт хисләрен тәрбияләү, шуларның нәтиҗәләрен күрү, алар хакында ишетү – үзе бер бәрәкәт кебек тоемлана.

**Әдәбият**

*Фәхретдинов Р.* Асар. Беренче җилд. Беренче җөзьә. Казан: Казан император университеты типографиясе, 1900. 32 б.

*Фәхретдинов Р.* Асар. Беренче җилд. Икенче җөзьә. Оренбург: Г.И. Кәримов типографиясе, 1901. 87 б.

*Фәхретдинов Р.* Асар. Беренче җилд. Өченче җөзьә. Оренбург: М.-Ф.Г. Кәримов типографиясе, 1903. 160 б.

*Фәхретдинов Р.* Асар. Беренче җилд. Алтынчы җөзьә. Оренбург: М.-Ф.Г. Кәримов типографиясе, 1904. 338 б.

***Яхин Фәрит Зәкиҗан улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать*
*институтының текстология бүлеге мөдире*

УДК 001.83(100)

*А.Р. Москвина*

# МӘГАРИФ, ФӘН ҺӘМ МӘДӘНИЯТ ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ ТАТАР-КАЗАКЪ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕНЕҢ ЯҢА ФОРМАЛАРЫ

*(ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ тәҗрибәсеннән)*

В статье рассматриваются вопросы международного сотрудничества в сфере науки и культуры на примере Республики Татарстан и Казахстана. В частности, анализируются связи Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ с научными учреждениями Казахстана, раскрывается потенциал различных форматов сотрудничества.

**Ключевые слова:** международное сотрудничество в сфере науки и культуры, научные связи, международные связи Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ.

Яңа меңьеллык чигендә, глобальләштерү дәверендә традицион сәнгати мәдәниятебез, тарих, телебез нигезен өйрәнү милли сыйфатларыбызны, рухи кыйммәтләрне саклап калуның төп шарты булып санала. Милли мәдәни һәм фәнни өлкәләр аерымланган хәлдә үсешкә ирешә алмый. Татарстан өчен соңгы дистә елларда бу юнәлештәге эш дәүләтнең актив ярдәме белән алып барыла.

Республикада милли филология, әдәбият белеме һәм сәнгать белеме өлкәләрендәге фәнни тикшеренүләр һәм татар халкының рухи кыйммәтләрен саклау, шул исәптән башка халыклар, аеруча төрки кардәшләр белән мәдәни фәнни һәм сәнгати бәйләнешләр алып бару миссиясен үтәүдә ТӘҺСИ әйдәүче фәнни оешма булып тора. Хәзерге вакытта Татарстанда гына түгел, Россиядә, якын һәм ерак чит илләрдә яшәүче татарларның матди һәм рухи мәдәниятен тикшереп өйрәнү активлаша бара, үзара фәнни һәм мәдәни элемтәләр торгызыла, күп милләтле пространство шартларында тел, мәдәният, сәнгать үсеше закончалыклары һәм үзенчәлекләре ачыклана. Татар телен, әдәбиятын һәм сәнгатен төрки халыкларның рухи мирасы яссылыгында өйрәнү милли (татар) фән өчен уңышлы нәтиҗәләр яуларга мөмкинлек бирә.

ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты бу юнәлештә үз эшен Россиянең Башкортстан, Мари Эл, Чувашстан, Тыва Республикаларындагы, Түбән Новгород, Әстерхан, Омск, Төмән һ.б. өлкәләрендәге һәм Пермь краендагы, Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Казакъстанның татарлар күпләп яши торган төбәкләрендәге, Иран, Төркмәнстан, Төркиядәге фәнни үзәкләр белән тыгыз элемтәдә алып бара. Киң спектрдагы уртак проектларны тормышка ашыруга яшь галимнәр дә

тартыла. Әлеге язма кысаларында Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ белән Казакстан арасында барган фәнни диалогка киңрәк тукталып узу урынлы булыр.

Мәгариф системасы буенча Алматы шәһәрендәге шушы өлкә белән шөгыльләнүче М.О. Ауэзов исемендәге әдәбият һә сәнгать институты белән элемтәләр киңәя. 2016 елның май аенда аннан өч магистрант Казанга килеп «Әдәбият белеме» буенча стажировка уздылар (аның кысаларында фәнни архивларны тикшереп өйрәнү эшләре, әлеге проблемалар белән шөгыльләнүче яшь галимнәр белән танышу каралган иде).

Фәнни элемтәләр төрле юнәлешләр буенча Казанда һәм Казакъстанның фәнни үзәкләрендә оештырыла торган конференцияләр ярдәмендә ныгытыла (әлбәттә, аларның һәркайсында яшь белгечләр дә катнаша). Мәсәлән, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган «Фольклор системасында милли һәм гомумкешелек кыйммәтләре» дигән халыкара фәнни-гамәли конференциядә (2014 ел, апрель) Б.У. Азибаева (М.О. Ауэзов исем. Әдәбият һәм сәнгать институты) Ж.А. Аймухамбетова, К.К. Сарекенова (Л.Н. Гумилев исем. Евразия милли университеты), Р. Абилхәмит кызы (Казакъстан Республикасының С. Сәйфуллин исем. агротехник университеты) катнаштылар. А.К. Ниязов (Казакъстан Республикасы милли сәнгать академиясе) педагог-мәгърифәтче, рәссам Ш.А. Таһировның тууына 150 ел тулуга, ә Р.И. Каргабекова (М.О. Ауэзов исем. Әдәбият һәм сәнгать институты) белән С.Ж. Кобжанова (Казакъстан Республикасының А. Кастеев исем. дәүләт сәнгать музее) П.М. Дульскийның тууына 135 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференциягә килделәр.

2009 елда Казанда уздырылган «Төрки дөньяда киез сәнгате: үткәне һәм бүгенгесе» халыкара симпозиумында киез басу осталары династиясеннән Беспековлар гаиләсе катнашты.

Җаекта (Уральскида) М. Утемисов исем. Көнбатыш Казакъстан дәүләт университеты һәм шул ук исемдәге музей базасында күренекле татар шагыйре Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗатына багышлап уздырылган конференцияләргә ТӘһСИ галимнәре дә чакырылган иде. 2016 елның апрелендә Алматыда «XX гасыр – XXI гасыр башында сәнгать белеме мәсьәләре» дигән халыкара фәнни-гамәли конференциядә безнең Институтның яшь галимнәре (М. Газизова белән Л. Шкляева) катнашты.

Мәдәниятара диалогны үстерүдә мәдәни өлкәдәге элемтәләрне, мәдәни вакыйгалар хакында мәгълүмат алышуны киңәйтү зур әһәмияткә ия. ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Казакъстан Республикасының Алматыдагы Т.К. Жургенов исем. Сәнгать академиясе, М.О. Ауэзов музей-йорты һәм Семей шәһәрендәге Невзоровлар гаиләсе исемен йөрткән Сәнгать музее белән хезмәттәшлек итә. «Татарстан һәм Казакъстан рәссамнары», «Төрки театрлар рәссамнары» дигән

алмаш күргәзмәләр оештыру буенча эш алып барыла.

Фәнни басмалар әзерләү өлкәсендә ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ белән Казакъстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Фән комитеты каршындагы М. Ауэзов исем. Әдәбият һәм сәнгать итституты арасында хезмәттәшлек итү буенча килешү төзелде. Аның кысаларында «Төрки тел театрлары фестиваль хәрәкәте» җыентыгы, «Казакъстан рәссамнарының тасвирый сәнгате үсешенә Татарстан рәссамнары йогынтысы» дигән очерклар сериясе бастырып чыгару планлаштырыла. Г. Тукайның тормыш юлын һәм иҗатын колачлаган персональ энциклопедиядә дә Казакъстан галимнәренең өлеше бар.

ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИ Казакъстанның А. Байтурсынов исем. Тел белеме институты белән хезмәттәшлек итә. 2014 елның май аенда безнең Институт галимнәре Алматыда булып, озак вакытлы фәнни хезмәттәшлек турында сөйләшеп кайтканнар иде. 2016 елның июнендә яшь галимнәребез, Татарстан Республикасыннан читтә тупланып гомер итүче татар халкының туган телен, тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү максаты белән, Казакъстанның Семей шәһәрендә булып кайттылар.

ТӘҺСИның Язма һәм музыкаль мирас үзәге хезмәткәрләре белән Астана шәһәрендәге Халыкара төрки академия галимнәре тарафыннан ««XX гасыр башы төрки-татар вакытлы матбугатының электрон-мәгълүмати сайты»н булдыру», Г. Рәхим белән Г. Гобәйдуллинның «Татар әдәбияты тарихы»» басмасын текстологик әзерләп нәшер итү, «Аталар мирасы» программасы нигезендә Сәиф Сараи әсәрләрен, Корбангали Халидинең «Тәварихы хәмсәи шәркыйә» хезмәтен текстологик яктан басмага әзерләү буенча уртак проектлар тормышка ашырыла.

2016 елның апрелендә Э.Р. Каюмова М.О. Ауэзов исем. Әдәбият һәм сәнгать институтында «Хәзерге этапта Татарстанда музыка белеме: проблемалар һәм перспективалар» һәм «Республикада традицион мәдәниятне үстерү үзәге эшчәнлеге юнәлешләре һәм нәтиҗәләре турында» дигән темалар буенча чыгышлар ясады. Алар Казакъстан институты хезмәткәрләренә татарларда музыка белеме һәм фольклористиканың бүгенге торышы, өр-яңа әдәби һәм музыкаль язмалар белән якыннан танышырга мөмкинлек бирде, шулай ук төрки телле халыкларның рухи мәдәниятен чагыштырма планда өйрәнеп тикшеренүче Казакъстан галимнәре өчен бай материал булып хезмәт итәчәк.

Хәзерге вакытта Халыкара төрки академия белән берлектә «Аталар мирасы» күптомлыгын әзерләү проекты өстендә эш алып барыла.

2008 елдан ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты күппрофильле фәнни-тикшеренү институтлары белән халыкара хезмәттәшлек өлкәсендәге традицияләрне дәвам итә. Бу юнәлештә мәгълүмати багланышларны киңәйтү

һәм фәнни эшчәнлектә үзара фәнни-методологик йогынтыны көчәйтү, лекция курсларын алып баруда автор-белгечләр алмашу, фәнни материаллар һәм тикшеренү нәтиҗәләре турындагы басма хезмәтләр белән танышып бару, фәнни эшләрне рецензияләүдә үзара хезмәттәшлекне җәелдерү, хезмәткәрләр өчен фәнни стажировкалар оештыру зур әһәмияткә ия. Югарыда саналган чаралар татар фәнен халыкара казанышлар үрнәгендә үстерергә ярдәм итәчәк. Яшь галимнәр белән уртак фәнни тикшеренүләрне дә ешрак уздырасы иде. Онлайн конференцияләр, фәнни-гамәли семинарлар, форумнар, тематик симпозиумнар, дистанцион белем бирү, архив базалары онлайнына үтеп керү, бергәләп күргәзмәләр, яшь белгечләр өчен стажировкалар оештыру да уңай нәҗитәләргә юл ачар иде.

***Москвина Альбина Ринат кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли*
*сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 78

***Э.М. Галимова***

# ТАТАР МУЗЫКА СӘНГАТЕНДӘ Г. ТУКАЙ МИРАСЫ

Многогранное творчество Г. Тукая неоценимо в развитии татарской профессиональной музыкальной культуры. Наследие выдающегося поэта является богатейшим источником сюжетов и мотивов для татарских композиторов и деятелей культуры в создании различных по жанру музыкальных произведений. В татарской профессиональной музыке возник целый пласт произведений, связанный в своих истоках с творчеством великого поэта.

**Ключевые слова:** поэзия Г. Тукая, музыкальное наследие, Г. Тукай и татарская музыка, Г. Тукай и музыкальный фольклор, поэзия и музыкальные жанры.

Г. Тукай шәхесе турында бар нәрсә дә мәгълүм, аның иҗаты һәм үз заманының иҗтимагый тормышында тоткан урыны бар яктан да өйрәнелеп беткән кебек. Ләкин бу беренче карашка гына шулай тоела. Чынлыкта исә Тукай темасына кагылышлы өйрәнелмәгән аспектлар чиксез, ул һәр яңа буын тикшеренүчеләргә яңа яктан ачыла, чөнки вакыт, тарихи вакыйгалар үз кануннарына буйсындыра, һәм шул уңайдан фәнни яктан өйрәнер өчен кызыклы юнәлешләр барлыкка килә.

Г. Тукай энциклопедиясе – бөек шагыйрьгә бәйле булган, бүгенге көндә әле һаман да ачыкланмаган сорауларга җавап табар өчен менә дигән фәнни басма. Энциклопедия – музыка сәнгатенең барлык тармакларын үз эченә алган. Шагыйрь сүзләренә язылган халык җырларының феноменын ачыклау, төрле жанрдагы музыкаль әсәрләрне анализлау, әлеге шәхескә багышлап язылган музыкаль сәхнә әсәрләре үрнәкләренең үзенчәлеген билгеләү, театр һәм кино сәнгатендә әһәмияткә ия булган иҗади мисалларны барлау, яңа буын композиторларының бүгенге заман ысуллары белән язылган әсәрләрен тасвирлау һәм башка темаларга кагылышлы 140 ка якын мәкалә урын алган анда.

«Тукай һәм татар музыкасы» бәйләнеше, тема буларак, мәгариф системасында киң чагылыш таба. Шулай ук әлеге мәсәлә фәнни яктан А. Алмазова, Г. Гобәйдуллина, Й. Исәнбәт, Р. Исхакова-Вамба, М. Нигъмәтҗанов, З. Сайдашева, Ф. Салитова, Ф. Арсланова, И. Газиев һәм башка музыка белгечләре хезмәтләрендә тикшерелде.

Әйтергә кирәк, Г. Тукай иҗаты – татар музыкасының формалашуына һәм алга таба үсеш алуына зур этәргеч бирде. Ни өчен дигәндә, иң беренче мәсьәлә итеп, музыка белгечләре, фольклор үрнәкләрен күздә тотып, шагыйрь иҗаты белән халык көйләренең бәйләнешен өйрәнәләр. Әлбәттә, бу юкка түгел, чөнки Тукай көчле тавыш иясе булмаса да, илһамланып Коръән

сүрәләрен, «Мөхәммәдия» китабын, борынгы татар бәетләрен, мөнәҗәтләр һәм озын көйләрне җырларга яраткан. Китап уку көйләренең ритмик калыбын ассызыклап, халык җырларының «моң» феноменын билгеләгән үзенчәлекләрен күңеле белән тоя белгән. Тукайның «Милли моңнар» шигыре «Әллүки» көе белән илһамланган, «Өзелгән өмид»нең музыкаль-поэтик символы булып – саз, ә «Авыл җырлары» шигырьләр циклының нигезендә халык җырлары тора. Әлеге татар музыкасының нигезендә яткан халык җырлары турында энциклопедия битләреннән тирәнтен мәгълүмат алып була.

Энциклопедиянең музыка сәнгатенә һәм музыкаль фольклор юнәлешенә кагылышлы өлешен барлап чыккач, берничә фикер белән уртаклашасы килә. Гомумән алганда, татар музыкасы сәнгатендә Г. Тукай мирасын фәнни яктан өч юнәлешкә бүлеп өйрәнеп була. Әлеге фикер энциклопедия эчтәлегендә дә чагылыш таба.

Беренче юнәлешкә югары сәнгать төренә караган, Г. Тукай шәхесен күздә тотып язылган һәм бөек шагыйрьнең тормышын чагылдырган әсәрләрне кертергә була. Татар музыкантларының композиторлык эшчәнлегендәге беренче иҗади эшләренә бәя бирү һәм тарихи фактларга ачыклык кертү энциклопедиянең уңышлы ягын билгели. Шагыйрь мирасы милли композиторларыбыз С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин, Н. Җиһанов, М. Мозаффаров, А. Ключарев, Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин иҗатларында төрле жанрдагы әсәрләрдә чагыла: вокаль һәм инструменталь миниатюралар, зур күләмле симфоник музыка үрнәкләре һәм музыкаль сәхнә әсәрләре.

Тарих битләренә күз салсак, революциягә кадәрге камера уен кораллары музыкасының башы Тукайның чордашы Заһидулла Яруллин исеме белән бәйле, һәм ул аның «Тукай маршы»ннан башлана. Берничә дистә елдан соң композитор Н. Җиһанов әлеге әсәрне симфоник башкару өчен оркестровка эшли.

Композитор М. Мозаффаровның «Тукай истәлегенә» дип аталган (1952) симфоник поэмасында шагыйрь исеме халык бәхете өчен көрәшүче символы буларак яңгырый. Әсәрнең беренче музыкаль темасы татар шигъриятенең чәчәк атуын тасвирласа, икенчесендә Тукайның сүзләренә «Анам кабере янында» дип исемләнгән татар халык җыры цитата буларак яңгыраш ала.

Тукай мирасын мәңгеләштерү йөзеннән композитор Р. Ахиярова «Моңлы сазым» (1986) симфоник поэмасын иҗат итә. Әсәрнең үзенчәлеге – «Туган тел» көен цитата буларак куллану. Әлеге тема, шагыйрь тормышының лейтмотивы буларак, лирик халәтеннән чыгып, ахырга таба гимн кебек яңгырый.

«Туган тел» көе шулай ук Р. Кәлимуллин иҗат иткән «Г. Тукай истәлегенә» дип исемләнгән квартет нигезендә дә яңгырый. Кыска интонацион лейттемадан этәргеч алып, аны эзлекле үстереп (тембр, фактура, метроритм ягыннан), композитор оркестровка ярдәмендә динамик үсештәге композиция тудыра. Симфоник

жанр әсәрләре рәтендә композитор Р. Кәлимуллинның кыллы уен кораллары өчен язылган «Тукай көйләре» (2000) симфониясен искә алмыйча булмый. Аның әлеге әсәрләре энциклопедиядә теоретик анализлап бирелә.

Г. Тукайның 120 еллыгы уңаеннан композитор Р. Ахиярова, Р. Харис либреттосына нигезләнеп, «Шагыйрь мәхәббәте» операсын иҗат итә. Операның эчтәлеге мәхәббәт фабуласы белән генә чикләнми. Авторлар шулай ук шагыйрь тормышының аерым мизгелләрен, аның иҗади казанышларын әсәр аша күрсәтүне дә максат итеп куялар. Р. Харис либреттода Тукай тормышыннан биографик фактларны куллана, әсәргә аның шигырьләреннән өзекләр кертә, аның эчке кичерешләрен (мәхәббәткә омтылуын, үлемнән куркуын) чагылдыра. Энциклопедиядә әлеге әсәрнең язылу тарихы турында һәм музыкасына карата төгәл һәм тулы мәгълүмат бирелә.

Яшь композитор буларак, Г. Тукайның 125 еллыгына Р. Батулла пьесасы буенча «Зәйтүнәкәй» дип исемләнгән музыкаль драма иҗат иттем. Әсәрне 2011 елда режиссер Ринат Әюпов Г. Кариев исем. Казан Татар дәүләт яшь тамашачылар театрында сәхнәләштерде. Драманың үзәгендә булган Зәйтүнә образы музыкаль характеристика ягыннан ике лейтмотив аша бирелә. Шуның берсе – «Зәйтүнә җыры» – гади, шул ук вакытта нәзакәтле, бөек шагыйрьгә карата мәңгелек мәхәббәт утында янган гүзәл кыз образы тудыра. Әсәрнең башка үзенчәлекләре турында тулырак мәгълүматны энциклопедия битләрендә таба аласыз. Әлеге әсәр өчен язылган «Ак канатлы шагыйрь» гимны шул ук елда Мәскәүдә бөек шагыйребезгә һәйкәл ачу тантасында яңгырады. Цитата буларак кулланылган «Туган тел» һәм «Тәфтиләү» көйләре татар милләтенең якты киләчәген тасвирлый.

Икенче юнәлешкә без Г. Тукайның әкиятләренә нигезләнеп язылган музыкаль әсәрләрне кертәбез. Әлбәттә, Шүрәле – иң яраткан образларның берсе. Мисал итеп И. Якубовның ораториясен, А. Ключарёвның фортепиано өчен әсәрләрен әйтергә була. Симфоник жанрлар арасында Н. Җиһановның «Кырлай» һәм «Шүрәле» симфоник поэмасы, М. Шәмсетдинованың «Тукай әкиятләре» сюитасы игътибарга лаек.

Балет – Г. Тукай әкиятләренең үзенчәлеген чагылдыру өчен менә дигән жанр. Дөньякүләм танылган композитор Ф. Яруллиның «Шүрәле» балеты – татар музыка сәнгатенең йөзек кашы. Ул бүгенге көнгә кадәр театр репертуарында саклана. Ни өчен дигәндә, композиторның музыка язу үзенчәлеге милли көйләрне заманча ысуллар белән баетудан гыйбарәт. Әлеге әсәр, композиторның бөеклеген дәлилләп, шул чорның музыкаль ачышы булып тора.

Балет жанрында 1957 елда Ә. Бакировның «Су анасы», ә 1958 елда Р. Гобәйдуллинның «Кисекбаш» әсәрләре куела. Энциклопедия әлеге әсәрләрнең язылу тарихын ачыклый. Ләкин ике балетның да иҗади го-

мерләре озын булмый. Музыка белгечләре моның сәбәбе итеп либреттода артык персонажлар күп булуын һәм музыканың төрле стильдә язылуын атыйлар.

2013 елда Г. Кариев исем. Казан Татар дәүләт яшь тамашачылар театры, Т. Миңнуллин пьесасына нигезләнеп, балалар өчен яңа жанрда «Әйт әле күбәләк» музыкаль мистерия премьерасын күрсәтте. Композитор буларак, минем өчен бу бик үзенчәлекле эш булды.

Режиссер Р. Әюпов әсәрдә төп рольне музыкага тапшыра һәм актерларны драматик диалоглардан азат итә. Балалар төп эчтәлекне пластик хәрәкәтләр ярдәмендә аңлыйлар. Кечкенә Апуш Г. Тукайның бөтен экият геройлары белән бергә курку хисен җиңә, ә күбәләк аны киләчәк иҗатында кыю фикерле булырга өнди.

Өченче юнәлешкә без бөек шагыйрь сүзләренә нигезләнеп иҗат ителгән музыка әсәрләрен кертер идек. Г. Тукай шигърияте – вокал жанры үрнәкләрен үстерү һәм кабатланмас җырлар иҗат итү өчен композиторга менә дигән илһам чыганагы. Мәсәлән, Солтан Габәшинең Тукай сүзләренә 1915–1917 елларда иҗат ителгән «Юаныч» һәм «Галәл гомья», «Мәжрух указ» романслары бик кызыклы, чөнки композитор, Тукай шигъриятенең поэтик үлчәмен игътибарга алып, үзенчәлекле көйләр яза. Габәшинең «Бишек җыры»н хор өчен эшкәртүе дә жанр ягыннан яңалык. Шул ук 1925 елда ул, татар музыкасы тарихында беренчеләрдән булып, «Ике заман» исемле хор циклын иҗат итә.

Шагыйрь иҗаты Н. Җиһанов, Җ. Фәйзи, М. Мозаффаров, З. Хәбибуллин, А. Монасыйпов, Ф. Әхмәтов, Р. Еникеев, И. Якубов, М. Шәмсетдинова, Р. Ахиярова, Р. Кәлимуллинның җыр һәм романс циклларында, халык җырлары эшкәртмәләрендә, балалар өчен язылган әсәрләрендә дә чагылыш таба. Шулай ук Р. Яхинның «Шагыйрь» драматик монологы, «Мәхәббәт җыры» лирик романсы – аеруча дан казанган вокаль әсәрләр.

А. Монасыйпов иҗаты тирән мәгънәле әсәрләрдән тора. Аны замандашлары татар музыка сәнгатенең симфонисты дип атыйлар. Зур күләмле әсәрләре арасында баритон һәм симфоник оркестр өчен язылган «Тукай аһәңнәре» вокаль-симфоник поэмасы өчен (1974) композитор шагыйрьнең үз халкына ялкынлы мәхәббәтен, ышанычын һ.б. темаларны эченә алган «Туган җиремә», «Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен...» («Сәрләүхәсез»), «Туган авылым», «Тәүбә вә истигъфар», «Өзелгән өмид», «Белмәдем» («Мөридләр каберстанынннан бер аваз»), «Бу ямьсез болыт» («Татар яшьләре») исемле 7 шигырен сайлап ала. Әсәрнең музыкаль телендә Тукай шигырьләренә язылган («Пар ат», «Туган тел») лирик халык җырлары интонацияләре һәм Гендельнең пассакалиясеннән алынган үткен цитаталар бергә үрелеп бара.

Энциклопедиянең киң колачлы фәнни басма икәнлеген Г. Тукай иҗаты белән бәйле музыка сәнгате әһелләренең иҗади эшчәнлеген тасвирлау да

күрсәтә. Г. Тукай сүзләренә язылган җырлар, романсларны башкаручы татар халкының милли җырчылары – И. Шакиров, У. Әлмиев, Г. Рәхимкулов, Х. Бигичев, Э. Җәләлетдинов, Ф. Сөләйманова И. Газиев, З. Сәхәбиева һ.б. иҗат юллары белән энциклопедиядән танышып була. Тукай темасына кагылган төрле жанрдагы әсәрләр республикабызның музыкаль коллективлары репертуарында да урын алган. ТР дәүләт симфоник оркестры, ТР халык уен кораллары Дәүләт оркестры, «La Primavera» Казан дәүләт камера оркестры, ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, ТР дәүләт фольклор музыкасы ансамбльләре турында энциклопедияга кергән мәкаләләрдә мәгълүмат туплап була.

Г. Тукай иҗаты – тулы бер гасыр дәвамында тирәнтен, эзлекле өйрәнелгән иҗат. Г. Тукай энциклопедиясе – татар милләтенә мәдәни бүләк һәм төрки халыклар өчен тагын бер зур ачыш. Алга таба да шагыйрьнең тормышы һәм иҗади мирасын эзлекле өйрәнүгә, яңа ачыштабышларга җирлек бар. Г. Тукай шәхесенә махсус багышланган энциклопедия алдагы максатларны билгеләргә ярдәм итәр дип ышанып калам.

***Галимова Эльмира Мөнир кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире*

УДК 745.51

*Л.М. Шкляева*

# УРТА ИДЕЛ БУЕ ТАТАРЛАРЫ ЙОРТЛАРЫН БИЗӘҮДӘ ТӨРКИ ОРНАМЕНТЛАР

Статья посвящена анализу происхождения некоторых орнаментов традиционной деревянной резьбы татар Среднего Поволжья. Указывая на древнетюркское происхождение солярных орнаментов и звериного стиля в резьбе, автор обращает внимание на повсеместное их использование и после принятия ислама. Выполняя вначале обережную функцию, эти орнаменты затем стали неотъемлемой частью декоративной системы татарского народа.

**Ключевые слова:** татарское декоративно-прикладное искусство, традиционная татарская деревянная резьба, экстерьер традиционного татарского дома, тюркский солярный орнамент, тюркский звериный стиль в искусстве.

Традицион татар сәнгате йортларның тышкы ягын кисеп, уеп-сырлап бизәүдә бай орнаменталь системаны тәшкил итә, алар милли тарихи һәйкәлләрнең образлы чагылышын һәм символларын саклау функциясен үтәүдә семантик әһәмияткә ия. П.М. Дульский [Дульский], Ф.Х. Вәлиев [Валеев, 2002], Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова [Валеев, Валеева-Сулейманова, 1987] һәм башка сәнгать белгечләре XIX гасыр ахыры – XX гасырның соңгы чирегендә Казан губернасында яшәүче татарларның агачтан салынган авыл йортларын декоратив бизәүне тикшереп өйрәнүгә зур игътибар бирәләр. Алар орнаментларның бик борынгы төрки мәдәният үрнәкләренә барып тоташуын билгелиләр. Үзенчәлекле татар йортларының тышкы бизәлешендә гомумтөрки, Урта Азия, сәлҗүк һәм Госман империясе дәверләреннән килгән бизәү орнаментларын күзәтергә була [Халитов, 2013]. Бүгенге татарларның борынгы бабаларында гамәли иҗатның барлыкка килүе ерак гасырлардан – Идел Болгарстаны, Алтын Урда, Казан ханлыгы заманыннан ук килә. Әлеге мәкаләдә XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында Урта Идел буенда яшәгән татарларның барлык субэтник төркемнәре (Казан татарлары, мишәрләр, керәшеннәр) тарафыннан кулланылган йорт фасадларын кисеп, уеп эшләү орнаментлары типологиясе карала.

Татарларның йортларны киселмә орнаментлар белән бизәү сәнгате борынгырак төрки дөнья белән киң бәйләнгән. Күчмә төркиләр Урта Идел буена VII йөздә килеп урнашканнар [Хузин, 2010, с. 114–116], алар инде мең еллык тарихка, шул ук вакытта зур үсеш алган мәдәнияткә, һөнәрчелеккә һәм агач эшкәртүнең сәнгати серләренә ия булалар [Казаков, 2006, с. 629–630]. Яңа урында алар башта җирле фин-угорларның стационар торак йортларын төзү ысулларын үзләштерәләр. Утрак тормышны кабул иткән күчмә халык,

мөгаен, йортларны бизәүдә элеккеге үзләренә таныш орнаментларны һәм киселмә бизәкләрне дә кулланганнардыр.

Борынгы күчмә төркиләрдә агачны сәнгатьчә эшкәртү осталыгы б.э.к. VIII–VI гасырда ук югары дәрәҗәдә була [Баркова, 2012]. Кисеп эшләнгән бизәкләр көнкүреш һәм табыну эшләнмәләренә төшерелә. Сурәтләр, гадәттә, яхшы таныш хайваннар дөньясы образларын гәүдәләндерә. Татарларның борынгы бабалары кабул иткән җәнлекләр стиле зур киңлекләрдәге Дала территорияләрендә яшәгән халык сәнгатендә шартлы чагылыш тапкан, соңыннан ул татар халык сәнгате осталары тарафыннан йортның тышкы ягына киселмә бизәкләр төшерү сәнгате үзенчәлегенә әверелә һәм орнаменталь бизәлеш элементлары сыйфатында шактый таралу ала. Мәсәлән, татар йортлары фасадын матурлау композициясендә симметрия рәвешендә ике якка урнаштырылган мөгезсыман бөтеркә куллана. Бу орнаментның килеп чыгышы иң борынгы төркиләр культурасы белән бәйле: алар ат дирбияләренә аккош, тәкә һ.б. фигуралар төшерә торган булганнар [Степанова, 2010, с. 103–110], моны өченче Пазырык курганы табылдыклары раслый. Тәкә (тәкә мөгезе) борынгы төркиләр һәм аларның дәвамчылары өчен яшәүгә сәләтлелек чыганагын гәүдәләндерә.

Урта Идел буе татарлары йортларының киселмә бизәлешендә тагын бер орнаментның мәгънәви эчтәлеген ачыклау борынгы төркиләрне саклаучы символга барып тоташа [Валеев, 1969, с. 27]. Ул – казлар (пар каз) сурәте [Арсланова, 1989, с. 156–160]. Монысы кимәк ыруглык кабиләләре каберлекләреннән табылган әйберләр белән раслана. Каз образлары болгарларның (VIII–IX гасырлар) металлдан яки балчыктан ясалган сәнгати эшләнмәләрендә дә очрый. Пар каз сурәте бизәкләреннән файдалануның аңлатмасы катлаулы түгел, ул «өлешләрдән бөтен булу»ны гына белдерә. Бу кошны томшыгын тамчы рәвеше белән XIX гасыр ахырында торакларның экстерьерына урнаштырганнар, һәм әле хәзер дә бу форма яшәвен дәвам итә. Йортларны киселмә орнаментлар белән һәм башка орнитоморф мотивлар белән бизәү бүгенге халык сәнгатендә дә кулланыла. Моның сәбәбе, мөгаен, исламга кадәрге төрки ышанулар һәм риваятьләр белән бәйледер.

Евразиянең күп кенә төрки-монгол халыкларында аккошка табыну көчле булган [Кукашев, 011, с. 79]. Чыңгыз хан үзе ак кошка табынган [Кукашев, 2011, с. 81]. Алтын Урдада XIV гасырда көзгеләрне кош фигуралары белән бизи торган булганнар [Фонякова, 2010, рис. 74–5]. Аккош образлары Казан татарлары халык сәнгатенең йорт бизәлешләрендә әле хәзер дә кулланыла. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Мамадыш районының Баскан авылында аккошлар гаилә бәхетен гәүдәләндерә [Шкляева, 2015, с. 40]. Осталар кошларны парлап, профильдә бер-берсенә каратып, тәрәзә йөзлегенең өске өлешенә

урнаштыралар. Татар җырларында аккошлар сафлык һәм изгелекне символлаштыралар [Габидуллина, Хабибуллина, 2014, с. 32–35]. Кошларга яки җәнлекләргә табыну төрки мәдәниятнең нигезен тәшкил иткән тәңречелеккә барып тоташа [Гумилев, 1967, с. 76–86]. Төркиләрнең халык сәнгатенә күктәге баш Алла-Тәңре һәм аның хатыны – йорт һәм гаиләне яклаучы (мифологиядә еш кына кош рәвешендә кабул ителә торган) Умай образлары тирән үтеп кергән [Степенова, 2010, с. 286].

Борынгы төркиләрдә Тәңре образы соляр розетка рәвешендәге кояш һәм күк белән ассоциацияләнә. Алтын Урда, Идел Болгарстаны һәйкәлләрендә, борынгы төрки чыгышлы артефактларда соляр розеткалар күп төрле формаларда гәүдәләндерелгән. Мәсәлән, б.э.к. V–IV гасырларда яшәгән осталар тарафыннан иҗат ителеп, Пазырык курганнарында табылган эшләнмәләр арасында сигезнурлы розетка белән бизәлгән агач мендәр булуы мәгълүм. Алтай каберлекләрендә ияр покрышкасы өчен дүрттаҗлы чәчәк формасында эшләнгән тәңкә табыла. Ат дирбияләренең кайбер детальләре очына түгәрәк диск рәвешендәге розеткалар беркетелгән булган. Хуннулар (сөнниләр) дәверендә (б.э.к. I гасырда һәм безнең эраның I гасырында) табут тышына розеткалар төшерелгән булган. VIII–X гасырда салтау (болгар-хәзәр) осталары әйберләрне розетка һәм тукранбаш орнаментлары белән бизи торган булганнар [Фонякова, 2010]. Иртә болгар декоратив-гамәли сәнгатенә салтау-маяк культурасының эстетик йогынтысы [Валеева-Сулейманова, 2006, с. 594] Хәзәр каганлыгыннан Урта Иделгә күчеп килүчеләрнең күплеге белән аңлатыла [Халиков, 1969, с. 74]. Розетка орнаментлары белән бизәү буыннан-буынга күчә барган, йортларны киселмә орнаментлар белән матурлау халык сәнгатенә үтеп кергән. Эре розеткалар һәм аларның сегментларын капкаларга урнаштыру бүгенге татарларның борынгы бабалары күчмә тормыш белән гомер кичергәнлеге турында сөйли. Борынгыда тирмәгә керү-чыгу өчен көйләнгән киез ишекләрне ыруглык тамгалары һәм орнаментлар белән бизәү гадәте күчерелмә торакларның агач ишекләренә дә кисеп-уеп эшләнгән бизәкләр төшерүне дәвам итүгә йогынты ясаган. Татарларда өй ишеге койма артына «яшерелгән» була, шуңа күрә ул капка ачылуга күренеп торырлык итеп бизәлә.

Хәзер татарлар йортның тышкы бизәлешендә тукранбаш орнаментларыннан киң файдаланалар. Моның төп чыганагын салтау-маяк культурасы йогынтысы белән болгарларда киң таралыш алган тукранбаш образы тәшкил итә, ә аның беренчел үрнәге төркиләр исламны кабул иткәнче үк инде табигать көчен символлаштырган лалә чәчәк булган [Фенякова, 2010, с. 69]. Тукранбаш гәүдәләнеше иртә болгар декоратив-гамәли сәнгате әсәрләрендә билгеләп үтелә [Валеев, Валеева-Сулейманова, 1987, с. 30–31; Валеева, 1983]. Бу форма, Пазырык культурасы

дәверендә үк төрки кабиләләр тарафыннан файдаланылганлыктан, болгарларга генетик яктан таныш була (аның башлангычы – поши мөгезләренең стильләштерелгән образыннан гыйбарәт). Күрәсең, нәрсәдәндер саклануга нигезләнгән табигый тойгы нәтиҗәсендә бу форманы үсемлек орнаменты алыштырган.

Йортларны тыштан бизәү тарихының төрки катламы татар декоратив сәнгатенең тотрыклы юнәлеше – үреп эшләнгән бизәкләр төшерү белән бәйле. Борынгы күчмә кабиләләр торакларының агач терәген, ныклык өчен, үрелгән баулар белән чорный торган булганнар. Бу алымны соңрак торакның тышкы күренешендә мәҗбүри элемент буларак кабул иткәннәр һәм ул алардан соңгы буыннар осталары тарафыннан үрмә орнамент рәвешендә файдаланылган [Халитов, 2013, с. 36–40]. Хәзер аны татарлар йортларының тышкы ягын бизүдә кулланалар. Әйтик, Татарстанның Мамадыш районы Баскан авылындагы тәрәзә йөзлекләренең өске өлешендә кисеп эшләнгән кошлар сурәтләрен очратасың. Алар ике детальдән тора, берсе – кошның гәүдә контурын, икенчесе аның каймалап үрелгән койрыгын хәтерләтә.

Шулай итеп, борынгы төрки халыкларның дөньяны кабул итүен чагылдырган орнаменталь сәнгатьне татарларның борынгы бабалары да кабул иткән һәм ул болгарларның, аннан соң татар халкының декоратив системасына үтеп кергән. Авылларда әлегә кадәр торак фасадларын бизәүдә төрки чыгышлы орнаментларга символик мәгънә бирәләр. Йортларны тарихи формалашкан милли рухтагы киселмә бизәкләр белән матурлауда алар янәшәсенә элек-электән төрки саналган элементлар өстәлә килә. Татарларның субэтник төркемнәренең дин белән бәйләнмәгән гомум тарихи үткәне төрки орнаменталь катлам аша чагылыш таба.

**Әдәбият**

*Арсланова Ф.Х.* Образ птицы на головных уборах кимакских женщин // Маргулановские чтения: сб. м-лов конф-ции. Алма-Ата: Б. и., 1989. С. 156–160.

*Баркова Л.Л.* Скотоводы Алтая (Пазырыкская культура) в Скифскую эпоху // Кочевники Евразии на пути к империи: СПб.: Принт, 2012. С. 91–103.

*Валеев Ф.Х.* Орнамент казанских татар. Казань: Таткнигоиздат, 1969. 204 с.

*Валеев Ф.Х.* Татарский народный орнамент. Казань: Таткнигоиздат, 2002. 302 с.

*Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Древнее искусство Татарии. Казань: Таткнигоиздат, 1987. 166 с.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Булгарское искусство // История татар с древнейших времен: в 7-ми т. Казань: Рухил. 2006. Т. 2. С. 594–602.

*Валеева Д.К.* Искусство волжских булгар (X – начало XIII вв.). Казань: Таткнигоиздат, 1983. 132 с: ил.

*Габидуллина Ф.И., Хабибуллина Л.И.* Образ птицы в татарской литературе // Филологические науки. Вопросы теории и практики. № 9.4.1. Тамбов. Грамота, 2014. С. 32–35.

*Гумилев Л.Н.* Древние тюрки. М.: Наука, 1967. 504 с.

*Дульский М.П.* Орнамент казанских татар // из архива П. М. Дульского, папка 2 «А» Рукописи. Искусство Татарстана. Казань. Промыслы. 7 с.

*Казаков Е.П.* О взаимодействии волжских болгар с финно-уграми // История татар с древнейших времен в 7-ми т. Казань: Рухил, 2006. Т. 2. С. 629–630.

*Кукашев Р.Ш.* Лебедь – птица шаманская // Символы тюркской культуры. Ташкент: ART-PRESS, 2011. С. 79–83

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос: книжные дастаны. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2014. 380 с.

*Полякова Г.Ф.* Изделия из цветных и драгоценных металлов // Город Болгар: ремесло металлургов, кузнецов, литейщиков. Казань, ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1996. С. 232–235.

*Степанова Е.В.* Конское снаряжение кочевников Алтая скифского времени (по материалам курганов пазырыкской культуры) // Кочевники на пути к Империи. Из собрания государственного Эрмитажа. Каталог выставки. СПб.: Славия, 2010. С. 103–110.

*Фонякова Н.А.* Прикладное искусство Хазарии второй половины VIII–X вв. по материалам художественной металлообработки. Казань: Институт истории АН РТ. 2010. 168 с.

*Халиков А.Х.* Древняя история Среднего Поволжья. М.: Наука, 1969. 394 с.

*Халитов Н.Х.* Стили и формы средневековой архитектуры Казани: историко-архитектурное исследование. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. 351 с.

*Хузин Ф.Ш.* К вопросу о времени возникновения оседлости у волжских булгар // Научный Татарстан. 2010. № 4. С. 114–126.

*Шкляева Л.М.* Образ птицы в декоре экстерьера сельских строений татар Среднего Поволжья рубежа XX–XXI веков (по результатам экспедиции 2013 года в Мамадышский район Республики Татарстан) // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств. 2015. № 2. С. 261–304.

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли*
*сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 76.03

***М.Р. Газизова***

# 1920–1930 ЕЛЛАРДА «ЧАЯН» ЖУРНАЛЫ БИТЛӘРЕНДӘ ХАЛЫКАРА СӘЯСИ САТИРА

Статья посвящена сатирической графике Татарстана 1920–1930-х годов. Автор анализирует развитие международной темы на страницах журнала «Чаян», показывает изменение тематики в зависимости от особенностей международной политики и интересов государства, выделяя два периода – 1920-е и 1930-е годы. Эти же периоды отражают и художественные особенности журнала, характеризующиеся ограниченным кругом художников и их полупрофессиональным уровнем в 1920-е годы, работой большого числа профессиональных мастеров сатирической графики — в 1930-е годы.

**Ключевые слова и фразы:** сатирическая графика; международная политическая сатира; журнал «Чаян»; искусство Татарстана.

Совет хакимиятенең беренче елларында карикатура массакүләм агитация сәнгатенең төп өлешен били. Яңа җәмгыятьне актив пропагандалау һәм аның дошманнары белән көрәш карикатура ярдәмендә алып барыла. «Советская карикатура [20-е годы XX века] набирала тогда высоту. Ещё совсем молодая, она с каждым днем становилась все более зрелой. С первых дней своих была искусством переднего края. В этом ее сила. И основа ее притягательности» [Телькович, 1977, с. 5]. Сатирик рухтагы вакытлы матбугат басмалары күренә башлый: мәсәлән, «Крокодил» (Мәскәү, 1922), «Прожектор» (Мәскәү, 1923), «Мыштым» (Үзбәкстан, 1923), «Нианги» (Грузия, 1923). Татарстанда 1923 елдан айга бер мәртәбә сатирик «Чаян» журналы чыгарыла башлый (ул үз эшен әле дә дәвам итә). Бу журнал башта татар телендә генә нәшер ителә, ә 1956 елдан башлап, шул ук исемдә рус телендә дә басыла.

«Чаян», «Нианги», «Мыштым» кебек милли басмалар Россиядә инкыйлабка чаклы ук эшләп килүче сатирик журналистиканың дәвамчылары булалар. «Чаян», XX гасыр башында Г. Камал һәм Г. Тукай тарафыннан нигез салынган «Яшен» (1908–1909) һәм «Ялт-Йолт» (1910–1918) журналлары кебек, татар сатирик басма графикасы традициясен дәвам итә. «Появление печатных периодических изданий сатирического направления на татарском языке было не случайным, так как в самой культуре народа, его фольклорных произведениях средствами юмора и сатиры бичевались негативные явления, проявлявшиеся в обществе [Вагапова, 2011 с. 277].

Сатирик «Чаян» журналы таралышы белән ил башкаласы басмаларыннан калышмый, татар халкы арасында киң таныла. С.М. Червонная язганча, «В первые годы профиль журнала почти целиком определяла

«внутренняя» тематика, бытовая сатира, международной темы он касался редко. Тогда журнал имел свой ярко выраженный национальный колорит» [Червонная, 1987, с. 226]. Шуңа да карамастан, 1920 елларда, аеруча 1930 елларда журнал битләрендә татар сатирик графикасының инкыйлабка кадәрге чоры традицияләрен дәвам иткән халыкара тематика шактый урын алып тора. Тик бу тема сәнгать фәне тикшеренүләреннән ерак китми, шуңа күрә алар тагын да җентекләбрәк өйрәнеп тикшерүне таләп итә. Татарстан сатирик графикасының Совет чоры С. Червонная, Л. Елькович, А. Файнберг кебек сәнгать белгечләре хезмәтләрендә анализлана. Әмма аларның тикшеренүләре 1970 еллар белән тәгәлләнә, шуңа күрә Татарстанның карикатура сәнгате яңача, бүгенге күзлектән чыгып бәяләүне көтә.

Сатирик журналлар халыкның киң катлавына тәкъдим ителгәнлектән, андый басмаларда текстка караганда рәсемнәргә өстенлек бирелә. «Чаян»га да шул ук сыйфатлар хас. 1920 елларда милли үзаң күтәрелеше көчәя һәм журнал битләрендә милли тематика белән бәйле карикатуралар бастырыла.

1920 елларда «Чаян» рәссамнары гәүдәләндергән мөһим халыкара темаларга килгәндә, аларның шул чор өчен иң популяр булганнарын аерып күрсәтү кыен түгел. Алар, беренче чиратта, монархиянең бәреп төшерелүенә юнәлдерелә. Күп кенә карикатураларда Россия империясенең соңгы патшасы Николай II, аерым алганда, аның Көнбатыш белән мөнәсәбәтләре көлке объектына әвереелдерелә, аның шаржлаштырылган портретлары, үзен сурәтләгән карикатур рәсемнәр басылып чыга. Тагын бер мөһим тема: Көнбатыш Европа белән Американың җимергеч сәясәте, аеруча аларның күтәрелеп килүче илләргә карата колониячел сәясәте. Өченче юнәлеш: капиталистик илләрдәге халыкара инкыйлаби хәрәкәтләр. 1930 елларда Германиядә, Италиядә, Испания һәм Япониядә фашистлар яклы режимның көчәюе сәбәпле, карикатур рәсемнәрнең күбесе фашизмга каршы көрәш темасына багышлана.

«Чаян» графикасы сәнгатьчә эшләнеше белән баштагы елларында (1923–1929/30 елларда) Мәскәү журналларыннан күпкә калыша. Чөнки анда әле тиешле дәрәҗәдә сәнгати белемгә ия булмаган рәссамнар эшли. Шуңа да карамастан, аларның һәркайсы кабатланмас образлар, оригиналь сюжетлар табарга, үзләренең шәхси сәнгати манераларын булдырырга омтыла.

Татарстан сынлы сәнгатендә Совет чоры милли осталарының иң беренчесе Арсланов Госман Вәли улы (1897–1941) була, ул җирле матбугатка хезмәт күрсәтүче бердәнбер рәссам санала [Дульский, 1930, с. 10]. Г. Арсланов «Чаян» белән аның беренче көннәреннән үк хезмәттәшлек итә, журналга урнаштырылган карикатураларның күбесе аныкы була. «Азам профессии художник обучился, беря частные уроки и посещая некоторое время Пермские художественно-

промышленные мастерские» [Дульский, 1930, с. 10]. Госман Вәли улының рәсем сәнгате буенча махсус белемгә ия булмавы, әлбәттә, рәсемнәрендә дә чагылыш таба: «Они были бы еще острей и выразительнее, если бы этот несомненно талантливый график подходил с большей требовательностью к их пластической стороне, к сатирической графике рисунка» [Елькович, 1977, с. 26]. Г. Арсланов һөнәри белем җитешсезлеген карикатураларында үткен сатирасы һәм мәгънәви көлкеле сурәтләре, көтелмәгән чагыштырулары, оригиналь композицияләре, тасвирый чаралар төрлелеге белән тулыландыра. Ул персонажларны сурәтләүдә гротескка мөрәҗәгать итә, рәсемнәренең сатирик көчен төрле төстәге җете ачык буяулар белән арттыра, һәр детальне, киемнәрне бөтен нечкәлекләре белән җентекләп ясый. Г. Арсланов сатирик графиканың төрле формаларын – плакат характерындагы карикатуралар да, үзенчәлекле комикслар да (рәсемдәге күренешне хикәяләгән текстлы басмалар), аерым кешеләрнең портретларын шаржлап бирүне һ.б.ларны куллана. Рәссам Россиянең һәм Татарстанның сынлы сәнгать һәм матур әдәбият классиклары образларыннан еш файдалана. Мәсәлән, аның «Империализмга һәйкәл» карикатурасы [Арсланов, 1924, № 13, тышлык] нигезен В.В. Верещагинның «Апофеоз войны» картинасы сюжеты тәшкил итә: Николай II не, тәхет урынына, кешеләрнең баш сөякләре өеменә утырып сурәтли ул. «Халыкара печән базары» карикатурасы исә Г. Тукайның татар җәмәгатьчелегенә киң мәгълүм «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» сатирик поэмасын хәтерләтә [Арсланов, 1933, с. 7].

Г. Арсланов заманының һәр яңалыгын бик тиз тотып ала. Әйтик, «Чаян» журналының 1926 ел, 6 нчы, 7 нчы һәм 1927 ел, 12 нче саннары тышлыгына Төркия солтанлыгының таркалуына кагылышлы карикатураларын урнаштыра. Аларда соңгы төрек солтанының, качып, башка илләрнең үзен сыендыруларын сорануы, мескенлеккә төшүе тасвирлана. Европадагы социаль проблемаларны рәссам үзенең «Җанлы манекен» хезмәтендә сурәтли: кибет витринасында көннәр буе хәрәкәтсез басып торучы кызны – җанлы манекенны гәүдәләндерү аша, тыштан караганда якты төсләргә күмелгән Европадагы хатын-кызларның авыр хәлен чагылдырырга омтыла. Рәссам андагы шартларның һәр деталенә игътибар итә, витринаның бизәлешен, анда күрсәтелгән киемнәрне бөтен нечкәлекләре белән бирә. Авторның бу карикатурасында 1920 елларда Европада һәм Америкада киң таралыш яулаган арт-деко стиле йогынтысы да чалымлана. Шуны билгеләп үтәргә кирәк, 1920 еллар ахырында инде Г.В. Арсланов иҗатында аның һөнәри дәрәҗәсенең югары булуы сизелеп тора, чөнки ул графика өлкәсендә актив эшли, үз осталыгын камилләштерү белән даими шөгыльләнә.

1920 еллар ахыры – 1930 еллар башында «Чаян» журналы коллективы махсус белемгә

ия, талантлы рәссам-графиклар белән тулылана. Мәсәлән, анда П. Новичков, И. Бобровицкий, В. Кораблинов, Г. Поляков һ.б. эшли башлый.

Бу чорда журнал битләрендә халыкара тема көннән-көн зуррак урын били бара. Еш кына анда Мәскәү журналларыннан (мәсәлән, «Крокодил»дан) күчермәләр бастырыла. «Чаян»ның үз рәссамнары да, нигездә, Россиякүләм сатирик графика осталары Дмитрий Моор, Михаил Черемных, Виктор Дени һ.б. рәссамнар иҗатына юнәлеш тоталар. Шул ук вакытта алар дөнья сатирик графикасы классиклары, аеруча Франциянең төрле дәверләрдәге революцион рәссамнарына (Андре Жиль, Филипп Оноре һ.б.га) мөрәҗәгать итәләр.

1930 елларның беренче яртысында журналдагы күп кенә карикатуралар Г. Поляков (≈1901–1949) тарафыннан иҗат ителә. Ул Казан сәнгать училищесын тәмамлый, Революцион Россия рәссамнары ассоциациясендә әгъза булып тора. Г. Поляков «Чаян» журналы белән 1920 еллар ахырыннан хезмәттәшлек итә. С. Червонная аның иҗатын болай характерлый: «В его рисунках привлекает крепкая, чёткая, ритмическая слаженность композиции, своеобразная монументальность формы, живописность в передаче пространственной среды» [Червонная, 1975, с. 244]. Г. Поляков карикатуралары оригиналь табышлары һәм көтелмәгән чишелешләре белән аерылып тора. Ул беренче булып «Чаян»да фотомонтаж техникасын куллана башлый. Шул ысулдагы «Сүзсез» («Без слов») карикатурасында рәссам [Поляков, 1933, с. 4] шул чорда киң таралган революцион сатира сюжетын – ике дөнья (социализм белән капитализм) антогонизмын нигез итеп ала. Ак-кара сызылмалы рәсем фотографик сурәтне имитацияли.

1935–1936 елларда дөньякүләм сәяси графика Италиянең Эфиопиягә бәреп керүенә каршы күтәрелә. Бу темага Г. Поляков «Җиләк-җимешләр илендә» («Во фруктовой стране») рәсемен иҗат итә [Поляков, 1933, с. 4]. Рәссам Муссолининың шарж рәвешендәге символик образы аша фашистлар режимы сәясәтен яктырта. Карикатурада табутны хәтерләткән әрҗәләрдәге кеше башы сөякләре – «Яңа төрле җиләк-җимешләр»нең аллегорик жанр ярдәмендә сурәтләнүе әсәрнең драматизмын тагын да көчәйтә. Г. Поляковның бу карикатурасы, ак-кара төсләр белән генә эшләнсә дә, рәсем сәнгатендә тирән психологик образлар тудыруга ярдәм итә торган тәэсирле һәм үтемле детальләр сайлый белүе белән игътибарны бик тиз җәлеп итә.

1932 елда «Чаян» журналы битләрендә Н. Борисовның көлкеле рәсемнәре басыла башлый. Аның Октябрь революциясенең 15 еллыгына багышланган иҗаты аеруча уңышлы санала. Рәссам совет сәнгате өчен иң популяр мотивны – капитализмның җимерелүен аеруча уңышлы гәүдәләндерә: ул аны кызу тизлек белән упкынга таба чабып баручы машина рәвешендә сурәтли. Әсәрнең композициясе төрле

якка юнәлгән диагональләрне чагыштырма планда күрсәтүгә нигезләнгән. Мәсәлән, упкынга ыргылучы машина ярдәмендә ул Көнбатыш илләр җитәкчеләрен, ә кызыл флаг җилфердәтеп алга-югарыга омтылган поезд аша революциянең җиңеп чыгуын гәүдәләндерә. Ак-кара сызылмалы рәсемне кызыл төс белән төрләндерү күңел күтәренкелеге һәм якты өмет рухы өсти [Борисов, 1932, с. 10].

1939 елда «Чаян» белән үткен сәяси фикерле рәссам-график В. Кораблинов хезмәттешлек итә. Ул фәкать халыкара темаларны гына күтәрә: «С его приходом международная политическая карикатура “Чаяна” делает заметный качественный скачок» [Елькович, 1977, с. 48]. Үзенең «Бераз геометрия белән мавыгу» («Небольшое увлечение геометрией») дип аталган хезмәтендә автор фашистлар режимының ерткычлыгын сурәтләргә омтыла. Очларында Германия, Италия һәм Япония лидерлары утырган үзенчәлекле өчпочмаклыкның, шушы илләр сәясәте нәтиҗәсендә һәлакәткә дучар ителүе сурәтләнә. В. Кораблинов карикатуралары вакыйгаларны, сәяси күренешләрне турыдан-туры түгел, ә читләтеп, символик формада чагылдыра. Ул гротескка кыю мөрәҗәгать итә: сәяси процессларның, аерым шәхесләрнең һәм вакыйгаларның тискәре якларын чиктән тыш күпертеп, ассызыклап күрсәтә белә. (Соңыннан бу автор, Воронежга китеп, әдәбият өлкәсендә эшли.)

«Чаян» журналының тәүге саннары өчен карикатуралар өйрәнчек рәссамнар тарафыннан да эшләнә. Соңыннан аларның күбесе сатира осталары булып танылалар. Шундыйларның берсе – Павел Тихонович Новичков (1909–1968). Ул Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда журнал эшчәнлеген торгызу буенча зур хезмәт куя һәм сатирик графика традицияләрен саклауга һәм үстерүгә аеруча игътибар бирә. Озак кына вакытлар «Чаян»ның художество редакторы була. Аның «Туган илен саткан кешеләр» («Люди, которые продали Родину») рәсеме тирән мәгънәгә ия [Новичков, 1937, с. 9]. Башка күп кенә карикатурачылар кебек үк, ул да иҗатында фантасмагорик образлардан файдалана. Фашистларның хәрби башлыкларын П. Новичков канга сусаган, коточкыч куркыныч, кеше башлы ерткычлар рәвешендә гәүдәләндерә. Рәссам үзенең сатирасында чынбарлык белән фантастиканы оста итеп үреп бирә белә, кешеләрнең йөзләренә, фигураларына һәм киемнәренә игътибарны көчәйтү өчен чамасыз арттырып җибәрүләргә бара.

«Чаян» журналы белән хезмәттәшлектәге сатириклар һәм карикатурачылар арасында иң көчле иҗатчы Иосиф Ефимович Бобровицкий (1904–1986) була. Ул Казанга 1935 елда Бакуның «Вышка» газетасындагы эшен калдырып килә. И.Е. Бобровицкий күп фигуралы катлаулы композицияләргә мөрәҗәгать итә, аның карикатураларының күбесендә берничә вакыйга, күп предметлар һәм детальләр яктыртыла. Моңа мисал итеп, рәссамның Икенче Бөтендөнья сугышы

башланыр алдыннан гына иҗат иткән, фашизмга каршы юнәлдерелгән «Время очередной кормёжки хищников» сатирик әсәрен китерергә була [Бобровицкий, № 7, тышлык]. Плакат стилен хәтерләткән бу рәсемнең композициясендә силуэт-күләм кушылмасы файдаланылган, һәм ул сурәткә киңлек һәм тәэсирлелек өсти.

Димәк, «Чаян» сатирик журналы, чыга башлаган көненнән бирле, илдәге һәм республикадагы эчке проблемаларга гына түгел, халыкара сәяси темаларга да зур урын бирә. Басмага мөрәҗәгать итү активлыгы һәм аның проблематикасы тарихи вакыйгаларга бәйле рәвештә үзгәреп тора. 1920 елларда «Чаян» битләрендә күтәрелгән төп темалардан, әйтеп үтелгәнчә, Россия монархиясенең җимерелүен, Көнбатыш Европа белән Американың күтәрелеп килүче илләргә карата колониячел сәясәтен атарга була. Карикатураларның өченче юнәлешен – зур күпчелеген – революцион хәрәкәт тәшкил итә.

1920 елларда журналда, нигездә, махсус белеме булмаган рәссамнар эшләгәнгә күрә, анда басылган сатирик әсәрләр тиешле югарылыкта булмый әле. Ә инде, әйтеп үтелгәнчә, 1920 еллар ахырында аларга яхшы һөнәри әзерлекле карикатурачылар килеп кушыла. Һәм сатирик графика өлкәсендә зур тәҗрибә туплап килгән П. Новичков, И. Бобровицкий, В. Кораблинов һ.б. авторлар ярдәмендә «Чаян» журналы үзенең эчтәлеген сәнгатьчә югары дәрәҗәгә күтәрүгә ирешә дә.

**Әдәбият**

*Арсланов Г.В.* Живые манекены [рисунок] // Чаян. 1935. № 7–8.

*Арсланов Г.В.* Памятник империализму [рисунок] // Чаян. 1924. № 13.

*Арсланов Г.В.* На международном Сенном рынке [рисунок] // Чаян. 1933. № 11–12.

*Бобровицкий И.Е.* Время очередной кормежки хищников [рисунок] // Чаян. 1939. № 7.

*Борисов Н.* Без слов [рисунок] // Чаян. 1932. № 10–11.

*Вагапова Ф.Г.* Синтез традиций в оформлении дореволюционных татарских сатирических журналов // Филология и культура. 2011. № 26. С. 277–280.

Дульский П. М. Оформление татарской книги за революционный период. Казань: Татполиграф, 1930. 24 с.

*Елькович Л.Я.* На линии огня. Казань: Таткнигоиздат, 1977. 126 с.

*Кораблинов В.* Небольшое увлечение геометрией [рисунок] // Чаян. 1939. № 6.

*Новичков П.Т.* Люди, которые продали Родину [рисунок] // Чаян. 1937. № 2.

*Поляков Г.Я.* Во фруктовой стране [рисунок]// Чаян. 1933. № 1.

*Червонная С.М.* Искусство Татарии. М.: Искусство, 1987. 352 с.

*Червонная С.М.* Художники Советской Татарии. Казань: Таткнигоиздат, 1975. 212 с.

***Газизова Марина Ринат кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*

## Булатова М.Р. Курмантауский говор среднего диалекта татарского языка в этнолингвистическом аспекте

Китап сөючеләрнең киштәсендә тагын бер китап урын алды. Ул татар тел белеменең кызыклы да, әһәмиятле дә булган тармагына – диалектологиягә багышланган һәм «Курмантауский говор среднего диалекта татарского языка (в этнолингвистическом аспекте)» (Казань: Издательство Магариф – Вакыт, 2016) дип атала. Китапның авторы филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни хезмәткәре Миңнира Рәхим кызы Булатова.

Башкортстанның көньягында татар теленең сөйләшләре әле һаман ачыла тора, өйрәнелә килә. Менә шуларның берсе – кормантау сөйләше. Бу сөйләш М.Р. Булатова тарафыннан ачыла һәм авторның 2011–2015 елгы фәнни экспедицияләре ярдәмендә баетыла.

Китапта бик әһәмиятле кереш бирелгән, анда бу территориядә таралган сөйләшләр турында кыскача мәгълүмат китерелә: тепекәй (Д.Б. Рамазанова), турбаслы (Ф.С. Баязитова) һәм башкалар (И.С. Насипов).

Автор үзеннән алда бу өлкәне тикшереп өйрәнүчеләр хезмәтенә зур игътибар бирә, кормантау сөйләшен шулар белән чагыштырып өйрәнүгә зур көч куя. Аннан соң әлеге сөйләшне Башкортстанның көнбатыш, төньяк, үзәк өлешләрендә таралган сөйләшләр белән җентекләп чагыштырып, аерымлыкларын берәмтекләп ачыклап күрсәтә бара. Башка татар сөйләшләре һәм төрки телләр белән дә чагыштырулар уздыра.

Хезмәтнең тагын бер әһәмиятле якларыннан берсе шунда: автор сөйләшнең формалашу тарихына зур урын бирә, архив материалларын иркен файдалана, диалектологларның, археологларның, тарихчыларның хезмәтләрен тирәннән чагыштырып, тикшереп өйрәнә (Н.В. Никольский, С.И. Руденко, А.Н. Усманов, А.П. Смирнов, А.Х. Халиков, Р.Г. Кузеев, В.Ф. Генинг, Н.А. Мәҗитов, М.З. Зәкиев, Л.Т. Мәхмүтова, Ф.Г. Гарипова, Д.Б. Рамазанова, А.З. Әсфәндияров, И.С. Насипов һ.б.). Хезмәткә көчле тарихилык хас: бер яктан, анда кормантау сөйләше вәкилләренең тарихы яктыртыла, икенче яктан, сөйләшнең тарихы чагыла һәм глоттогенез һәм этногенез мәсьәләләре үзара бәйләнештә сурәтләнә.

Кормантау сөйләше Башкортстанның Гафури районы Кормантау, Бурлы, Яңа Бурлы (Новые Бурлы), Җилем-Каран (Зилим-Каран), Таштамак / Абдулла (Абдуллино), Кызыл-Яр авылларында таралган. М.Р. Булатова халык арасында йөргән легендалар, архив материаллары, ревизия кенәгәләре нигезендә һәрбер авыл тарихын, тормышкөнкүрешен тәфсилләп яза.

Хезмәттә тел белеменең бөтен тармаклары буенча анализ

ясала. Башта фонетик үзенчәлекләр бүлегенә күз салыйк. Автор *и~ә, ә~и* (*кәштә* – әд. киштә, *кәбән* – кибән, *әпәй* – ипи) кебек татар сөйләшләренең киң таралган күренешләре белән беррәттән, *о~у* (*олай* – әд. улый, *боғаз* – бугаз), *ө~ү* (*көзәтү* – әд. күзәтү), *у~ы* (*ҡарлуғач* – әд. карлыгач), *ү~и* (*күгәwен* – әд. кигәвен) кебек телнең аеруча борынгы катламнарына барып җитә торган үзенчәлекләрне тота алган һәм аларның характерын тел материаллары белән аңлатуга, башка сөйләшләр белән чагыштыруга зур урын бирә.

Сөйләшнең сузык һәм тартык авазлар системасы автор тарафыннан тулы һәм бай мәгълүматлы итеп аңлатыла. Сузыкларның, дифтонгларның составы (*-ай/-әй, -ый/-ый*) белән дә сөйләш, бер яктан, Урал төбәге татар сөйләшләренә якын торса, икенче яктан, аның Касыйм, Чүпрәле, Пермь, Себер татарлары кебек борынгы сөйләшләр белән зур уртаклыгы да ачыла.

Күпчелек тартык авазларның әйтелеше һәм кулланылышы буенча кормантау сөйләше әдәби телдәгечә. Шуның белән бергә аерымлыклар да бар. Автор нечкә әйтелешле сүзләрдә ***ш*** авазының әйтелешен аерып чыга: *щәл / ш'әл* – шәл, *бищ* – биш һ.б. Мондый күренеш урта диалектның златоуст һәм көнчыгыш диалектның саз ягы сөйләшләрендә дә бар.

Көньяк Башкортстандагы сөйләшләр өчен ***ч*** авазының кулланылышы катлаулы мәсьәлә булып тора. Татар-башкорт контактлы сөйләшләрендә аның кулланылышы төрлечә. Златоуст сөйләшендәге ***с*** *ц*-лаштыручы мишәрләргә кайтып кала дип санала. Тепекәй сөйләшендә – башкорт теле йогынтысы дип карала, учалы сөйләшендәге *(ч>)с* шулай ук мишәрләрдән булырга мөмкин. Кормантау сөйләшендәге *(ч>)с* шулай ук *ч*-ләштерүче мишәрләрдән килә булса кирәк.

Көньяк Башкортстандагы сөйләшләр өчен ***ч*** авазы урынына ***с*** куллану характерлы үзенчәлекләрнең берсе булып тора. Тепекәй, учалы, кормантау һәм златоуст сөйләшләре әлеге күренеш буенча берләшәләр. Гомумән, автор үзенчәлекләрне билгеләүгә, аңлатуга объектив якын килә, башка сөйләшләрдәге күренешләрне истә тотып аңлата белә. Бу яктан авторның китап азагында урнаштырылган (348–349 битләр) таблицасы бик урынлы.

Китапның ачышы булып саналган үзенчәлекләрдән тагын **гᵍ** авазын күрсәтергә кирәк. **Гᵍ** (мәсәлән, *Гᵍөлназ* – әд. Гөлназ) дип тамгалана торган бу вариант урта һәм көнбатыш диалектларының үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр.

Хезмәттә, гомумән, фонетик яктан бик нечкә күзәтүләр, авазлар кулланылышында күптөрле үзенчәлекләр чагылган, фонетист булырга теләүчеләр өчен бик бай материал бирелгән.

Шундый ук кызыклы да, бай да бүлек итеп «Морфология» бүлеген дә санарга мөмкин. Биредә барлык сүз төркемнәре состав ягыннан да, функцияләре буенча да тирән өйрәнелгәннәр. Сүз төркемнәре әдәби тел белән

чагыштырма планда тикшереләләр. Һәр сүз төркеменең категорияләре аерым карала һәм һәрберсенең аермалы якларын күрсәтүгә зур урын бирелә.

Мәсәлән, исем сүз төркемен генә алыйк. Билгеле булганча, иркәләү-кечерәйтү функциясе исемнәрнең аерым күрсәткече булып тора һәм ул *-кай/-кәй, -чык/-чек* кушымчасы белән белдерелә. М.Р. Булатова исә кормантау сөйләшендә *-кай/-кәй* кушымчасының 8 функциясен билгели һәм аларның һәрберсен тәфсилле итеп анализлап чыга: иркәләү-кечерәйтү мәгънәсеннән тыш, кеше исемнәре һәм туганлык терминнарына гына түгел, йорт хайваннары, җансыз һәм абстракт предмет белдергән исемнәргә дә ялгануы (*бәрәскәй, хәтеркәй*), ясагыч кушымча булуы (*сәпәкәй итү* – әд. кул чабу, *сәнсәкәй бармак*), сорау алмашлыгына да кушылуы (*нәмәкәй, нәрсәкәй*) һ.б. Күплек кушымчасының экспрессив, эмоциональ берничәшәр мәгънә төсмерләрен, килешләрнең функцияләрендә берничәшәр мәгънә функцияләрен ача. Шулай итеп, М.Р. Булатова һәр сүз төркеме турындагы өйрәтмәләрне баета.

Шундый ук юл белән башка сүз төркемнәре дә анализлана: сыйфат ясагыч кушымчалар, сан ясагыч кушымчалар *-лаган/-ләгән* (*йегермеләгән бала* – әд. егермеләп), төп сан урынына җыю санын куллану (*икәүсе уқый* – әд. икесе укый), алмашлыклар: *анау, монау, нәмә, қайсылай, әләйди* (әллә нинди), *берәй* һ.б.

Алмашлыкларның төрләнешендәге аерымлыклар исә борынгы төрки телгә үк барып тоташа: *безең, мениң* һ.б. Юнәлеш килешендә фонетик вариантлар хас (мәсәлән: *мийә/мийа/миңә* һ.б.). Шундый ук формалар бәрәңге, дөбъяз, керәшен, пермь һәм башка татар сөйләшләрендә, башкорт, ногай, караим, азәрбайҗан һ.б. телләрдә күзәтелә.

Татар телендә диалекталь күренешләргә иң бай сүз төркеме булып фигыль санала. М.Р. Булатованың тикшеренүләре дә шуны күрсәтә. Һәр заман формасы, аның төрләнеше, функцияләре автор тарафыннан бик җентекләп анализлана: затланышлы, затланышсыз формалар, инфинитив формалары *-ырга/-ергә, -мага/-мәгә, -мак/-мәк, -уга/-үгә, -асы/-әсе.*

Ярдәмлек сүз төркемнәре дә кормантау сөйләшендә шактый үзенчәлекле икәне ачыклана. Автор аларның составы ягыннан да, функцияләре ягыннан да өйрәнә торган сөйләштә кызыклы үзенчәлекләр таба алган.

Кайбер бәйлекләргә вариантлылык хас: *кебек / күwек / кеwек / күк; сыман / сымақ; белән / белә / была; тикле / тиклек / тиклем; қадәр / қәдәр / хәдәр(е) / хәдәрле* һ.б. Сөйләш өчен үзенчәлекле бәйлекләр дә табылган, алар татар теленең мөмкинлекләрен чагылдыра: *алта* – әд. алып. Гомумән, *ал* – тамырыннан мондый бәйлекләр Урал тирәсе сөйләшләрендә күп очрый. Мәсәлән: *ала, әләп* – әд. алып һ.б. Сөйләштә бәйлек сүзләр дә шактый. Әдәби телдәгеләрдән тыш, сөйләштә *тапкыр, кыр, эргә* һ.б. кулланыла.

Теркәгечләр һәм кисәкчәләр бүлекчәләре дә автор тарафыннан

җентекләп, иренмичә анализланганнар, мисаллар күп китерелә.

Хезмәтнең уңышлы якларыннан берсе – анда синтаксис бүлеге аерым бирелә, синтаксик категорияләр махсус тикшерелә, моның өчен диалектология фәнендә синтаксис белән бәйле мәсьәләләрнең куелышы, диалекталь синтаксисның өйрәнелеше турында кереш урнаштырыла. Синтаксис мәсьәләләре сүзтезмәләр, хәбәрне формалаштыру, хикәя җөмләнең төзелеше турында, өндәү җөмләләрнең бирелеше, инверсия, кушма җөмләләрнең типлары дигән бүлекчәләрдә яктыртыла, кайбер мәсьәләләр яңалыклы булуы белән үзенчәлекле.

Автор кормантау сөйләшенең лексик үзенчәлекләренә дә зур игътибар бирә. Диалекталь лексиканы тематик төркемнәргә бүлеп тикшерә. Бер төркем сүзләр сөйләштә икенче мәгънә төсмере дә белдерә икән: *бәс* – 1) сыкы, 2) көрән төс (коричневый); *җай* – 1) тәртип, тыныч, мөмкинлек, 2) әкрен, ипләп; *азақ* – 1) әд. азак, 2) аннары һ.б. Кайбер сүзләр үзенчәлекле төсмер белдерә: *қыстырма* – кер кыстыргычы, *бер килке* – бервакыт һ.б.

Хезмәттә кантуганлык һәм никах туганлыгы атамалары тулысынча, система итеп яктыртылган: *әни, әти, энекәш, апа, ага, түтәй, бисә/бичә, каембикә, балдыз* һ.б.

Кеше белән бәйле атамалар шулай ук үзенчәлекле төркемне тәшкил итәләр: *йаwрын* – әд. иңбаш; *йөнтәфи* – йонлач; *көмәгәй* – аңкау; *танау* – борын; *тубық* – тез; *сыйқан* – чуан; *әшимә* – әкрен эшләүче, җыйнаксыз (кеше); *бүсмәт* – 1) юан, 2) әкрен кыймылдаучы; *қапақ* – кукраючан; *саха* – сантый; *мықтым* – нык, таза; *шақару* – каеру һ.б.

Үсемлекләр, хайваннар дөньясы белән бәйле лексика шулай ук бик бай: *оргасы* – саулык/теше; *драж* – төклетура; *қайау* – корт угы; *өкө* – мәче башлы ябалак; *йыла* – элмә; *қарға қарағаты* – карга шомырты; *кәшәнәк* – касә яфрагы; *көрән мәтрүшкә* – мәтрүшкә; *песәй күмәсе* – песи борчагы; *тал көсөге* – тал песие; *кәшәнәк* – касә яфракчыгы; *сасқау* – дымлы, томанлы (һава) һ.б.

Матди мәдәният белән бәйле лексика да бик бай, анда төп сүзләрдән башка, үзенчәлекле вариантлар да күп күзәтелә. Кайберләрен күрсәтеп үтик: *кәлкүн* – әд. таган, *төнәү* – кунача, *җилпүгес* – йолпыч, *пежник* – сукыр лампа, *чиқалай* – мүкләгеч, *башантай* – йон оекбаш, *кәзә тойақ сабата* – күтәртмәле чабата һ.б.

Сөйләштә рухи мәдәният белән бәйле үзенчәлекле атамалар системасы формалашкан: *аулақ өй, сәмриқош уйыны, сабан сөрөш, үсмә алыш уйыны* һ.б. Кайбер бәйрәм исемнәре игътибарга лаек: *қарға ботқасы, җизнәй бүләге, сугым өмәсе, җәй ташы* һ.б. Бу төр лексика автор тарафыннан кушымта итеп бирелгән.

Лексика бүлегендә генетик катламнар да берникадәр аерып чыгарыла: гарәп-фарсы, рус, башкорт, фин-угыр алынмалары.

Сөйләш диалектизмнарга бик бай, аларның кайберләре әле өйрәнелеп кенә килә. Автор туган ягы сөйләшен яхшы белә, бай материал тәкъдим итә. Китерелгән лексик материалларның бер өлеше фәнгә беренче башлап кертелә.

Кормантау сөйләшенең фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләрен һәм бу сөйләш вәкилләренә хас булган гореф-гадәтләрне, йолаларны, халык авыз иҗатын, авыллар тарихын һәм тормыш-көнкүрешен чагылдырган материаллар сөйләү үрнәкләре рәвешендә кушымта бүлегендә бирелә.

Гомумән, Миңнира Булатованың монографиясе татар диалектологиясен үстерүгә зур өлеш кертә. Хезмәтнең кайсы бүлегенә күз салсак та, авторның яңалыклары шактый, кормантау сөйләше әдәби телгә дә яңалыклар кертә. Хезмәт татар диалектологиясенең казанышларын истә тотып язылган, югары дәрәҗәдәге анализ үрнәге итеп карала ала.

***Рамазанова Дария Бәйрәм кызы**,*
*филология фәннәре докторы, профессор*

# Сәнәигы нәфисә. Искусствоведение Татарстана: альманах. Выпуск 1. Теория, история, современная художественная практика, арт-рынок

*Басманың концепциясе һәм перспективасы хакында редактор сүзе*

«Сәнәигы нәфисә / Икусствоведение Татарстана: альманах» басмасын эшләүгә алынуымның сәбәбе – Казан сәнгать белгечләренең, рәссамнарның һәм сәнгать сөючеләрнең күптәнге хыялын тормышка ашыру ниятеннән булды.

XX гасыр башында ук инде татар мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре Габдулла Тукай белән Галимҗан Ибраһимов сәнгать турында «Сәнәигы нәфисә» (нәфис сәнгать) дигән журнал чыгарырга хыялланганнар. Шушы рухтагы журнал чыгару омтылышын, беренче булып, «Туган» мәдәни фонды (президенты С. Хәбибрахманова) ясый һәм 1993–1995 елларда «Татарстан» журналына кушымта рәвешендә аның берничә санын чыгаруга да ирешә.

Әлеге «Альманах» исә сәнгать белеме өлкәсендә, башка басмаларның кушымчасы гына булмыйча, махсус җыентык булarak төзелде. Аның сәнгатипублицистик, әдәби, иҗтимагыйсәяси журналлардан аермасы шунда, бу басмада сынлы сәнгать һәм декоратив-гамәли сәнгать буенча фәнни язмалар урнаштыру күздә тотылмады. Анда, беренче чиратта, ватан һәм дөнья сәнгате киңлегендә Татарстан Республикасының заманча сәнгати тормышындагы мөһим аспектларны чагылдыру бурычы куелды.

Безнең бурыч – сәнгать белеме фәне горизонтларын киңәйтү – фәннәрара тикшеренүләргә төрлечә карашларны, аның методологиясен, киләчәген күрсәтү, инде танылып өлгергән һәм яшь талантлы сәнгать белгечләренең яңа хезмәтләре белән таныштыру. Анда хәзерге этапта музейлар һәм галереяларда оештырылган күпкырлы күргәзмәчелек эшчәнлеге беренче тапкыр зур масштабта яктыртыла.

Сәнгать белгечләренең һәм әйдәүче рәссамнарның сәнгати киңлектә киң яклау тапкан концептуаль идеяләре һәм кураторлык проектлары фәнни яңгыраш алачак һәм алар гаять мавыктыргыч образлы һәм пластик контекстлар өстендә эшләүгә юл ачачак. Мәгълүм булганча, алар бүген бик актуаль һәм заманча фәлсәфи эзләнүләр рухын җанландырып, сәнгати танып белү процессының чикләрен юкка чыгаралар, һәм рәссамнарга (А. Ильясова, И. Хәсәнов, С. Гыйләҗетдинов һ.б.га) үзләрендәге киңкырлы авторлык сәләтен эшкә җигәргә мөмкинлек тудырачак. Басмада рәссамнарның гына түгел, сәнгать белгечләренең дә иҗади портретларына зур урын бирелгән. Моның максаты – рәссамның, сәнгать белеме өлкәсендәге галимнең иҗади шәхесен, аның иҗтимагый һәм социаль статусын күтәрү.

Бүген сәнгать өлкәсендә тикшеренүләр алып баручылар белән беррәттән, гаять киң танылу яулаган осталар, аз өйрәнелгән авторлар, халык сәнгате турында әлегә кадәр билгесез кала килгән фактларга һәм сәнгати һөнәрчелек, кәсепчелекне үстерү хакындагы проблемаларга да басмада киң урын бирелә.

Игътибар үзәгендә – профессиональ рәссамнар, сәнгать белгечләре, арт-базар белгечләре әзерләүнең актуаль проблемалары. Илдәге күренекле фәнни тикшеренү учреждениеләренең үзара элемтәсенә, Россиянең төрле шәһәрләрендәге һәм дөньядагы тар профильле белгечләрне, арт-тәнкыйтьчеләрне, коллекционерларны, галереячыларны, наширләрне басма хезмәтләр әзерләүгә тартуның перспективасы зур. Бу уңайдан «Галеев-галерея» (Мәскәү) тәҗрибәсе игътибарга лаек, ул безнең регион рәссамнары күргәзмәләрен, алар турындагы монографияләрне бастырып чыгару эшен башлап җибәрде. Аның проектларында коллекционерның шәхси зәвыгы илдәге аз билгеле сәнгатьне өйрәнүнең актуальлеге белән тәңгәлләшә. Бу проектны тормышка ашыруның бүгенге этабында ук инде Мәскәү, Идел буе регионы һәм төрки дөньяның танылган сәнгать белгечләрен (П. Гамзатова, Н. Розенберг, Р. Ергалиева) хезмәттәшлеккә тарту омтылышы ясала.

Соңгы елларда ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИында оештырылган «Төрки халыкларның сәнгати мәдәнияте чыганаклары һәм эволюциясе» (2008), «Төрки дөньяда киез сәнгате: тарихы һәм бүгенгесе» (2009), «Бакый Урманче иҗаты һәм милли сәнгатьнең актуаль проблемалары» (2012), «Россия һәм БДБ илләрендә сәнгать белеме үсешенең актуаль мәсьәләләре» (П.М. Дульскийның тууына 135 ел тулуга багышлана) (2014) дигән халыкара конференцияләр сәнгать белгечләре һәм рәссамнар арасындагы үзара аралашуларны җанландырып җибәрүгә зур йогынты ясады. Шулай ук ТР Сынлы сәнгать дәүләт музее инициативасы белән үткәрелгән «Казанские искусствоведческие чтения» дигән чара да игътибарга лаек.

Беренче чыгарылышның максаты – соңгы елларда (2008 дән башлап) Республика тормышындагы сәнгатьнең төрле аспектларына йомгак ясау, сәнгать өлкәсендә фәнни тикшеренүләр методологиясен яңартуның актуаль бурычларын, үзенчәлекле концепцияләрен, креатив проектларын, перспективасын калку итеп күрсәтү һәм академик фәннәр белән сәнгати эшчәнлекнең нәтиҗәле үсешенә ирешү.

Басманың «Мирас» бүлеге региондагы сәнгать дөньясының аз өйрәнелгән сәхифәләрен ача: гарәп каллиграфиясен фәнни өйрәнү аспектларын, профессиональ рәссамнар (татарлардан беренче скульптор М. Бакиев, рәсем сәнгате остасы Н. Фешин) иҗатын яктырта. Арт-күзәтүгә, репортажларга һәм рәссам, сәнгать белгечләренең әдәби иҗатына зур урын бирелә.

Яшь белгечләр әзерләү проблемасы үзенең актуальлеген

һичкайчан югалтмый, шуңа күрә басмада сәнгать белеме бирүгә багышланган язмаларга, Н. Фешин исем. Казан сәнгать мәктәбе (2015 елда 120 еллыгы билгеләп үтелде) рәссам-укытучысы Н. Фешин турындагы очеркларга зур урын бирелә.

Бүген Республикада Татарстандагы «Россия Рәссамнары берлеге», Татарстан Республикасының Рәссамнар берлеге, Татарстан рәссамнары тәшкиләте, Россия Рәссамнар берлегенең Татарстан һәм Яр Чаллы рәссамнары профессиональ бүлеге эшли. Безнең фикеребезчә, бу оешмалар барысы да бердәм иҗади пространствоның бер өлешен тәшкил итә һәм заманыбызның сәнгати процессы аспектларын төрле яклап чагылдыра, шул ук вакытта зур фәнни кызыксыну тудыра.

1935–1936 елларда Татарстанда мөстәкыйль эшли башлаган, рәссамнарны һәм сәнгать белгечләрен берләштергән (ул вакытта әле СССРның да, РСФСРның да Рәссамнар берлеге формалашмаган була) бу оешма бай традицияләргә ия. 2016 елның декабрендә без үзебезнең иҗади берлегебезнең 80 еллыгын билгеләп үттек.

Альманахның бу чыгарылышы шушы мөһим вакыйгаларга багышлана.

***Солтанова Рауза Рифкать кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире*

# Татарлар һәм Татарстан: «Татар энциклопедиясе»нең 5 нче томы дөнья күрде

Яңа гына Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә «Татар энциклопедиясе»нең ТР ФАнең Энциклопедия һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан эшләнеп басмага әзерләнгән 5нче томы ана телебездә дөнья күрде. «Татар энциклопедиясе» – татар халкы һәм Татарстанның борынгы чордан алып безнең көннәргә кадәрге тарихын яктырткан фәнни универсаль басма. Бу томда «Р», «С», «Т» (1 нче өлеше) хәрефләренә багышланган 3824 мәкалә урын алган. Аларның 1500 е шәхесләргә багышланган, 950 дән артык иллюстрация бар. Бу басма рус телендә чыккан энциклопедиянең тәрҗемәсе генә түгел. Аңа 100 дән артык яңа мәкалә өстәлде, күбесе яңартылды, төзәтелде, яңа статистик мәгълүматлар белән тулыландырылды.

Әлеге том бик үзенчәлекле, чөнки ул тулысы белән «татарлар», «Татарстан» төшенчәләре белән бәйле, шуңа күрә татар халкы, Татарстанның тарихы, сәнгате, әдәбияты, сәнәгате, авыл хуҗалыгы һ.б. өлкәләренең үсешен күрсәткән мәгълүматка бай мәкаләләр шушы томда тупланган. «Татарстан Республикасы» мәкаләсе үзе генә дә 54 бит урын алган. Анда республикабызның Конституциясе, хокукый статусы, административ-территориаль бүленеше, дәүләт органнары, символлары, дәүләт бүләкләре һ.б. турында аерым мәкаләләр бирелгән. «Татарлар» мәкаләсендә татар халкының килеп чыгышы мәсьәләсендә фәндәге 3 төп концепция китерелгән. Беренчесе – болгар-татар, икенчесе – татар-монгол, өченчесе төрки-татар концепцияләре. Татар сүзе белән башланган мәкаләләр бихисап: «Татар әдәбияты», «Татар драматургиясе», «Татар поэзиясе», «Татар прозасы», «Татар мәгърифәтчелеге», татар театрлары: «Татар академия театры», «Татар опера һәм балет театры», «Татар курчак театры «Әкият», «Татар халык архитектурасы», «Татар халык сәнгате», «Татар халык йолалары» һ.б. Республикабызның 331 авылы «Т» хәрефенә бирелгән, 62 авылның исеме дә татар сүзе белән башлана: Татар Аксуы, Татар Әйшәсе, Татар Буасы, Татар Суксуы, Татар Урматы, Татар Ялтаны һ.б.

«Р» хәрефенә бирелгән «Руслар», «Рус теле», «Рус алынмалары», «Рус халык архитектурасы», «Рус халык сәнгате», «Рус Урматы авыллыгы», «Руслаштыру сәясәте» исемле мәкаләләрдә Татарстанда рус халкы белән бәйле күп мәгълүмат тупланган. Күләмле, иллюстрацияләр белән бизәлгән «Руслар» мәкаләсендә (авторлары Р.Р. Батыршин, Г.Р. Столярова) халыкның Татарстан төбәгенә килеп урнашу тарихы, тормыш-көнкүреш рәвешләре, традицион милли киемнәре, социаль катлаулары, архитектура үзенчәлекләре, бәйрәмнәре чагылыш таба. Авылларга багышланган мәкаләләрнең исемендә күп кенә авыллар рус сүзе белән башлана: Рус Акташы, Рус

Әшнәге, Рус Сарсазы, Рус Урматы, Рус Ялтаны һ.б.

«С» хәрефенә башланган мәкаләләр дә үзенчәлекле. Алар «Саба» сүзе белән башлана: «Саба елгасы», «Саба районы», «Саба урманчылыгы», «Саба төбәк тарихы музее», «Саба аучылык тыюлыгы». Бу томда татар халкының милли бәйрәме Сабан туена, сынлы сәнгатькә, Советлар Союзы Геройларына, Социалистик Хезмәт Геройларына багышланган аерым күләмле мәкаләләр дә урын алган. Татарстанда яшәүчеләрдән 185 кеше Советлар Союзы Герое исеменә лаек була, шуларның 63е – татар, Социалистик Хезмәт Герое исеме 201 кешегә бирелә, аларның 93е – татар. «С» хәрефенә республиканың 117 авылы исеме теркәлгән, Саба, Сарман, Спас районнары турында киң мәгълүмат бирелгән. Татарстан территориясендәге археологик культуралар: «Салтау-Маяк культурасы», «Сөйке» комплексларына багышланган мәкаләләр бар. Татарлар читтә күпләп яшәгән төбәкләр турында: Рязань өлкәсе, Спас районы (Түбән Новгород өлкәсе), Сафакүл районы (Курган өлкәсе), Сатка районы (Чиләбе өлкәсе), Свердловск өлкәсе һ.б., шулай ук сәнәгать өлкәсе буенча күп мәгълүмат табарга була: Яшел Үзән шәһәрендәге «Серго исемендәге завод (Позис)», Казанның «Сантехприбор» заводы һ.б.

Энциклопедиянең хәзинәсе булырлык битләр – анда кергән аерым кешеләргә багышланган мәкаләләр (персоналийлар). Татар халкының күренекле тарихи шәхесләре: Казан ханнары Сәхибгәрәй хан, Сафагәрәй хан; җәмәгать эшлеклеләре Рәмиевләр, Таһировлар; сәнгать эшлеклеләре, халык артистлары: Сара Садыйкова, Салих Сәйдәшев, Җәваһирә Сәлахова, Габдулла Рәхимкулов, Натан Рахлин, Марсель Сәлимҗанов, Ринат Таҗетдинов, Александр Сладковский, Александр Славутский һ.б.; күренекле язучылар: Атилла Расих, Әхмәт Рәшит, Ибраһим Салахов, Сәгыйть Сүнчәләй, Һади Такташ һ.б.; күренекле галимнәр: академиклар Р.З. Сәгъдиев, Р.С. Сәйфуллин, Т.К. Сираҗетдинов, М.Х. Сәлахов, Н.А. Сәхибуллин, И.А. Тарчевский, В.П. Тронов һ.б.; сәясәт һәм дәүләт эшлеклеләре, авыл хуҗалыгы, сәнәгать җитәкчеләре һәм бик күп башка халык хуҗалыгы тармакларында эшләгән күренекле шәхесләрнең эшчәнлеге киң яктыртыла. Том ахырындагы кушымталар да игътибарга лаек. Анда Социалистик Хезмәт Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге лауреатлары, ТРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреатларының, шулай ук 5 нче том авторларының тулы исемлекләре бар. Татарстан Республикасының физик, административ, геологик карталары, шулай ук Татарларның Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә күпләп таралып урнашкан төбәкләрен күрсәткән карталар татар телендә бирелгән. Татарстанда 201 кеше Социалистик Хезмәт Герое исемен ала, шуларның 93 е – татар.

Кыскасы, Татар энциклопедиясенең ана телебездә эшләнгән 5 томы – Республикабызның, татар халкының зур рухи һәм матди потенциалга ия булуын күрсәтүче басма. Әлеге хезмәтнең дөнья күрүе – «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»н гамәлгә ашыру максатында башкарылган зур эш. Татар энциклопедиясе югары уку йортлары һәм мәктәп укытучыларының, журналистлар, матбугат, мәдәният хезмәткәрләренең һәм башка зыялыларның, һичшиксез, китап киштәләрендә булыр дип ышанабыз.

Бу том да, башка томнар кебек үк, республикабызның фәнни-тикшеренү институтларына, югары уку йортларына, ТР Милли китапханәсенә, архив учреждениеләренә, радио-телевидение, вакытлы матбугат органнарына тапшырылачак.

***Яруллина Алсу Гыйният кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Татар энциклопедиясе*
*һәм төбәкне өйрәнү институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

**2017 елның 24 апрелендә** Казандагы Г. Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе залында ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире, композитор, Татарстан Республикасының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Эльмира Галимованың иҗат кичәсе булды. Композиторларның I халыкара конкурс лауреаты исемен яулаган сәнгатькәрнең соңгы ике дистә еллар дәвамында иҗат иткән музыкаль әсәрләре тамашачыга театрлаштырылган концерт рәвешендә тәкъдим ителде.

Юбилярның иҗат кичәсен дәвам иткәндәй, 25 апрельдә Төркиянең Анкара шәһәрендә «Төрки дөнья хатын-кыз композиторлары концерты» халыкара проекты тормышка ашырыла. Анда Төркия, Казакъстан, Төрекмәнстан, Кыргызстан, Башкортстан, Азәрбайҗан авторларының һәм Татарстаннан Эльмира Галимованың музыкаль әсәрләре яңгырый. ТӘһСИнең театр һәм музыка бүлеге мөдире, сәнгать фәннәре кандидаты, композитор Э. Галимова бу проектта үзенең камера оркестры өчен язган «String extravaganza» әсәре белән катнашты.

**2017 елның 25 апрелендә** язучы, дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 130 ел тулуга багышланган «Мәдәниятләр төрлелеге контекстында Галимҗан Ибраһимов мирасы» дип исемләнгән халыкара фәнни-гамәли конференция булды. Ул Халыкара Төрки академия, Башкортстан Республикасы Фәннәр академиясе, Россия гуманитар фәннәр фонды белән берлектә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылды.

Конференция эшендә Татарстан Республикасы дәүләт органнары, ТР Фәннәр академиясе, республиканың фәнни һәм фәнни-белем бирү учреждениеләре, ТР Язучылар берлеге, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре; Казакъстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан Республикаларының фәннәр академияләре галимнәре; Мәскәүдән, Башкортстан, Чувашстан, Удмуртия, Кырым Республикаларыннан вәкилләр катнашты.

Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К.М. Миңнуллин тарафыннан эзлекле алып барылган пленар утырышта ТР Фәннәр академиясе президенты М.Х. Саләхов, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.А. Ратникова конференциядә катнашучыларга тәбрикләү сүзе җиткерделәр. Казакъстанның Л.Н. Гумилев исем. Евразия милли университеты профессоры Жакупов Жантас Алтай улы, Кыргызстанның Ч. Айтматов исем. Тел һәм әдәбият институты баш фәнни хезмәткәре Соронкулов Гөлҗегет Үмәр улы, Башкортстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Гаязов Әлфис Суфиян улы, Башкортстанда чыга торган татар газетасы «Кызыл Таң»ның баш мөхәррире Фәтхетдинов Фаил Камил улы, Кырым инженерлык-педагогика университетының кафедра мөдире Куртсәетов Рефик Җафар улы, Кырымтатар Язучылар берлеге сәркатибе, «Йолдыз» журналы баш мөхәррире Османов Диләвәр Ибраһим улы һ.б. сәламләү сүзе белән чыгыш ясадылар.

Конференция эшендә катнашучылар Галимҗан Ибраһимовка багышлап оештырылган күргәзмәдә әдипнең инкыйлабка кадәр үз кулы белән язган мәкаләләре, шулай ук Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан соңгы елларда әзерләп нәшер ителгән басмалар (алар арасында әле генә

дөнья күргән «Галимҗан Ибраһимов: "Мин хәят эзләдем, хәятта мәгънә эзләдем…"», «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. 3 нче чыгарылыш», «Галимджан Ибрагимов в фотографиях» китаплары да бар) белән таныштылар.

Галимнәр тарафыннан конференция өчен махсус әзерләнгән материаллардан «Мәдәниятләр төрлелеге контекстында Галимҗан Ибраһимов мирасы» дигән җыентык басылып чыкты (Казан: ТӘһСИ, 2017. 368 б.). Әлеге басмада Татарстан Республикасы һәм Россиянең башка регионнарыннан (Башкортстан, Чувашстан, Кырым Республикалары һ.б.), якын һәм ерак чит илләрдән (Казакъстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан һ.б.) 90 лап автор хезмәте урын алган. Аларда төркитатар һәм дөнья әдәбияты киңлегендә Галимҗан Ибраһимов иҗатының барлык юнәлешләрен дә чагылдыру; Галимҗан Ибраһимовның иҗтимагый эшчәнлеген тагын да тулырак яктырту; язучының әдәби, публицистик һәм эпистоляр мирасында фәлсәфи аспектларны төгәлрәк ачыклау; әдипнең әдәби-тәнкыйди эшчәнлеген һәм тел белеме өлкәсендәге хезмәтләрен киңрәк колачлау зур урын алып тора.

**2017 елның 26–28 апрелендә** Таулы Алтай шәһәрендә «Алтай теле белеменең көнүзәк мәсьәләләре: әдәби телне үстерү проблемалары, бүгенге орфографияне камилләштерү» («Актуальные вопросы алтайского языкознания: проблемы развития литературного языка, совершенствование современной орфографии») темасы буенча Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция уздырылды. Анда ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Ф.И. Таһирова да катнашты һәм «Татар теле орфографиясенең кайбер проблемалары» («Некоторые проблемы орфографии татарского языка») хакында сөйләде. Аның чыгышы Алтай тел белгечләрендә зур кызыксыну уятты. Алар татар һәм алтай телләре орфографиясендәге охшашлыкларны аерым билгеләп үттеләр.

**2017 елның 16 май** көнендә Кукмара районы Крайны өйрәнү музеенда «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясен дәвам итеп дөнья күргән «Милли-мәдәни мирасыбыз: Кукмара» китабын тәкъдим итү чарасы уздырылды. Анда район башкарма комитеты органнары вәкилләре, китапханәчеләр, музей хезмәткәрләре катнашты. Кунаклар арасында ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ тарафыннан 2011 елда шушы районга оештырылган комплекслы экспедициядә катнашкан галимнәр һәм Кукмара төбәгенең халык иҗаты, тел үзенчәлекләре, рухи мәдәнияте, музыкаль һәм сынлы сәнгате хакында борынгыдан әлегә кадәр сакланып килгән милли-рухи хәзинәне туплауда ярдәм күрсәткән информантлар да бар иде.

Китапны тәкъдим итү кичәсендә әлеге җыентыкның авторлары – Институтның халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре И.Г. Закирова, тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире Р.Р. Солтанова, халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре Ф.С. Баязитова катнашып, чыгыш ясадылар.

Крайны өйрәнү музее директоры Л.А. Дәүләтшина үзенең чыгышында бу китапның Кукмара районы халкы өчен бәяләп бетергесез рухи хәзинә булуына басым ясады.

**2017 елның 18–19 май** көннәрендә Казанда Россиянең күренекле сәнгать белгече, музей эшлеклесе, коллекционер, библиофил һәм педагог П.Е. Корниловның тууына

120 ел тулуга багышлап, «Россиядә, БДБ илләрендә һәм төрки дөньяда сәнгать белемен үстерүнең көнүзәк бурычлары» («Актуальные вопросы развития искусствознания в России, странах СНГ и тюркского мира») дигән халыкара фәнни конференция булып узды. ТР Фәннәр академиясе һәм аның Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Бөтенроссия «Сәнгать белгечләре ассоцияциясе» иҗтимагый оешмасы тарафыннан әзерләнгән бу форум ТР ФА залында үткәрелде.

Конференциядә катнашучылар каршында тәбрикләү сүзе белән ТР ФАнең хакыйкый әгъзасы, филология фәннәре докторы, ТР ФА вице-президенты Д. Заһидуллина, ТР ФА мөхбир әгъзасы, филология фәннәре докторы, ТӘҺСИ директоры К. Миңнуллин, Бөтенроссия «Сәнгать белгечләре ассоциациясе» иҗтимагый оешмасы генераль директоры Е Грибоносова-Гребнева, Россия сәнгать академиясе каршындагы Тасвирый сәнгать теориясе һәм тарихы фәнни тикшеренү институтыннан сәнгать фәннәре докторы О. Калугина, Польшаның дөнья сәнгатен өйрәнеп тикшерү институты президенты, сәнгать фәннәре докторы Е. Малиновски (Варшава), Казакъстанның Т. Жургенов исем. Милли сәнгать академиясе галимәсе Х. Труспекова, Үзбәкстанның Бохара дәүләт архитектура-сәнгать музей-тыюлыгы филиалы мөдире О. Мавланов һ.б. чыгыш ясадылар.

Конференция кысаларында А. Харшакның «П.Е. Корнилов. Личность. Время. События. Портреты из истории искусств» монографиясенең презентациясе үткәрелде. Әлеге фәнни хезмәтнең әчтәлегенә антиквар һәм арт-дилерлар халыкара конфедерациясе (ICAAD) эксперты, галерист И. Галиев җентекле анализ ясады. «Сәнгать белгечләре ассоциациясе»нең Татарстан бүлеге тарафыннан (ТР Мәдәният министрлыгы ярдәме белән) әзерләп нәшер ителгән «Сәнәигы нәфисә / Искусствоведение Татарстана: альманах» басмасының беренче чыгарылышы конференциядә катнашучылар арасында зур кызыксыну уятты һәм җанлы фикер алышуга этәрде. П. Корнилов нәселен дәвам итүчеләрдән рәссам-график Н. Корнилова белән РФнең атказанган рәссамы А. Харшакның ТР Милли музеена, ТР дәүләт сынлы сәнгать музеена, ТР ФА Г. Ибраһим исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә, Болгар дәүләт музей-тыюлыгына, «Зөя утрау-шәһәрчеге» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музеена Петр Евгеньевич Корниловның шәхси архивында сакланган әйберләрен тапшыруы конференциянең иң мөһим мизгелләреннән берсе булды. Ул бүләкләр арасында авторның уникаль графикасы, хатлары, фотографияләре һәм башка зур кыйммәткә ия документлары бар.

Форумда катнашучылар өч елга бер тапкыр Казанда «Корнилов укулары» уздырырга сүз куештылар.

**2017 елның 18–20 май** көннәрендә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы башкаласы Казан шәһәрендә «Милли тормыш һәм дин» VIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумын үткәрде. Форум делегатлары дин өлкәсенә кагылышлы мөһим сораулар һәм мәсьәләләр буенча фикер алыштылар. Беренче тапкыр Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы 2010 елның сентябрь аенда оештырылган иде.

Быелгы форумга барлыгы 1050 делегат чакырылды. Алар Татарстан Республикасыннан һәм Россия Федерациясенең 68 регионыннан катнашты. Форум программасы кысаларында дин әһелләре 18 май көнне

түбәндәге секцияләргә бүленеп эшләделәр: ислам дине һәм татар халкының милли үзенчәлеге; Болгар Ислам академиясе – милли рухи фикерне торгызу үзәге; мәчет һәм татар гаиләсе; ислам дине һәм күпкырлы матбугат (лекторий).

20 май көнне Форум делегатлары ТР Спасс районы Болгар шәһәрендә уздырылган «Изге Болгар җыены»нда катнаштылар.

**2017 елның 22 май** көнендә Татарстан Язучылар берлеге Татарстанның халык язучысы, драматург, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинны искә алу җыены оештырды.

Кичә Тукай клубында үтте. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов җыенны ачып җибәргәндә әлеге бинаны язучыларга алып бирүдә Туфан Миңнуллинның ролен ассызыклап узды.

Искә алу җыенында Г. Тукай премиясе лауреаты Туфан Миңнуллинның робагыйларын укыдылар. Кичәне алып баручы Земфира Гыйльметдинова әдипнең робагыйларын укып, робагый укуның үзе бер сәнгать икәнлегенә төшендерде.

Шагыйрьләрне яшь җырчылар алыштыра торды. Тамашачы «Әлдермештән Әлмәндәр», «Әниләр һәм бәбиләр», «Диләфрүзгә дүрт кияү» һәм язучының башка драма әсәрләреннән җырлар тыңлады.

**2017 елның 23 май** көнендә Татарстанның Баулы шәһәрендә күренекле язучы-прозаик, публицист, сынчы, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Миргазиян Мөхәммәтзакир улы Юнысовның тууына 90 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды.

М. Юныс – әдәбиятка зур тормыш тәҗрибәсе туплап килгән каләм осталарының берсе. Сәүдә корабларында навигатор, капитан ярдәмчесе, сәяси тәрбияче сыйфатында ул бөтен дөньяны диярлек әйләнеп чыга, диңгез-океаннарны иңли, күп илләрдә була, төрле милләт халыкларының тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре белән якыннан таныша. Бу истәлекләрен ул укучыга китаплары аша җиткерә.

Язучыны искә алу кичәсендә Казаннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, әдәбият галиме, шагыйрь Равил Рахмани, Миргазиян Юнысның кызы Камилла, Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлекчәсе җитәкчесе Рәфкат Шаһиев катнаштылар.

**2017 елның 23–24 май** көннәрендә республиканың Азнакай шәһәрендә «Көнчыгыш Татарстанда кеше һәм табигать. Югалып баручы авылларны өйрәнү, аларны саклап калу һәм торгызу проблемалары» («Человек и природа в Восточном Татарстане. Проблемы изучения, сохранения и возрождения исчезнувших сел») дигән тема буенча Бөтенроссия (халыкара дәрәҗәдәге) фәнни-гамәли, тарихи-крайны өйрәнү конференциясе булды. Ул ТР Азнакай муниципаль районы администрациясе, ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, Бөтендөнья татар конгрессы, ТР Милли музее һәм башка җәмәгать оешмалары тарафыннан оештырылды. Татарстан АССР төзелүгә 100 ел тулу (1920–2020) һәм Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге даирәсендә һәм Россия Федерациясендә Экология көнен уздыру, шулай ук Азнакай шәһәренең 30 еллыгы уңае белән оештырылган бу форумның пленар утырышында ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе, халык язучысы Р.И. Вәлиев, ТР ФАнең Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты директоры, ТР ФА вице-президен-

ты Р.С. Хәкимов, Бөтенроссия татар крайны өйрәнүчеләр җәмгыяте советы рәисе, Саратов өлкәсе татарлары Милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе К.А. Аблязов, Чиләбе өлкәсеннән Г.Г. Янтурина, Курганнан Ә.Ш. Хәбибуллин чыгыш ясап, килгән кунакларга тәбрикләү сүзләрен җиткерделәр.

Конференция барышында А.Ә. Борһанов (Казан), Р.Ф. Гатауллин (Уфа), Ф.Г. Сафин (Уфа), Р.В. Шәйдуллин (Казан), Ф.Ә. Арсланов (Ростов), М.М. Миначев (Түбән Новгород), М.В. Черепанов (Казан), М.Р. Солтангузин (Оренбург өлкәсе), Ш.С. Сейтимуров (Кырым) һ.б. күтәрелгән темалар буенча үз фикерләре белән уртаклаштылар.

**2017 елның 30 маенда** мәшһүр шагыйребез Габдулла Тукайның Уфага килүенең 105 еллыгын билгеләп үтү уңаеннан тантаналы чаралар уздырылды. М. Акмулла исем. Башкорт дәүләт педагогика университетының Филологик белем һәм мәдәниятара багланышлар институты татар теле һәм әдәбияты кафедрасы базасында «Преемственность традиции в литературах родственных народов» дигән тема буенча II Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция булып узды. Аның эшендә ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ галимнәре һәм Татарстанның мәдәният эшлеклеләре дә актив катнашты.

Конференциянең пленар утырышында катнашучыларга Татарстан Республикасы халык шагыйре Р.М. Миңнуллин, «Казан утлары» журналы баш редакторы И.М. Ибраһимов котлау сүзләре җиткерделәр. Конференциядә ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ директоры, филология фәннәре докторы К.М. Миңнуллин («Тукаеведение: достижения и перспективы»), Институтның баш фәнни хезмәткәре З.З. Рәмиев («Творчество Тукая в многотомных изданиях»), Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире И.Г. Гомәров («Наследие Тукая в архивных фондах Республики Татарстан») докладлар белән чыгыш ясадылар.

«Габдулла Тукай. Энциклопедия» китабын тәкъдим итү барышында ТӘһСИдән басманың баш редакторы З.З. Рәмиев, тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире, сәнгать фәннәре кандидаты Р.Р. Солтанова (китапның коллегия әгъзасы), театр һәм музыка бүлеге мөдире, сәнгать фәннәре кандидаты Э.М. Галимова чыгыш ясадылар.

Конференциянең максатын чагылдырган истәлекле вакыйга уңае белән «Син сазыңны уйнадың» дигән тантаналы кичәдә хәзерге чор башкорт һәм татар шагыйрьләренең (Кадим Аралбай, Хәсән Назар, Марат Кәримов; Роберт Миңнуллин, Мирза Мөхәммәт) шигырьләре һәм күренекле, яшь артистлар (И. Вәлитов, А. Сагынбаева, И. Газиев, М. Шәрипов һ.б.) башкаруында татар һәм башкорт көйләре яңгырады.

Әлеге чара Башкортстан Республикасы Халыклар ассамблеясы, Башкортстан Республикасы Милли-мәдәни үзидарәсе ярдәме белән оештырылды.

**2017 елның июнь аенда** ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Татарстанның Мөслим һәм Минзәлә районнарына, Башкортстанның Стәрлебаш районына, Новосибирск өлкәсенә комплекслы экспедиция оештырды. Июль аенда экспедиция Ульяновск өлкәсендә эшләячәк.

Экспедицияләр «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау» ТР Дәүләт программалары кысаларында оештырыла.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**
На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**
2017. № 2

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 21.06.2017.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,25. Тираж 500. Заказ

Журнал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20